АМУР ФӘЛӘХ

# ЗИМАГУР



*Повесть, хикәяләр*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-44
Ф90

**Фәләх, А.Н.**

Ф90 Зимагур : повесть, хикәяләр / Амур Фәләх. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. — 174 б.

ISBN 978-5-298-01917-0


Бу китабында Амур Фәләх гади авыл халкының Бөек Ватан сугышына кадәрге һәм аннан соңгы тормыш-көнкүрешен, рухи кичерешләрен тасвирлый. Әсәрләрдә шулай ук мәңгелек тема — мәхәббәт темасы да ачык чагыла.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-44

ISBN 978-5-298-01917-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Фәләх А.Н., 2010

# Зимагур



*(Повесть)*

# 1

...Октябрь урталары. Көннәр җылы тора. Яңгыр да соңгы тапкыр ике атна элек яуган иде. Ниһаять, бу якшәмбедә Нуруллага да ял бирделәр. Ир мөмкинлектән файдаланып калырга булды: олы кызын — Фәниясен алып, хәл белеп кайту нияте белән, Саниянең әниләренә, түбән очка китте.

Кечкенә Рәйсәне бишеккә салып йоклатты да Сания йорт-җирне тәртипкә китерергә кереште. Идәннәрне юып, мичкә ягып җибәргән иде, әкрен генә ишек шакыдылар.

Хуҗабикәнең әйдәкләвен дә көтеп тормыйча керүче — әнисе Миңниса апаның ахирәте, нәни оныгы Ләйсәнне ияртеп кергән күрше Рәшидә апа иде. Ләйсән, кerә-керешкә, бишектә йоклап ятучы Рәйсә янына йөгерде.

— Нишләп ята ул бу вакытта? Көндез йоклап буламыни? Мин йокламыйм, әнигә булышам, син дә тор, — дип, балага төрткәли дә башлады.

— Ай Аллам, нишлисең? Тимә, уятма...

Рәшидә апа, яшен тизлеге белән килеп, Ләйсәнне, җилтерәтеп диярлек, бишек яныннан алып китте. Ни хикмәт, бишектәге нарасый селкенмәде дә. Бу хәл дә Ләйсәнгә бик кызык тоелды.

— Әби-и, — дип сузып җибәрде ул. — Әнигә әйт әле, Рәйсә сыман еламый торган бәби алып кайтып бирсен әле миңа да-а...

— Балакаем! — Рәшидә апа күзләрен тутырып нәүмиз кыяфәттә аңа карап торучы оныгын кочагына сыендырды. — Кая, Нуруллаң күренми.

— Фәния белән әниләргә киткәние. Кайтырлар да инде.

— Миңнисаның хәлләре ничек соң әле анда? Авырып торам, дигәние беркөнне.

— Әкренләп кенә йөри инде...

...Чәй артыннан чәй, сүз артыннан сүз — аулакта ике хатын серләшер нәрсә бетәмени...

Сания камыр әвәли башлагач кына, өстәл артыннан кузгалдылар.

— И-и, чынлап та, күзләр генә тимәсен бәләкәчеңә, кызый. Күр инде, әй, сәгатьләр буе кыймылдап та карамады бит, рәхмәт төшкере... Ярый, Саниякәй, бик озакка китте бугай, берәр эшеңнән бүлдермәгәек тагын. Чыгыйк әле без... Сый-хөрмәтләрең өчен дә Аллаһының рәхмәтләре яусын үзеңә, — дип сөйләнә-сөйләнә, Рәшидә апа, Ләйсәнне житәкләп, чыгып китү ягын карады.

Камырны вак-вак түгәрәкләргә бүлеп кайнар мичкә салган гына иде, ниһаять, Рәйсә тарафыннан да кыштырдаган тавыш ишетелә башлады, бишек селкенеп куйды. Камырга буялган учларын аннан-моннан гына сөрткәләп, Сания тизрәк бишек янына ашыкты.

— Каяле, кем икән монда? Ә-ә, минем кызым уянган бит... Үсә, үсә, үсә, үсте-е...

Әнисенең күкрәген суырып ята торгач, Рәйсә тагын мәлҗерәде. Тамагы ачып кына уянган иде, күрәсең, — бер мизгелдән инде кабат мес-мес килеп йоклап китте.

Сания, кабат ишек шакыган тавыш ишетеп, сискәнеп китте. «Монысы тагын кем булыр?..»

Хуҗабикәнең күңелен нәрсәдер тырнап алды. Ишек катына килеп басуы булды, киләсе эленмәгән икән — ишек ачылып та китте. Бусагада кечерәк буйлы, оч-очлары өскә кайтарылып торган кап-кара мыеклы, тик

чәчләренә инде чал төшкән урта яшьләрдәге бер ир елмаеп басып тора.

— Исән-саулар гынамы? — диде абый кеше һәм, җавап сүзләре көтеп тормастан, кулындагы зур чемоданын идәнгә куеп, ишек катында баскан килеш, өй эчен күздән кичерде. Игътибарын кабат Саниягә юнәлтеп, тирән итеп сулыш алды. — Галия өйдә юкмыни? — диде ул көтелмәгән хәлдән аптырап калган, әле дә булса һушына килә алмый азапланган Саниягә дәшеп.

— Сез... кем буласыз соң? — дип, сорауга каршы сорау белән җавап кайтарды Сания, уйларын тәртипкә китереп.

Кунак ягыннан төгәл җавап ишетелмәде. Саниягә аның йөзе таныш та кебек иде, тик, искә төшмәсме дип, хәтер сандыгын күпме генә актарса да, алдында кем басып торуын тәгаен генә әйтә алмады.

— Галия каядыр киткән иде мәллә, кызым? — дип кабатлады абый, Санияне газаплы уйлардан арындырып.

«Әһә, әнкәйнең танышы икән», — дип уйлап куйды Сания үзалдына. Кунакны түргә дәште.

— Әле генә эшкә чыгып китте шул. Юлда каршыгызга очрарга тиеш иде югыйсә... Әйдәгез, узыгыз, абый.

Кунакның күзләрендә кызыксыну чаткылары кабынды. Як-ягына карана-карана, бизәкле ак чаршавы тартып куелган тәрәзә буендагы өстәл янына, Сания тәкъдим иткән аркалы урындыкка барып утырды.

— Димәк, син, сеңлем, аңлавымча, Галиянең килене буласың инде? Кайсы улыныкы соң?

— Нурулланыкы. Беләсездер бит?

«Беләсездер бит?» Менә сорау бу, ичмасам. Шулай, дускай, чит җирләрдә бик күп йөрсәң,

әллә нинди сораулар ишетерсең әле... Гомер диген, әй. Атка атланып чапкандай уза икән шул... Димәк, Нурулла да гаилә корып җибәргән. Кызны да эләктергән бит, карале, төскә-биткә ярыйсы гына күренә...

— Кызмы, малаймы? — Абый кеше түшәмгә асып куелган бишеккә ишарәләде.

— Кыз. — Сания нарасые яткан бишек янына килеп басты. — Монысы икенче балабыз, Ходай рәхмәте. Бер айлык инде.

— Беренчесе олымы соң? — дип кызыксынды кунак, шул арада аш өстәле тирәсендә мәш килә башлаган Саниягә күз ташлап.

— Яшь ярым булды. Әле әтисе бүген ял итә, икәүләшеп минем әниләргә киткәннәрие. Тиздән кайтырлар инде, боерган булса.

— Үзең кем кызы буласың соң? Бу авылныкымы, читтәнме? Бер дә төс-кыяфәтеңне чалымлый алмыйм дип әйтимме...

Сания эшеннән туктап калды. Кунак абыйга янә сәерсенеп карап куйды.

«Гаҗәп кызыксынучан кеше булып чыкты әле бу абый. Сорауларны яудырып кына тора. Нурулланың холкын белсә икән үзе... Йа Ходай, кайтып та керер әле, күп сорамас...»

Саниянең уйларын капка ягыннан колакка чалынып киткән тавыш бүлдерде. Ул уйлаганча килеп чыкмады чыгуын — ишектән керүче кеше аның Нурулласы түгел, әле генә эшкә дип чыгып киткән каенанасы Галия иде. Керүгә, өстәл янында утыручы кунакка күзе төште. Йөзе шундук җитдиләнеп калды.

— Кире борылып кайтырга туры килгәч, юлым уңмас инде дип уйлап куйган идем аны, — диде дә аралыкка кереп китте.

Каенанасының кунакны күргәч тә кинәт кәефсезләнеп калуына, аның белән исәнләшмичә

дә мич артына керен китүенә Сания аптырап калды. Моныңниндидер, әлегә үзе бөтенләй чамалый алмаган җитди сәбәбе барлыгын күңеле белән сизсә дә, каенанасы артыннан юнәлде.

— Әнкәй, нишләп алай итәсең инде, кеше бит кунакка кергән, — дип пышылдады Сания.

Галия килененең күзләренә усал караш ташлады.

— Сәбәбен аңлатырга өлгермәдемени әле? Йорт ишегеңне ачып керткәнче, иң башта нинди кунак икәнен сорарга иде үзеннән, килен, — диде дә почмакта эленеп торган бишмәт кесәсеннән ниндидер кәгазьләр алып, күлмәк кесәсенә тыкты.

— Ник монда әле син? Мәңге аяк басмам дигән идең ләбаса, — диде Галия, аралыктан чыккач, кунакка каш астыннан гына сөзеп карап.

— Нишләп алай дисең инде, Галия?..

Хуҗабикәнең бу чакырылмаган кунак белән иркенләп сөйләшеп утырырга исәбе дә, вакыты да юк иде, күрәсең.

— Ярар, эшкә соңга калам, — диде дә, өс киеменең сәдәпләрен эләктерә-эләктерә, өйдән чыгып китте.

Кунак, Галия чыгып киткән ишеккә төбәлеп, бераз тын гына утырды. Аннары, әлегәчә берни аңлый алмаган Саниянең күзләренә карарга батырчылык итмичә, әкрен генә урыныннан кузгалды.

— Ярар, кызым, Нурулла кайтканчы мин дә әйләнгәләп килим әле. Рөхсәт итсәң, әйберләрем сездә калып торсын инде, яме? Урамда өстерәп йөреп булмас, — дип, ишеккә таба юнәлде.

— Чәйләп алыйк инде, абый, кабартма да пешергән идем, — дип, Сания аны туктатырга ниятләгән иде дә, кунак:

— Кирәкмәс, рәхмәт, кызым, — дип кенә җавап кайтарды һәм чыгып та китте...

* * *

«...Авыл шактый үзгәргән. Йортлар шактый күбәйгән, урамнардагы юллар да тигез...»

Илле яшен куып килүче ир кайчандыр үзе тәпи йөреп киткән авыл урамнары буйлап атлады да атлады. Ара-тирә кайсы кая юл тоткан авылдашлары сәлам биреп узды. Танып белүчеләре бөтенләй диярлек булмады булуын, шулай да, хәтта артыннан сәерсенеп карап калсалар да, сәлам сүзләреннән ирнең күңеленә ниндидер җылылык, өмет иңгәндәй тоелды. «Кайчандыр сугыштан кайтып барганда очраган тиле Хәмит ялгышкандыр, бәлки» дигән өмет иде ул...

Шул мизгелдә, аның уй-хыялларына җавап ирештерергә теләгәндәй, берәүләрнең ишегалдында ярсып-ярсып эт өрә башлады. Эт тавышы гына булса да, «авыл холкын эт күрсәтер» диләрме әле? Ирнең кәефе мизгел эчендә кырылды, әле генә күңелендә бөреләнә башлаган өмет чаткылары юып алгандай булды.

«Нишләп йөрим инде мин? Нәрсәгә өметләнәм? Ике дистә ел чамасы элек бар нәрсәгә кул селтәп, үзем китеп барган идем бит. Туган җирен язмыш кочагына ташлап качкан адәмне авылдашлары ничек кичерсен инде?! Хыянәт иттем ләбаса, хыянәт иттем...»

## 2

...Мамадыштан килгән мәһабәт гәүдәле кешенең якты киләчәк, социализм, коммунизм турында канатланып сөйләвен бөтен авыл хал-

кы тын да алмый тыңлап утырды. Их, рәхәт заманаларда яшиселәр дә бар икән ләбаса. Моңарчы хыялларга да керен карамаган тормыш буласы ди бит — теләгән, булдыра алган кадәре генә эшләячәксең, кибетләрдән бернинди түләүсез кирәк кадәр нәрсәне аласың. Менә тормыш бу, ичмасам... Халыктан бары тик бер генә нәрсә сорала икән — даһи юлбашчыбыз иптәш Сталин тәгълиматларын өйрәнү, аларны тормышка ашыру...

«Сталин» сүзен ишеткәч, зал бер мәлгә тынып калды. Ул да булмады, үзара пышылдаша да башладылар: «Иптәш Сталинны бик кырыс холыклы диләр бит ул, нишләптер бу вәкилнең сүзләре минем күңелгә шик-шөбһә салды әле...», «Тагын берәр нәрсәгә салым-мазар өстәмәсәләр генә ярар иде инде...», «Мин ишеттем, ниндидер халык дошманнары юлбашчыбызга кул сузмакчы булган, ди...»

Пышылдап кына әйтелгән булса да, кайбер сүзләр Мамадыш вәкиле колагына да эләгеп калды. Иләп кенә торып басты да графиннан су салып эчте һәм, зал тәмам тынычлангач, сүзен дәвам итте:

— Иптәшләр, бөтен илдә социализм урнаштыруга керештек. Ишеткәнсездер, кайда утлы корал, кайда үткен тел кулланырга туры килде. Шунысы куанычлы: сез — гади халыкның күпчелеге — Коммунистлар партиясенең һәм иптәш Сталинның дөрес юлдан, бөтен дөнья халыклары өчен үрнәк юлдан атлавын аңладыгыз. Иптәш Сталин сезгә ышана, сезгә таяна, иптәшләр. Чөнки әле, сирәк-мирәк кенә булса да, партия һәм Сталин тәгълиматларын таныргa теләмәгән, халыкчан хөкүмәтебезгә каршы корткычлык юлын сайлаган искелек калдыклары — ишан-мулла ишеләр, гомер-гомергә

гади халыкны талап, эксплуатировать итеп яшәгән, шулар исәбенә баеган кулаклар очрап тора. Иптәш Сталин менә шушы элементларга каршы ачыктан-ачык сугыш алып барырга тәкъдим итә, җәмәгать... Безгә, партия әгъзаларына, бу көрәштә иң алгы сафта булырга туры килер. Лаеклы яшьләрне комсомол сафларына кабул итәргә кирәк. «Комсомол — партиябезнең дәвамчысы, резервы», — дип язган иптәш Сталин...

Мамадыш вәкиле кулындагы газетаны селкеде.

Яшь кенә булуларына карамастан, катлаулы тормышның ачысын-төчесен җитәрлек татырга өлгергән яшь-җилкенчәк, бала-чага, мондый матур сүзләрне тыңлап утырганда, таттлы хыялларга чумды. Вәкил чыгышы бала-чаганы гына түгел, бик күп михнәтләр кичереп чәчләренә вакытыннан алда чал кергән абзыйларны да, ирләре күмәк хуҗалык эшләре белән йөргәнгә, бөтен йортны үз җилкәләрендә тартып баручы, шуның өстенә кимендә биш-алты бала тәрбияләп үстерүче хатын-кызларны да битараф калдырмады.

...Харис, үз урамнарына кайтып җиткәнче, Мамадыштан килгән вәкил сөйләгәннәр хакында уйланды. «Революция булып, комсыз патшаны бәреп төшергәнгә ничәмә-ничә ел инде, ә партияне, социализмны санга сукмаучылар, коммунизм идеяләреннән шикләнүчеләр, замана тәгәрмәченә таяк тыгарга маташучылар һаман бетмәгән! Бактың исә үзебезнең авылда да ук бардыр әле алар. Күрми генә йөргәнбездер...»

— Әссәламегаләйкем, Харис улым! Җыеннан кайтасыңмы?

Үз капка төпләрендә зур гына пычак белән

ниндидер агач кисәген юнып утыручы Сабир абый егетне уйларыннан арындырды.

— Ярыйсы гына әле, — дип җавап кайтарды Харис. Олы кеше сүз каткач, игътибарсыз калдыра алмады, Сабир абый янәшәсенә үк килеп чүгәләде. — Бер тик тормыйсың син, әйеме, Сабир абый. Нәрсәләр майтарасың тагын?

— Минем билгеле инде, энем. Менә Миңлегөл апаң яңа ау үреп биргән иде, шуңа дип тәләкәләр ясап маташам әле...

Балыкчы янында озаклап утырмады Харис. Һаман да шул җыенда ишеткәннәре турында уйлана-уйлана, юлын дәвам иттерде.

«Әйе, бар шул андыйлар, карале. Шушы Сабирларны гына алыйк — ата кулаклар бит инде. Нәселдән нәселгә күчеп килгән бер шөгыльләре бар — балыкчылык. Гомер-гомергә шулай булды: елга-күлдән балык тотып кайталар да кешегә өләшәләр. Ашарына башка нәрсә булмагач, ала инде авыл халкы. Бушка дисеңме әллә? Булыр сиңа, көт! Акча алмаса да, алар бит хезмәтләтә түлиләр. Шулай булгач, эксплуататор, кулак булмыйча, кем булсын инде?! — Харисның карашы Сабир абыйларның сул як күршеләрендә генә торучы мәчет манарасына, очындагы сары ярымайга күчте. — Сабир шунда муллалык та итә бит әле. Мәчетенә кеше дә йөрми, вәгазен дә тыңлаучы юк инде, ә ул һаман үгездәй таза гәүдәсе белән мәчет манарасыннан азан әйткән булып маташа. Вәгазьләр, азаннар тыңлап утырырга яисә балык тотып кәеф-сафа корырга вакыт бар ди монда. Бүтән кешеләр кебек колхоз эшенә чыкса ярамаган микәнни?..»

* * *

...Харис үзе, гади крестьян гаиләсендә туып үссә дә, кечкенәдән белемгә омтылды. Герман сугышында бер кулын өздергән, революциядән соң Мамадышка барып укып кайткач, авыл халкын укырга-язарга өйрәтергә керешкән Кәрим абый дәресләренә дә теләп йөрде. Инде үзе хәреф таный башлагач, Кәрим абыйсыннан әллә нинди журналлар, китаплар алып торды. Беренче тапкыр Ленин тәгълиматлары, даһи юлбашчы иптәш Сталинның халык өчен башкарган игелекле гамәлләре турында да шул китап-журналлардан укып белде. Белемгә сәләтле малайны укытучы да үз итте.

— Сиңа ары таба да укырга кирәк, энекәш, — дия иде ул чираттагы китапны укып бетереп алып килгән Хариска. — Берәр кая барырга теләгең юкмы соң?

Булмый димени инде. Харисның укуын дәвам иттерәсе бик килде килүен. Тик шул ук Герман сугышында контузия алып кайтканнан бирле мантый алмыйча инде ничәмә-ничә еллар буе түшәктә ятучы әтисен, берсеннән-берсе бәләкәй дүрт бала тәрбияләүче әнисен ташлап кая гына китә ала инде ул?! Шуңа күрә әллә нинди хыяллар белән мавыгудан мәгънә юклыгы көн кебек ачык — белем эстәү нияте әлегә кадәр бары тик еракта гы, офык артындагы ният кенә булып кала бирә...

...Хариска унбиш яшь тулган елны тормыш михнәтләренә күнегеп кенә барган бөтен авылны шау-гөр китерерлек бер вакыйга булды.

Таң атып кына килә иде әле. Һич уйламаганда, Мамадыш тарафыннан ниндидер куркыныч тавышлар ишетелә башлады. Дөбер-шатыр килгән авазлардан мизгел эчендә бөтен авыл халкы уянды. Басу капкасы янына йөгере-

шеп чыктылар. Һәркемнең хәвефле карашы Мамадыш тарафына төбәлде.

Еракта н, сөзәк тау итәгеннән авылга таба ике кара нәрсә якынлашып килә иде.

— Ә-ә-ә, — дип сузды укытучы Кәрим, учын каш өстенә куеп бераз торганнан соң. — Курыкмагыз, җәмәгать, тракторлар бу...

— Нәрсә? Тыр-тыр?

Андый «тыр-тыр»ларны моңарчы күрү түгел, ишеткәне дә булмагач, авыл халкы өчен Кәримнең сүзләре генә бернәрсә дә түгел иде, билгеле. Ярты сәгать чамасы вакыт үткәннән соң, тегеләр авыл читенә килеп туктагач, тракторда утырган кешеләр исән-имин җиргә сикереп төшкәч кенә, бераз тынычландылар. Ләкин шулай да яннарына ук барып карарга батырчылык итүчеләр барыбер табылмады.

Укытучы Кәримнең сүзләренә караганда, тик торганда җансыз тимер кебек кенә күренүгә карамастан, иң көчле нәселле йөк атларыннан да шактый кодрәтлерәк икән «тыр-тыр» дигәнең. Авыл өйләрен, каралты-кураны бер урыннан икенче урынга күчерә ала, тау-ташларны «эһ» тә итмичә актарып ташлый, ди. Авырлыгы да бар икән үзенең — әнә бит, тәгәрмәч эзләре бер карыш җиргә батып тора...

«Тракторга утырып карыйсы килгәннәр бармы?» дигән сүз ишетелүгә, авылның иң кыю егетләре исәбендә торучы Харис алар янында иде инде. Ул тимер атның өстенә менеп агач урындыкка утырырга да өлгермәде, янәшәсендәге абый ниндидер тимер ыргакны үзенә таба тарткан иде — «тыр-тыр» берара пытыр-пытыр, дөбершатыр килеп торды да әкрен генә кузгалып китте.

— Нәрсә, шүрләтәме? — Тракторны иярләгән абый, куркудан күзләрен чытырдатып

йомган Хариска карап, шаркылдап көлеп җибәрде. — Ач күзеңне, кешегә тими ул... Телисеңме, сине дә өйрәтәм?..

«Ни сөйли бу абый? Өйрәтәм, диме? Көләдер әле, мин бит яшь...»

Аның уйларын укыгандай, абый кеше сул кулы белән Харисны кочаклап алды.

— Авыр эш түгел ул, менә карап тор...

Баштарак шактый катлаулы кебек тоелса да, кул ияләшкәч, трактор йөртүе җайлы гына икән. Тимер атны йөгәнләү серләренә өйрәнү өчен Хариска дүрт-биш көн җитте. Икенче атнада ук Мамадышка барып механизатор таныклыгы алып кайтты. Ярулла исемле иптәш егете белән авылның беренче тракторчысы булып киттеләр.

Эше никадәр генә авыр булмасын, егет үзлегеннән укуын ташламады. Аз гына буш вакыт тапса да, Кәрим абыйсы янына яңа китап алырга йөгерде. Тракторда ике ел чамасы гына эшләде ул. Аннары, ниндидер махсус югары уку йортларында белем алмаса да, сәяси яктан тәмам җитлеккән егетне укытучы Кәрим абый тәкъдиме белән бригадир итеп билгеләделәр.

Авылдашлары баштарак әллә ни өмет багламады аңа. Тик тәләпчән, тырыш, укымышлы яшь җитәкче кулы астындагы бригада бик тиз арада колхозда гына түгел, район алдынгылары сафына чыкты.

* * *

...Харисны колхоз рәисе Фоат чакырды. «Кызу эш вакытында юньлегә чакыртмый торгандыр, кичәге трактор өчендер инде» дигән уй йөгереп узды бригадирның күңеленнән.

Көне буе кырда эшләгәннән соң, Саматны трактор белән ферма маллары өчен болыннан печән тарттырырга җибәрделәр. Караңгы төшә башлагангамы, әз генә булса да арыганлыкны бетермәсме дип йотып куйган аракы зиһенен чуалтканмы — егет тракторының тирән чокырга керен батуын шәйләми дә калды. Күпме генә азапланмасын, тимер ат сазлы чокырдан чыга алмады. Төн уртасына кадәр көтеп тә кайтмагач, Харис, атка атланып, Саматны эзли китте.

Болыннан чыгып килүче шәүләне күреп алып, шунда элдертте.

— Нәрсә булды? Трактор кайда?

Самат бригадирны трактор янына әйдәкләде.

— Аһ, шайтан...

Харис такыр юлдан ике адым читтә, кабинасына кадәр саз эчендә утыручы тракторга төбәлеп төкереп куйды.

— Көне буе эшләп арылган, ничек кереп чумганымны сизми дә калдым, — диде Самат, аклангандай.

Харисның борынына сасы аракы исе килеп бәрелде.

— Әле син исерек килеш тракторга утырдыңмы?!

Бригадир, йодрыкларын йомарлап, Саматның өстенә килә башлады.

Тракторчы арткарак чигенде.

— Ярар инде, Харис, кызма...

Самат сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, Харис бар көченә аның яңагына сугып җибәрде. Ул тракторы янәшәсенә барып төште.

Бригадир сөзәргә җыенган үгез кебек карады да:

— Дуңгыз! Иртән трактор чип-чиста ки-

леш идарә каршында басып торсын! — дип, атына атланып, авылга кайтып китте.

Самат, авылга кайтып, Хәсәнне уятты. Аңа хәлне аңлатып бирде, ярдәмгә чакырды.

— Харис килгән иде инде, — диде Хәсән. — «Саматка булышасы түгел, юкса син дә трактордан коры каласың» дип кисәтеп чыгып китте...

Саматның башы түбән иелде.

— Булышмыйсың инде алайса?

— Үпкәләмә, кордаш. — Хәсән карашын читкә алды. — Харисны үзең беләсең...

Самат, кул селтәп, чыгып китте. Капкадан чыгып биш-алты адым гына атлаган иде, артыннан Хәсәннең тавышы ишетелде.

— Тукта, мин дә синең белән...

Йорт саен керен йөри торгач, ун ир-ат җыелды. Болынга төшеп киттеләр.

Иртән-иртүк Саматның тракторы колхоз идарәсе каршында тора иде инде...

* * *

— Нәрсә, энекәш, килдеңме?

Харис сүзсез генә рәис күрсәткән урындыкка килеп утырды. Үзенә сиздермичә генә, Фоатның йөзенә карады.

Колхоз рәисенең йөзендә ул-бу сизелмәде. Рәиснең Самат мәсьәләсендә чакыртмаганлыгын тоеп, Харис җиңел сулап куйды.

Фоат өстәл тартмасыннан бер катыргы кәгазь тартып чыгарды. Елмаеп, Хариска сузды.

— Мә, бу сиңа!

Катыргыдагы язмага күз йөртеп чыккач, Харисның да авызы ерылды. Колхоз рәисенә сораулы караш ташлады.

— Эш рәтен белгәннәрне тегендә дә хөрмәт

итәләр, — диде Фоат, имән бармагы белән югарыга ишарәләп. — Молодец, Харис, сиңа бирелгән бу бүләк колхоз өчен дә горурлык.

Бригадирның шатлыгы эченә сыймады:

— Рәхмәт, Фоат абый. Беләм, синең тырышлык нәтиҗәсе инде бу.

— Ярар, ярар, мактауга лаек кешеләрне вакытында күрә белү — безнең бурыч. Бар, бу грамотага өстәп премия дә бирелә, кереп ал бухгалтердан.

Харис колхоз рәисенә кат-кат рәхмәт укыйукый чыгып китте...

«Бирәм дигән колына — чыгарып куяр юлына...»

Бүләк алу шатлыгыннан канатланып кайтып килүче Харисның каршында күрше Сафа карт пәйда булды.

Инде күптәннән черек идәнен яңарту хыялы белән янган бу карт, язгы ташу суыннан сал тотып, такта ярдырмакчы иде. Юан бүрәнәләрне яр буеннан пилорамага кадәр өстерәтү нияте белән, бригадирдан трактор сорады.

Харисны кинәт алыштырып куйдылар диярсең.

— Юк сиңа трактор, — диде ул коры гына.

— Соң, Харис энем, кирәгие бит инде...

— Әйткәнме сиңа, юкмы?! — Бригадир кабынып китте: — Син урлаган ул бүрәнәләр өчен кыен ашыйсым килми. Баш катырып йөрмәле...

Сафа карт аптырап калды.

— Нинди «урлаган бүрәнә»?.. Сиңа хәтле бригадир булган Латыйп бер дә алай кыланмады, энем. Килешми, холыксызланма.

Харис кулындагы мактау кәгазен Сафа картның борын төбендә селки-селки гайрәтләнүен дәвам итте:

— Соң, бар, шул Латыйбыңнан сора. Үтереп мактыйсың шуны. Алай җүнле бригадир булгач, нигә авылдан чыгып качты, әйт әле?!

— Эш рәте белмәгәннән китмәде Латыйп, монысы сиңа да яхшы билгеле.

— Әйтәм җирле, мактап кына тордылар үзен, — диде Харис, җирәнгеч нәрсә турында сүз баргандай борынын җыерып.

Кулындагы катыргыны янә Сафаның борынына ук китереп терәде.

— Менә кара, эшләгән кешене беркайчан да онытмыйлар. Биргәннәр идеме соң Латыйпка бирәр мактау грамотасы?!

Сафа карт кулын селтәп китеп барды...

«Дисбедәге төймәләр кебек тезелешеп, берсе артыннан берсе килгән уңышлар, еш кабатланып торган мактау сүзләре кешене бозарга мөмкин» диләр. Ни хикмәт, моңарчы тыныч холыклы кебек күренгән Харис тупас, каты бәгырьле кешегә әверелде. «Эш сәгатендә вакытлы-вакытсыз гәпләшеп — ләчтит сатып утырган, буш вакытын кая куярга белми аптыраган авылдашларына, хезмәттәшләренә кул күтәргәли икән» дигән сүзләр дә ишетелгәләде. Үзе турында сөйләнгән гайбәтләр колагына барып ирешкән чакларда тәмам чыгырыннан чыга башлады бригадир.

Колхоз рәисенә барып зарланучылар да, Харисның өенә килеп янап китүчеләр дә булды. Тик Фоат бригадирның үз эшен җиренә җиткереп башкаруын, җитәкче буларак таләпчән булуын хуплады гына...

* * *

Фоат, күрше авыл кешесе булгач, кичкырын өенә кайтып киткән иде. Авыл советы

рәисе дә, шул ук вакытта колхозның партком секретаре да булып исәпләнүче Гали караңгы төшкәч кенә Харисны үз янына дәште.

Бригадир килеп кергәндә, Гали сул кулының бармак очлары белән иягенә төрткәләп, уң кулы белән биленә таянган килеш, ишекле-түрле йөренә иде. Харисның сәламенә каршы:

— Утыр! — дип кенә боерды.

Харис каушап калды, чөнки аның белән үз гомерендә беренче тапкыр болай дорфа сөйләшүләре. Әле ике-өч көн элек кенә тырыш хезмәте өчен ВЛКСМ райкомының мактау грамотасы белән бүләкләнгән Харис, үпкәсен белдереп, партком секретаре адресына әлләниләр әйтеп ташларга әзер иде бу мизгелдә. Тыелып калды. Якында, кул сузымында гына башка урындыклар, хәтта кәнәфигә хәтле була торып та, рәис бүлмәсенең аргы почмагына өеп куелган күпсанлы урындыкларның берсен өстәл янына өстерәп алып килеп, шуңа утырды. Аның бу хәрәкәтләре нindидер протест йөзеннән ясалуын Фоат та аңлап алды.

— Нәрсә керпе кебек энәләреңне кабарттың әле? — диде ул, кара күн белән тышланган кәнәфиенә җәелеп утыргач, Харисның күзләренә туп-туры карап.

Рәиснең күзләре ут чәчрәтеп яна иде.

— Нигә чакырттың, Гали абый? — Бригадир егет үзен тыныч тотты. — Эттәй арыдым, иртәгә таң тишегеннән торасы бар...

— Ә син ашыкма-а, энекәш! Ашыкканга ат типкән, ди. Тынычлан, хәзер барысын да белерсең!

Ни хикмәт, шул мизгелдә Харисның бәгырен нәрсәдер тырмап узды. Күңелендә туган уйларын куарга теләп, егет йөзен учлары белән

сыйпап алды. Ләкин рәис аны чынбарлыкка кайтарды:

— Энекәш, сине иркәләп утырырга вакытым юк, — диде ул, бригадирга таба елыша төшеп, һәм ярым пышылдауга күчте: — Яхшылап тыңла мине.

— Нәрсә булды, Гали абый? Тыңлыйм!

Рәис күн белән тышланган кәнәфиен бригадир янынарак күчерде.

— Синең турыда төрле сүзләр йөри башлады бит әле, бригадир.

— Йөридер инде, — дип кенә куйды Харис, әллә ни исе китмәгән кыяфәт чыгарып. — Эш эшләгән кешедән гаеп табарга мачтыр бит инде безнең халык.

Егетнең йөзенә бәреп чыккан битарафлык Галигә ошап бетмәде, күрәсең, — гаҗәпләнүле күзләрен бригадирның күзләренә текәде:

— Исең китмәгәнгә охшый. Бер гаепсезгә гайбәт тараталар, дисең инде алайса?

— Гали абый, бөтенләй эшләмәгән кеше генә бер дә ялгышмый инде ул. Бардыр, ялгышларым да бардыр. Гаепле булсам, җәза бир. Тик шуны әйтә алам: кемгә дә булса кул күтәргәнем юк минем, ышан...

Рәис аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— Ә Самат?

Харисның теле әйләнмәс булды. Эчтән генә салмыш тракторчыны сүгеп куйды. «Мужик диген инде шуны. Җитәкчеләргә әләкләргә дә өлгергән!»

Гали югалып калган Харисны тынычландырырга ашыкты:

— Ярар, энекәш, борчылма. Белгәнемчә, сәбәбе булган. Колхоз милке белән саксыз кыйланган кеше җавабын да алырга тиеш. Зарла-

ныn килгән иде бүген. «Шуның белән котылганыңа рәхмәт әйт» диn куыn чыгардым.

Харис җиңел сулаn куйды.

— Мактау кәгазе белән бүләкләнүең шәп, — диn дәвам итте сүзен партком секретаре. — Безгә синең кебек кешеләр кирәк!

Бригадир егетнең эчен янә рәхәтлек тойгысы кытыклаn узды. Ләкин Харис уйлавынча, Гали абыйсының кичкырын идарәгә чакыртуының төп сәбәбе бу булырга тиеш түгел иде. Ялгышмаган.

— Сиңа бер сүзем бар. Турыдан бәреп сораганга аптырама... Минем урында эшлисең киләме?

Харис бу сорауның ни өчен бирелүен аңламады.

«Кем инде үз урынын тиктомалга башка бирәүгә тәкъдим итсен? Әллә минем хакта шундыйрак гайбәт сөйләгәннәрме үзенә?»

Бәлки, ялгыш ишеткәнмендер диn, җаваnсыз калырга булды. Тик рәиснең сүзе җитди иде — кабатлаn сораганда да, йөзендә бер генә җепсел дә селкенмәде.

— Шаярмыйм, энекәш. Эшлисеңме?

Харис ни диn җаваn кайтарырга да белмәде. Дөресен әйткәндә, аның югарырак урләрне яулыйсы килә, бик килә. Бригадир егет өчен авыл советы рәисе урындыгына ирешү, һичшиксез, галәмәт сикереш булачак. Тик...

— Ник, Гали абый, синең бит әле үзеңдә дә дәрт ташып тора. — Егет салпы якка салам кыстырды.

Төз атты — аның бу сүзләре рәис күңеленә хуш килде. Канәгать елмаеп, Харисның җилкәсенә дусларча суккалаn алды.

— Ярар, — диде ул, бөтенләй пышылдауга күчеп. — Сүз булсынга гына бирмәдем мин бу сорауны. Хәзер аңлатам...

Харисның кызыксынуы арткannan-арта барды.

— Шундый хәлләр, энекәш. Партия, иптәш Сталин, райком күрсәтмәләрен кабатлап чыгасым килми инде сиңа. Син — комсомолец, үзең дә танышпыр. Нинди заманда яшәгәнлегебезне беләсең...

Харис сагаеп калды.

— Синнән берни дә яшермим, ышанычым зур, — дип дәвам итте рәис. — Минем дә үсәсем килә.

— Ник, Гали абый, син болай да авылда иң зур кеше бит инде, — диде бригадир егет, елмаеп, һәм бу сүзләрне әйтүенә үкенеп тә куйды.

— Акыллы булып маташма, малай актыгы, — дип җикерде рәис, күзләрен түгәрәкләндереп. — Бала-чага түгел бит инде син. Дөньяны безнең авыл белән генә чикләнгән дисеңме әллә?

Тынлык урнашты. Партком секретаре өстәлдәге графиннан су салып эчте.

— Тәк, Харис дус, болай итәбез, — диде ул, тагын ярым пышылдауга күчеп. — Миңа НКВД кушкан бер эшне башкарып чыгарга кирәк...

«Әһә, менә нәрсә! Юкәдә икән бит чикләвек! Тик шулай да нигә боларны миңа сөйли?»

Рәис Харисның нәрсә уйлаганын чамалады булса кирәк — «моңа серне ачып дөрес эшләдем микән» дигән кебегрәк беравык тын гына аның күзләренә текәлеп торды да дәвам итте:

— Сабир турында нәрсәләр беләсең?

— Балыкчы Сабирны әйтәсеңме?

— Ну!

Гомер-гомергә Кәрәкә күленнән, Нократ елгасыннан балык тотып көн күрүче Сабир абыйны Харис кына түгел, бөтен тирә-як халкы яхшы белә. Беренче мәхәббәте Миңниса... Әйе,

күптән түгел генә шул Сабирның Миңниса исемле кызына гыйшык тотып та йөргән булды бит әле ул...

## 3

...Авыл урамнарына кичке караңгылык пәрдәсе ябылган иде инде. Кызларның җыелыштан кайтып килешләре.

— Карале, Миңниса, — Рәшидә ахирәтенең җиңеннән тартты, — берәр нәрсә сизәсеңме?

Миңниса сагаеп калды, Рәшидәнең күзләренә сораулы караш ташлады. Ахирәте күз кырые белән генә артка таба ишарәләп алды:

— Безнең арттан берәү килә бугай анда. Байтактан искәреп барам, бер адым да калмый... Юк, юк, берүк борыла күрмә, — дип пышылдады.

«Йа Раббым, анысы кем инде тагын?! Берәр бәйләнчек җилкуар булмагае...» Миңнисаның бөтен тәне куырылып килде. Күз кырые белән генә як-ягына каранып алды. Ярый әле, бәхеткә, сирәк кенә булса да, үтеп-сүтеп йөрүчеләр күренгәли — ул-бу була калса...

Каршыда гына берәүнең ян бакча коймасына терәтеп ясаган эскәмиясе дә бар иде. Миңниса ахирәтен шунда әйдәкләде. Янәсе, бераз хәл алырга утыргандай итәләр. Артларыннан килүчене дә яхшылап күздән кичерергә, аның ниятләрен чамаларга җай чыгачак.

Эскәмиягә барып урнашулары булды, колак төпләрендә генә: «Нихәл, сылукайлар», — дигән тавыш ишетелде. Кызлар, курыккан атлы кыланып, чыр-чу килеп алдылар, утырган җирләреннән сикерешеп тордылар. Алар янәшәсендә үк яшь, чибәр егет басып тора иде. Рәшидә аны шундук танып алды.

— Кеше дип торам, син икән әле. Җанны ала яздың бит, — диде ул ниндидер зур гөнаһ кылганлыгын аңлаган кеше кыяфәтендә башын аска иеп торучы егеткә. Үзе, аның яшькелтем күзләренә карагач, ялгыш кычкырдым бугай дигән шикелле, имән бармак башын тешләп куйды, бит алмалары уттай кызуын тойды.

Шул рәвешле бер-берләренә карашып, яшьләр сүзсез генә шактый басып тордылар.

Ниһаять, егет, бар булган кыюлыгын туплап, телгә килде:

— Ярар инде, үпкәләмәгез, кызлар, — диде ул, карашын бер Рәшидәгә, бер Миңнисага күчереп. — Сезнең белән бергә кайтасым килде. Чабасыз да чабасыз, артыгыздан һич җитешле түгел.

Миңнисаның ахирәте сүз сорап кеше кисәсенә керә торганнардан түгел.

— Ташбака кебек өстерәлеп йөрергә безне кем дип беләсең син? Синең эшең юктыр да... Безгә бит әле кайткач та йоклашлы түгел, эш муеннан.

Егет тә югалып кала торганга охшамаган — җавабы һәрвакыт әзер.

— Бик яшь күренәсез бит әле болай, нинди эш ди ул төн уртасында? — дип елмайган булды.

— Беткән ди эш! — Рәшидә сөйләшер сүз бетте дигән мәгънәдә «һе!» дип кенә куйды да Миңнисаны, култыклап алып, читкәрәк сөйрәде.

— Туктагыз инде, кызлар! — Егетнең алардан калырга исәбендә дә юк иде, артларыннан атлады. — Әйдәгез, танышыйк булмаса.

— Кх-кх-кх... Ычкындың мәллә? Үз авылдашларың белән танышып йөрмәсәң... Коммун Харисны белмәскә! Бәйләнергә бүтән сүзең юктыр шул. — Рәшидә бу сүзләрне төрттеребрәк

әйтергә тырышса да, йөзе елмая иде. — Без бәйләнчекләрне яратмыйбыз.

Бераз сүзсез генә атладылар.

— Ярар инде, Рәшидә, сине белсәм дә, менә бу туташны, чынлап та, хәтерләмим бит әле.

«Бигрәк соңга калдык бүген. Әниләрдән эләгер инде. Ападан башка беркая да чыгармаслар микән бүтән».

Рәшидә кинәт үз уйларына батып, «әңгәмә»гә кысылмыйча гына янәшәдән атлаучы ахирәтенә терсәге белән төртеп алды. Миңниса дерт итеп китте.

— Ә?

— Харисның синең белән танышасы килә.

Миңниса уңайсызланып калды. Башын аска игән килеш, каш астыннан гына егеткә карады. Шул мизгелдә аларның карашлары очрашты. Кызның бит алмалары кайнар су чәчрәгәндәге кебек кызышып, чеметтереп алды.

Сүз артыннан сүз чыгып, яшьләр түбән оч ягына кайтып җиткәннәрен абайламыйча да калдылар. Кутыр урамы ягыннан Рәшидә яши торган тыкрыкка кергәч, адымнарын акрынайттылар. Җыелыштан алган тойгыларны, «яңа таныш» Харис сөйләгән мавыктыргыч хикәятләрне һич кенә дә төнге караңгылыкта калдырасы, яңалыкларга бай көнгә нокта куясы килми иде кызларның.

«Рәшидәне озата барыр инде бу Харис», — дип уйлады Миңниса һәм... күңел түрендә моңарчы бер дә сизелмәгән тойгы — көнләшү хисе уянып килүен аңлап, сискәнеп куйды.

— Ярар, мин кайтыйм инде, — диде ул әле һаман Харисны сораулар белән газаплаучы Рәшидәгә һәм, кырт борылып, күрше урамга, үз йортлары ягына таба атлады.

Рәшидә өйләренә кереп китте, күрәсең, —

караңгы тыкрык ягында шакылдап капка ябылды. Бер минут та үтмәгәндер, артыннан аяк тавышлары ишетелде.

Миңнисаны Харис куып җитте.

— Сине өеңә кадәр озатырга буламы? — диде егет тыныч кына һәм, кызның җавап кайтарганын да көтеп тормыйча, янәшәсеннән атлый башлады.

Юл буе бер сүз дә сөйләшмәделәр. Миңнисаларның капка төбенә килеп туктагач кына, бөтен кыюлыгын туплап, Харис кызның кулын тотты. Кыз, аңына килеп, кулларын тартып алды да тизрәк өйгә керәп китү ягын карады.

— Мин иртәгә киләм! — дигән сүзләр аны өйалдына кадәр озатып керде...

...Ике атналап вакыт үтте. Яшьләр көн дә аулакта, су буенда очраштылар. Беренче чорларда еш кына сөйләшер сүз таба алмыйча интеккән чаклары булгаласа да, тора-бара алар арасындагы киеренкелек үзеннән-үзе бетә барып, ике яшь йөрәк бер-берсеннән башка яши алмас дәрәҗәгә килеп җитте. Кеше күзенә күренеп йөрделәр дип әйтерлек булмаса да, «без капчыкта ятмый» дигәндәй, авылда «якын арада өйләнешергә чамалыйлар икән» дигән сүз таралды...

* * *

...Рәшидә кергәндә, Миңниса, җылы сулы тазын ишек катындагы урындыкка куеп, шунда табак-савыт җыештыра иде.

— Чыгасыңмы? — диде ул, ахирәтенең олы якта гәп корып утыручы туганнары ишетмәслек итеп, ярым пышылдап кына.

Ләкин шул вакытта Миңнисаның әнисе

килеп чыкты. Рәшидә сүзләрен ишеткән булса кирәк, тыныч кына:

— Бу вакытта кая бармакчы тагын? — дип сорап куйды һәм күрше кызының күзләренә сынаулы караш ташлады.

— Миңлегөл апа, болай гына, монда, капка төбенә генә чыгып утырыйк дигән идем. — Рәшидә сер бирмәде, җавабын тиз тапты: — Бер атна буе иркенләп сөйләшкән юк бит...

— Карале, ахирәткәем, Харисың килгәлиме соң? — диде Рәшидә, капка төбендәге эскәмиягә чыгып утыргач.

«Харисың...» Һай бу Рәшидәне...

Миңниса йолдызлар белән чуарланган күк йөзенә төбәлде дә уйга чумды.

— Килә... Карале йолдызларны, Рәшидә. Алар шундый матур итеп, серле күзләрдәй елмаялар. Һәрберсеннән җанга ниндидер якты нур үтеп керә дә, ирексездән җырлап җибәрәсе килә...

Миңниса хыял канатларын тагы да ныграк җәя төште.

«Тик... ничектер оялдыра. Күктәге йолдызлар мине ишетеп торырлар да җырлавымнан көләрләр кебек. Шуңа күрә мин җырламыйм, аларны гына күзәтәм... Ә ул тиздән мине «сорарга киләм» диде...»

Миңнисаның күз карашы әлеге ялгыз йолдызга береген калды. Кыз, киләчәген күз алдына китереп, хыял арбасына утырды да шул йолдызга таба китте...

— Миңниса, уян! — Рәшидә ахирәтен чынбарлыкка кайтарды. — Йолдызлар вакытлыча гына сердәш икәнен, аларның таң аткач та югалачакларын онытма. Төш җиргә!..

Шул вакыт кызлар бөтенләй күз алдына да китермәгән хәл булды. Капкадан Рәшидә белән

Миңнисаның нәрсә турында сөйләшкәнен ишетеп торган Миңлегөл апа килеп чыкты. Сүзсез генә яннарына килеп, Миңнисаны җитәкләп алды. Көтелмәгән хәлдән югалып калган Рәшидәне капка төбендә калдырып, кызын өстерәп диярлек, тиз-тиз адымнар белән өйгә керен тә китте...

* * *

Миңлегөл апа җайлап кына ире янәшәсенә килеп утырды да сүзне ничек башларга икән дип баш ватарга тотынды. Хатынын нәрсәдер борчыганын Сабир абый да сизеп алды, күрәсең. Чәй салынган чокырыннан күзен алмыйча гына:

— Нәрсә, әнисе, бер-бер борчуың бар мәллә? — дип сорады.

— Әтисе, — диде, ниһаять, Миңлегөл апа, бераз кыюлыгын туплап. — Кызыбыз турында сөйләшеп аласы иде бит.

Сабир абый кырыс карашын хатыны тарафына борды:

— Кайсысын әйтәсең? Монысынмы? — Әле дә булса башын аска иеп ишек катында басып торучы Миңлисага ишарәләде. — Нәрсә булган тагын?

— Сизмисеңмени, кызыбыз үсеп җитте. Башлы-күзле итәр вакыт җиттмәдеме, дим, — дип, турыдан ярып салды Миңлегөл апа.

Гаилә башлыгы, сүзнең кай тарафка борылачагын әлегә күзалламый иде булса кирәк, көлемсерәп кенә куйды.

— Һе, монысы инде яшьләрнең үз эше. Алар язмышын без хәл итә алмыйбыз, әнисе, — диде Сабир абый һәм кинәт җитдиләнеп калды. — Нәрсә, әллә берәр сүз әйттеме?

Миңлегөл апа дәшмәде. Ире, урындыгыннан торып, аның каршысына ук килеп басты.

— Ну сезне! Сөйләшкәнсез, сизеп торам. Нәрсә ди инде? Егетем бар, диме?

— Бар, ди шул. — Миңлегөл апа авызын яулык чите белән каплады да карашын читкә күчерде.

Сабир абыйның йөзенә ачулы кыяфәт керде, хатынының иңнәреннән кысып тотты да, ялгыш эшләгәнен аңлап, икенче мизгелдә үк кулларын алды.

— Сөйлә! — диде ул, тавышын көчәйтә төшеп. — Мин нәрсәне белми калдым? Бер-бер хәл булганмыни?

Миңлегөл апа да иренә усал итеп карап куйды:

— Китсәнә, нәрсә сөйлисең син? Тәүбә, диген, Аллаһ сакласын! Шөкер, кызыбыз белән берни дә булмаган, тик...

Сабир абыйның түземлеге бетте. Ишекле-түрле йөрергә тотынды.

— Ну сөйлә инде, әнисе, газаплама!

— Сабирҗан, — диде Миннегөл апа, иренең күзләренә туп-туры карап. — Утыр әле, тынычлан.

Сабир абый теләр-теләмәс кенә урындыгына килеп утырды.

— Миңнисабыз Харис исемле егет белән йөри икән.

— Ничек?! — Сабир абыйның күзләре түгәрәкләнде. — Коммун Харисны әйтмисеңдер, шәт?!

— Соң... шул инде... Бер караганда, уйлап-уйлап куям да...

Сабир абый кабат урыныннан кузгалды.

— Әнисе, син әйтәсеңме моны?! — Хуҗаның йөзендә гаҗәпсену билгеләре чагылды. — Син, мөслимә башың белән... Юк, ризалыгым юк! Бетте!..

— Туктале, әтисе, кешене алай гына бәяләмиләр бит инде...

— Уйлап-уйлап куя, имеш, — дип бүлдерде Миңлегөл апаны ире. — Уйлармын мин сезгә! Кяферләр нәселе белән генә туганлашасы калган инде хәзер... Йа Ходай, ахырзаманнарга да килеп җиттекмени, хәерле булсын... Ишетсен колагыгыз: башка бу турыда бер авыз сүз чыкмасын!

Сабир абый, сүз тәмам дигән кыяфәттә кырт борылып, ишегалдына ук чыгып китте...

* * *

Кичке эңгер-меңгер зәңгәр күктә йөзгән кояшны тау ягының югары очында дулкын-дулкын булып яткан калкулыклар артына яшерде. Акрын гына моңланып, сандугач җыр сузып җибәрде. Кайдадыр ерак түгел генә күке, кемгәдер озын гомер теләп, бик озак итеп еллар санады. Елга буе үзәне, сихри әкият кебек җанланып, үзенә дәшеп тора иде. Су буеның иң матур җиренә төшә торган сукмак борма-борма булып югары очтан ук килә...

Харис Миңнисаның шушы сукмак буйлап киләчәген белә. Моңа кадәр дә шушында каршы ала иде ул сөйгәнен. Ул аны көндәгечә, күзен алмыйча көтте, ә Миңниса һаман күренмәде. Елга буендагы тал куаклары, бүген кызның күренмәвенә борчылгандай шаулашып, җил белән серләшеп алдылар.

Инде эңгер-меңгерне язгы караңгылык та күмеп бара. Харис тынычлыгын югалтты, әмма көтәргә булды. Ул бүген Миңнисага тәкъдим ясаячак...

Төн уртасы якынлашып килә. Миңниса һаман күренмәде... Бу хәл берничә көн кабатланды инде. Кыз инде алтынчы көнен су буена төшми. Югалды, ни кичке уенга чыкмый, ни су буена.

Көннәр акрын гына көзгә авышты. Август ае гына булуга карамастан, яшел әкият дөньясы төсен җуя башлады. Бөтен җиргә моңсулык инде. Камышлар һәм таллар арасында да, өметне өзәргә дигән сыман, сары төстәге киемнәрен киярга ашыгучылар күренә...

Сагышларга түзәр әмәл юк. «Нишләп очрашуга килми соң Миңниса? Берәр ярамаган, тузга язмаган нәрсә әйтеп үпкәләттемме? Нинди хата ясадым?»

Бер күрүдә гашыйк булган сөйгәнен озак вакыт күрми торудан гаҗиз булган Харисның күңелен бары тик шушы сораулар газаплады. Түземлеге тәмам чиктән ашкач, тәвәккәлләргә булды егет — катгый карарга килеп, Миңнисалар йортына таба юл тотты...

Таныш капка янына килеп җитүгә, күңел түрендә ниндидер тартыну, каушау кебек хисләр баш калкытса да, егет, адымнарын әкренәйтмичә, ишегалдына атлады.

— Бах-бах! Ур-ра, мин җиңдем...

Харис, тавыш иясен эзләп, як-ягына карады. Шулчак, бакча коймасы артында агач мылтыклы малай белән кызчыкны күргәч, үзалдына елмаеп куйды. Булачак каениш белән балдыз! Бер-берсе белән атышлы уйнаулары. Балалар, Харисны күреп, тынып калдылар.

Малай, чаяланып:

— Әти өйдә юк, балыкка китте! — диде һәм борынын мышкылдатып алды.

— Әниегез өйдәме соң? — Харис инде бераз кыюланып китеп янәшәсенә үк килеп баскан нәниләр янына чүгәләде.

— Әни дә юк. Суга китте.

Малай бакча капкасыннан кереп китеп юк булды.

— Сеңелкәш, ә Миңниса апаң...

Кыз, егетне моңарчы да күргәләгәне булгач, аның нәрсә әйтергә теләгәнен сүзсез дә аңлый иде, шуңа күрә ахырына чаклы тыңлап торуны кирәк тапмады:

— Хәзер чакырам, — диде дә, аягындагы кәвешен әллә кайларга чөеп, өйгә кереп китте.

— Нишләп йөрисең монда? — Бу сүзләрне тешләрен кысып, ачулангандай әйтергә тырышса да, Миңнисаның бит алмалары егетне күрүгә чиксез шат икәнлеген сатып тора — чөгендер кебек кызарып чыкты.

— Сине алып китәргә килдем.

Харис, елмаеп, сөйгәненә таба бер адым ясады.

— Кит моннан, кеше күрсен тагын... Көпә-көндез... — Миңниса читкә тайпылды.

Егет арткарак чигенде дә кулларын чалбар кесәсенә яшерде.

— Нигә очрашуга килмисең? Су буена да күптән төшкәнең юк.

Миңнисаның бит алмалары элеккедән дә ныграк кызарды. Харисның сорауларына җавап кайтармыйча гына, карашын җиргә, аяк очына күчерде. Бераздан егетнең күзләренә текәлде. Харисның йөрәген ялкын өтеп алды. Кызның очкын чәчеп торган күзләренә, кызарып пешкән чиядәй иреннәренә, алсу бит алмалары тудырган илаһи гүзәллеккә гашыйк егет тыныч кына карый алырлык түгел иде шул.

— Харис, берүк үпкәләмә инде...

Ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, Харис кызның сүзләрендә нинди тирән мәгънә ятуын йөрәге белән тойды. Шул мизгелдә аны алыштырып куйдылар диярсең — усаллыгы йөзенә чыкты.

— Тә-ә-әк, — дип сузды «кияү егете», үзенең нык кына үпкәләгәнлеген яшереп тормастан. — Аңлавымча, бүтән килеп йөрмәскә кушуың инде, ә?

Миңнисаның күзләреннән яшь бәреп чыкты.

— Әти рөхсәт итми...

— Нәрсә ул, минем комсомолец икәнне белми мәллә?

— Менә шуның өчен каршы да инде.

— Аһ... кулак калдыгы...

Нәфрәте артканнан-арта барган Харис, әкренләп, үз-үзен белештермәс дәрәҗәгә якынлашып килә иде. Йөзе угыз сөте кебек аксылсаргылт төскә керде. Күзеннән нур качты. Нишләргә белмичә шактый гына торганнан соң, ниһаять, бөтенләй зиһенен җуя барган Харис, аты-юлы белән сүгенеп, соңгы сүзләрен кабатлады:

— Кулак калдыгы!..

Авылда бер генә кеше дә бу очрашуга, гомумән, ике арадагы мөнәсәбәткә шушылай нокта куелыр дип фаразламаган иде. Баштарак соңгы очрашу вакытында Миңнисага әйткән пычрак сүзләре, котырып кайтып китүе өчен үз-үзен битәрләп йөргән булса да, көннәрдән бер көнне кызның үз капка төпләрендә ниндидер егет белән көлешә-көлешә сөйләшеп утыруларын күргәч, ачуы тагын да ныграк кабара төште.

Ике көннән Миңниса белән гәпләшеп утырган әлеге күрше егетен — мөәзин Зәки малае Мөнирне — югары оч малайлары кыйнап, аякларын имгәттеләр, тагын бер атнадан өйләренә тенту белән килеп, Зәкине каядыр алып киттеләр. «Халыкны колхозга, Советка каршы котыртып яткан булган. Авыл советы рәисе Гали белән коммун Харис сизеп алган» дигән сүз таралды халык арасында.

Байларга, мул тормыш белән гомер кичерүче кешеләргә карата нәфрәт белән караса да, Харис авылдашының кулга алынуын, ниндидер газапларга таруын теләми иде. Шуңа күрә үзе

турында гайбәт тараткан кешеләргә бик нык үпкәләде. Ә бүген...

## 4

Бүген авыл советы рәисе тагын шул турыда сүз алып бара. Харисны авылдашларына яла ягарга өнди. Сабир абыйга!..

Харис уйга чумды. Бер караганда, дин тотмавын, комсомолец булуын сылтау итеп, Миңнисаны аннан биздергән, күпме генә үгетләп карасалар да, колхоз эшенә чыгудан баш тарткан Сабир абыйдан үч алу өчен менә дигән мөмкинлек иде бу.

«Беренче мәхәббәтеңә аяк чалучы кешене кичереп буламы? Икенче яктан караганда, әгәр хәзер балыкчы Сабирны сөргенгә җибәрсәләр, Миңниса, аның туганнары нишләр? Аларның ни гаебе бар? Миңнисаның күзенә ничек күренермен?.. Бирмәсәләр ни, ул бит барыбер минем беренче мәхәббәтем! Ата-анасының кирелеге аркасында гына миннән читләшергә мәҗбүр булды... Гали абый белән дә араны салкынайтмавың хәерлерәк. Нишләргә?..»

Харис ике ут арасында калды.

— Гали абый, берүк ачуланма, миңа уйларга кирәк, — диюдән ары уза алмады ул.

Ике арада булган әлеге сөйләшү Хариска төн буена тынгылык бирмәде. Авыл советы рәисенең тәкъдиме күңелне кытыкларлык та шул. Авыл халкы арасында беренчеләрдән комсомол сафына баскан, беренче тракторчы булып эшләгән егеткә һәркайда да алдынгы, башкалардан бер башка өстенрәк тору өчен җае да чыкты шикелле...

«Әллә соң шул кулак калдыгын, чынлап та, җәһәннәмгә олактырыргамы? — дигән уй бер

генә килмәде анын башына. — Шунысы да бар бит әле: мин ул шикаятькә кул куймасам, рәис башка берәүне күндерергә дә күп сорамас. Көтәрсең аннары Гали абыйдан игелек! Сабир абыйны, бер уена кергән икән, барыбер Себергә олактырачак инде. Ул чакта нәрсә? Ул чакта үзеңне дә, кулакларны яклаган өчен... Юк, юк! Булдыра алмыйм. Миңнисаны барыбер яратам бит мин. Ничек мин аңа авырлык китерим ди?! Ә бәлки... кире уйлар Сабир абый? Бәлки, сөйләшеп карарга дыр?..»

Харис, таң беленер-беленмәс, Миңнисалар яши торган урамга юнәлде.

«Миңниса сүзе Миңнисаныкы, әтисе үзе әйтсен, аңлатсын!»

Бик вакытлы килеп җитте — Сабир абый ятьмәләрен күтәреп чыгып китәргә җыенган иде инде.

Коммун Харис кушаматлы егетнең сорамый-нитми генә үз ишегалдына килеп керүен күреп, Сабир абый, ни әйтергә дә белмичә, берара тын гына басып торды. Балыкчы үз эше белән китеп барса, сөйләшә алмый калачаклар. Шуны яхшы аңлап, Харис беренче булып сүз катты.

— Сабир абый, минем хакта әллә ниләр сөйләгәнсең икән. Шулай да аңлашып аласы иде әзрәк.

Хуҗаның егет белән юкны бушка аударып утырырга теләге дә, вакыты да юклыгы йөзенә чыккан — җавапка берни дә әйтмәде, ятьмәләрен култык астына кыстырып, капкага таба юнәлде.

— Сабир абый, дим. — Харис хуҗаның юлына аркылы төште. — Тыңла инде. Җитди мәсьәлә буенча килдем.

Егетнең сүзләре әллә ни кызыксыну уятмаса

да, Сабир абый туктальп калды. Ятьмәләрен җиргә куйды, бер кулы белән биленә таянды.

— Йә?!

— Сабир абый, Миңниса...

Хуҗа Харисны шундук бүлдерде:

— Ул мәсьәләдә сөйләшергә уйласаң, маташма да, энем. Мин үз сүземне әйттем. Дөрес сөйлиләр: нәкъ шулай дидем, денсезләргә бирергә дип кыз үстермәдем!

Харис, эчен хәшәрәтләр кимерсә дә, Сабир абыйның әйтеп бетергәнен көтте.

— Шуны аңла, Сабир абый, — диде ул, үзен көчкә тыеп. — Хәзер патша заманы түгел. Бер-берсен яраткан кешеләр тормышына кысылырга синең хакың юк!

Егетнең тавышы көчәйгәннән-көчәя барды. Кычкырып җибәргәнен дә абайламый калды.

— Комсомолец кеше түгел мәллә синең өчен?

Сабир абый:

— Ник кеше өенә килеп акырасың әле син, малай актыгы?! Тыңлап торган булам тагын үзен, — диде, тыныч булырга тырышып.

Сабир абый, артына да борылып карамыйча, күлгә таба китеп барды.

Харис бу минутта үзен-үзе кая куярга да белмәде. Йодрыкларын йомарлады, балыкчының артыннан йөгерергә дип талпынып куйды. Тик аяклары аны тыңламады. Егет ике генә адым атлады да балавызга ябышкандай катып калды. Инде инеш буйлап күлгә якынлашып килүче Сабир абыйны Харисның теш арасыннан кысып чыгарган «Контра!» дигән сүзе генә куа китте...

* * *

— Гали абый, керергә буламы? — Харис авыл советы рәисе бүлмәсенә атылып килеп керде.

Чакыруны да көтеп тормастан, өстәл янына килеп утырды.

Рәис, Харисның нинди йомыш белән йөргәнлеген чамалаганга күрә, канәгать елмаеп куйды.

— Нәрсә, энекәш, сөйлә, уйладыңмы?

Җитәкченең боерыклы тавышы үзенекен эшләп өлгерде — Харисның кергәндәге кызулыгыннан җилләр исте. Кыюсыз гына сүз башлады:

— Кичәге сөйләшүне әйтәм... Чын нәрсәме ул?

— Минем сине алдаганым бар мәллә? — дип кенә куйды рәис.

— Юк, алай димим... — Ялгыш сүз ычкындырмагаем тагын дигәндәй, егет каушап калды. Имән бармагы белән өскә таба ишарәләде. — Сине тегендә алган очракта, бу урын миңа калу, чынлап та, булырдай нәрсәме, диюем, Гали абый?!

— Анда эш тормаячак, сүз бирәм, энекәш. Теләсәң — бу урын, теләсәң — колхоз рәисе. Тик, беренче чиратта, хәзер үк гариза яз — син инде җитлеккән, партиягә тәкъдим итәбез. Аннан соң, үзең беләсең, озакка сузмыйча гына бер эшне башкарып ташлыйсы бар.

— Сабирны әйтәсеңме?

Гали абый Хариска таба иелә төште.

— Сабир... һәм колхоз рәисе турында...

Харис сагаеп калды.

— Анысына ни булган тагын?

Авыл советы рәисенең җавабы егетне бөтенләй аптыраштa калдырды:

— Фоат синең үзеңә комачау булачак! Вакытында котылырга кирәк... Курыкма, энекәш, законсыз нәрсә эшләмибез, форсаттан файдаланып калырга тырыш. Мин сиңа бер документ

күрсәтәм. — Авыл советы рәисе аның алдына бер бит кәгазь куйды. — Укы!

Кәгазьнең өске бер почмагына «Татарстан АССР Эчке эшләр Халык комиссарына» дип язылган иде. Харис эшнең нидә икәнлеген шундук аңлап алды. Карашы үзеннән-үзе язуның аскы өлешенә шуды. Имза куелмаган. Курка-курка гына хатның эчтәлеге белән танышырга кереште.

*«...Террор кулланып, алдап һәм экономик яктан басым ясап, председатель Фоат авылдагы властьны тулысынча үз кулына алды. Озак вакыт шулай диктаторлык итте. Ярлыларны, карт-корыны кыйнап эшләтте, гаиләләргә тиешле пособиеләрне беркайчан да тулысынча бирмәде, ялган документлар тарату белән шөгыльләнде. Кешеләрне эксплуатацияләү, төрле ришвәтләр алу исәбенә үзенең кулак хуҗалыгын торгызды. Закировның Гражданнар сугышы елларында кызыллардан качып урманда йөргәнен, аклар белән ныклы элемтәдә булганын да белүчеләр бар... Гомумән, колхоз рәисе булып эшләгән чорда да совет власте үткәргән барлык чараларга каршы эш алып барды, үзе, белемле кеше буларак, гади халыкны төрлечә мәсхәрә итеп яшәде һәм яши...»*

Харис үз күзләренә ышанмыйча утырды. Авылдашларының берсе язган бит шушындый «хат»ны! Яшь кенә булса да, үзен бригадир итеп куйган колхоз рәисенең «халык дошманы» булуына күңеле ышанмады. Аның икеләнеп калуын Гали абый да сизде.

— Син, энекәш, шикләнмә, бу хатта йөз процент дөреслек дияргә була. Теләсәң, тагын әллә ниләр сөйләп бирә алам.

Харис күз кырые белән генә авыл советы

рәисен күзәтте. «Димәк, бу моны үзе язган булып чыга инде!» дигән уй йөгереп узды башыннан.

— Фоат абыеңның егерме алтынчы елда сыерын яшереп асравы хакмы? — Гали абыйның күзләреннән очкыннар чәчри иде. — Хак! Ачлык елында аның рөхсәтеннән башка солы тарттырган өчен тегермәнче Гатаны кыйнаганлыгы, утызынчы елда мал-мөлкәтләрне җәмгыятьнеке итү өчен Мамадыштан вәкил килгәч, берничә кешене ияртеп китеп, бу чарага каршы тавыш бирергә өндәве хакмы? Ул елны колхоз рәисе иде инде ул. Икмәк әзерләү кампаниясе вакытында «Хөкүмәт икмәкне чит илгә җибәрә... Ярлыларны күпме генә ашатсаң да, хәл үзгәрмәс, чөнки ялкаулар бит алар», — дип әйткәнен үзем ишеттем. Шушы агитациясе нәтиҗәсендә икмәк әзерләү планы үтәлми калган иде...

«Әллә нинди замана җитте... Ышанмыйм. Моңа кадәр тәртипле генә, тырышып эшләп йөргән кешеләрнең «халык дошманы» булуларына ничек ышанасың инде?! Шулкадәр үк начар кеше микәнни соң бу Фоат абый да? Чыбык очы гына булса да, туган тиешле бит әле ул безгә. Авыл советы рәисе үзе сөйләп утырса да...»

Хариска эссele-суыклы булып китте, тәне куырылып, калтыранып куйды. Рөхсәт сорап, Гали абый өстәлендәге графиннан салкын су салып эчте. Ә рәис өстәл тартмасыннан тагын бер кәгазь тартып чыгарды һәм, шуңа карап, сөйләвен дәвам итте:

— Мең тугыз йөз егерме сигезенче елда, яшергән икмәкләрен табарга ярдәм иткән өчен, кулак Фоат Закиров туганнан туган абыйсын батырып үтермәкче булган... Гомумән, мондый контраны ничек колхоз рәисе итеп куйганнардыр, акылыма сыймый. Ул бит совет власте

крестьяннарны дөрес юлдан, Ленин юлыннан алып бармый дип исәпли. «Совет власте дөрес юлдан китмәде, тиздән алышыначак, чөнки ул ялкауларны гына яклый, ә калган крестьяннарны газаплый», — дип сөйләп утыра беркөнне. Дистәләгән кеше алдында! Ярлы халык арасындагы хезмәт активлыгын аның шушы котыртулары төшерде дә инде...

Ниһаять, Гали тынып калды, карашы янында утыручы бригадир егеткә беректе. Харис ни әйтергә дә белмәде. Саклык белән генә сорап куйды:

— Сабир абый турында да шушындый документлар бармы?

— Бар шул! — Авыл советы рәисе янә ярым пышылдауга күчте: — *Менә тыңла: «Якупов Сабир озак еллар буена советка каршы агитация алып бара. Беркөнне генә колхозчылар алдында колхозны таркату турында агитация ясады. «Колхозда биш йөз грамм икмәк өчен ахмаклар гына эшли. Колхоздан чыгып, производствога керсәгез яки, һичьюгы, минем белән балыкка йөрсәгез яхшырак булыр, гаиләләрегез ач утырмас», — диде. Бер колхозчыга шулай ук: «Колхозчылар шул мескен граммнар өчен эшлиләр, ә үзләре ач утыралар», — дигән. Узган ел авыл халкының күмәк җыелышында шул ук сүзләрне диярлек кабатлады: «Колхозчылар көне-төне эшлиләр, ач яшиләр, хөкүмәт ярдәм итми. Шулай булгач, ниемә кирәк ул колхоз дигәннәре. Ул берние белән дә яхшы түгел, аерым хуҗалыкчылар, ичмасам, рәхәтләнеп ипи ашыйлар, куас эчәләр», — дип сөйләде. Нигә андый «халык дошманнары»н иректә йөртәләр икән?!» Бу хатны да үзебезнең авыл кешесе язган! Озын сүзнең кыскасы, синең «бабай»ның да биографиясе билгеле...*

Рәис шаркылдап көлеп җибәрде. Харисның йөзе чөгендер кебек кызарды...

— Йә, нәрсә, энекәш, кул куясыңмы?

Дөресен генә әйткәндә, Харисның рәис «тәкъдимен» хупламый чарасы юк иде. Дәрәҗәле җитәкче сүзләренә ышанмаска мөмкин димени?! Чын-чынлап, башын югалтыр дәрәҗәгә җитеп гашыйк булган комсомол егет үзен бөтен авыл каршында рисвай иткән балыкчы Сабирдан үч алырга карар кылды...

## 5

Харис, ике урам чатындагы багана төбенә, ялгыз бүрәнәгә чүгәләп, тәмәке кабызды. Тирән итеп бер суырды да, күзләрен йомып, үзенең бүгенге халәте турында уйларга чумды.

«Их Хәмит, Хәмит! Хаклы булгансың инде әллә?..»

— Кызганам мин сине, энем.

Көтелмәгән хәлдән Харис сискәнеп китте, тәмәке төтененә тончыгып, буыла-буыла йөткерергә тотынды. Кайдан килеп чыккандыр, янәшәсендә әле генә баш миенә кереп урнашкан Хәмит елмаеп тора иде. Харис аның унбиш ел элеккечә кыяфәттә булуына, төскә-биткә һаман да үзгәрмәгәнлегенә шаккатты. Әллә өстендәге киеме дә шул ук инде...

— Син дә исәнмени әле, Хәмит? — диде Харис, йөзенә битараф төс чыгарырга тырышып. — Һаман акыл сатып йөрисеңме?

Хәмит аның сүзләрен әллә ишетте, әллә юк — үз сүзен дәвам итте:

— Шулай, әйттем бит мин сиңа теге вакытта. Мине тыңлаган булсаң, йөрмәс идең олыгаеп килгән мәлеңдә болай тинтерәп, зимагур булып...

Харис бу сүзләрдән сагаеп калды. Хәтерли, бик яхшы хәтерли Харис ул сөйләшүне. Сугыштан яраланып кайткан көн турында әйтүе...

Сугыштан кырык дүртнең көзендә кайтты ул...

...Фашистларны куа барып, ил читенә җиткәннәр иде инде. Көтелмәгән хәл килеп чыкты. Партизаннардан өрәктән курыккандай шүрләп килгән немецлар моңа кадәр тау-ташлы урыннарны, урман-болыннарны читләтеп үтү ягын карыйлар иде. Ә бу юлы, чарасызлыктандыр инде, Белоруссиянең очсыз-кырыйсыз урманына кереп юк булдылар. Әлегә тавыш-тыннары ишетелмәсә дә, нинди мәкер корып, хәл җыеп ятулары көн кебек ачык. Аларны, һичшиксез, ачык кырга куып чыгарырга кирәк. Бу эшкә атлы кавалерияне кулай таптылар.

— Нәрсә, егетләр, тәвәккәллибезме? — диде Харис, штабтан кайтып төшкәч. — Командование безнең һөҗүмне көтә.

Сугышка кергәннең беренче көненнән бирле фашистларны бергә дөмбәсләгән взвод солдатлары арасында, нинди гайре табигый көчләр ярдәме белән диярсең, бүгенге бәрелешкә кадәр хәтта яралланучылар да булмады. Шуңа күрә штабта утыручылар арасында аларга кырын караучылар да юк түгел иде. Атака вакытларында блиндажда, окопта качып утыралардыр, дигән сүзләргә кадәр ишетелде.

— Безне почти дезертирларга санныйлар, күрсәтик әле кемлегебезне. По коням! — Харис, сикереп торып, атына атланды. Шуны гына көтеп торганнар диярсең, урман ягында немец автоматлары тыкылдый башлады. Харис үкчәсе белән атның корсагына типте. Ат, арт аякларына басып, тартылып куйды. Взвод команди-

ры, кылыч тоткан сул кулын күтәреп, гадәттәгечә: «Алга!» — дип кычкырмакчы иде, өлгерми калды. Култык астын нәрсәдер куырып алды. Сул як күкрәге авыртуга түзә алмыйча, Харис атыннан мәтәлеп төште. Башы янәшәдә яткан зур гына ташка бәрелде. Күз аллары караңгылана башлады. Бар булган көчен туплап торып утырды да, ярым пышылдап кына булса да, команда бирде:

— Алга!..

Харисның взводы, «Ура!» кычкырып, дошман өстенә ябырылды. Ирнең күз алдыннан туганнары, балалары йөгерешеп узды. Озын керфекләрен челт-мелт йомгалап, каш астыннан гына оялып карап торучы зәңгәр күзле украин кызының сылу буй-сыны күренеп киткәндәй булды. Тагын берничә мизгелдән командир аңын җуйды...

Ул уянганда, бүлмә эче яп-якты иде. Зур тәрәзәдән кергән кояш нурлары Харисның күзләрен сукырайткан кебек булды. Озак кына учлары белән угалап торганнан соң, ниһаять, күзләре яктылыкка ияләшкәндәй итте, егет тирә-юньне күзәтергә кереште.

«Тукта, нинди җир соң әле бу? Ничек килеп эләктем мин монда? Әле генә сугыш кырында идем бугай бит... — Азаплана торгач, Харис үзенең аттан мәтәлеп төшүен исенә төшерде. — Ак түшәм, стеналар. Димәк, мин лазаретта?..»

Хәрәкәтсез байтак ятылган, күрәсең, аркаларга хәтле оеган. Харис, икенче яккарак борылып ятарга ниятләп, кулын кымшаткан иде, күкрәге авыртуга түзә алмыйча акырып җибәрде. Кабат аңын җуя баруын сизде.

Ул да булмады, йөгереп диярлек, янына апак халат кигән шәфкать туташы килеп җитте. Үзалдына сөйләнгәндәй, борын астын-

нан гына нәрсәдер мыгырданып, кулындагы чүпрәкне Харисның борынына якын китереп алды. Нашатырь спирты исеннән егетнең сулышы кысылды. Йөткерәм дип нык кына киерелгән иде, күкрәге кабат чыдап булмаслык авырта башлады. Ничек итсә итте, йөткерү теләген басарга туры килде егеткә. Тын алуы җиңеләя төшкәч, ялварулы күзләрен янында басып торучы хур кызына төбәде.

— Әһә, безнең герой да аңына килде, ниһаять, — диде кыз, елмаеп, шприцка озын гына энә беркеткән арада. — Бу дөньяга бер кайткач, кире җибәрдем юк инде сине...

— Сеңлем, мин кайда? — Кыз укол кадаганнан соң, Харисның тәненә бераз хәл кергәндәй булып китте. — Яра җитдиме?

Шәфкать туташы шприцын, спирт салынган шешәсен яңадан кечкенә тартмасына урнаштырды да, елмаеп:

— Син госпитальдә, абыем... — диде дә, авызындагы бөтен тешләрен күрсәтеп көлеп җибәрде. — Дөресен әйткәндә, исән калырсың дип уйламаган идек инде.

Харисның күңелен курку биләп алды. Бераздан үз-үзен кулга алды.

— Нәрсә булган соң минем белән?

Шәфкать туташы, тартмасын читкә куеп, Харис янәшәсенә утырды.

— Пуля, култык астыннан кереп, аздан гына йөрәгеңә барып җитми калган... Бер сантиметр... Бөтенесен дә белмим белүен, операциядә катнашмадым. Мин белгәне шул — операция бик уңышлы булмаган, диделәр, йөрәккә якын булгач, пуляны ала алмаганнар...

Госпитальдә бер айга якын ятарга туры килде Хариска. Аягына басып йөри башлагач, сулыш алулары иркенәйгәч, кабат фронтка җи-

бәрүләрен күпме генә үтенсә дә, аны, батырлыгы өчен берничә орден, медаль белән бүләкләнгән кавалеристны, сугышка яраксыз дип, туган якларына кайтарып җибәрделәр.

Кайтуын алдан хәбәр итеп тормады. Поезд төн караңгылыгында Кукмара станциясендә тукталгач, берни уйламастан перронга сикерде. Тик хәзер кая барырга? Сугышка кадәр Кукмарада булгаласа да, вокзал тирәләре белән бик үк таныш түгел иде ул...

Биштәреннән тәмәке янчыгы чыгарып, койма буена чүгәләде. Кесәсен кат-кат капшап караганнан соң, җирдә аунап ятучы бер газетаны иелеп алды да, аны тураклап, бер кисәге белән махра төрде, калган өлешләрен кесәсенә тыкты. Төрелгән «кәҗә мөгезе» төбенә кадәр янып беткәч кенә, төн уртасы җитүгә карамастан, капка төпләрендә гәп корып утыручы бала-чагадан Мамадышка бара торган юлны сорап, ашыкмый гына шул якка таба атлады. «Авылга җитмеш чакрым тирәсе. Юл уңаена берәр техника булса, ике-өч сәгатьтән кайтып җитәргә булыр иде дә, — дип уйлап куйды ул. — Их, тизрәк балаларымны күрергә... Бер караганда, фронтка яңадан җибәрмәүләре яхшырактыр да әле. Безнекеләр әнә фашистны инде Польшага ук куып чыгарганнар. Болай барса, тиздән өннәрен үк туздырып атачаклар...»

* * *

Таң алдыннан авыл капкасыннан килеп кергән Харисны беренче күрүче яшен бер кеше дә төгәл генә белми торган Хәмит булды.

— О! Син дә исәнмени әле, зимагур? — дип каршы алды ул түшен орден-медальләр бизәгән Харисны.

Харис авылдашын таныды. Үзен белә-белгәннән бирле шушы кыяфәттә хәтерли ул Хәмитне. Авыл читендәге беренче каралтының капка төбендәге эскәмиягә барып утырды, Хәмитне янына чакырды. Тегесе килеп җиткәч, дусларча кочаклап алды.

— Авылда хәлләр ничегрәк, яшәп буламы?

Хәмит, күзен кыса төшеп, тозлап-борычлап нидер әйтергә җыенгандай авызын ачып торды да, Харисның кочагыннан арынып, читкәрәк китеп утырды.

— Син мине кыйнадың, — диде ул, ниһаять, авызын очлайта төшеп, авылдашының күзләренә карамыйча гына.

Алты ел чамасы элек булып узган вакыйгалар бер мизгелгә Харисның хәтерен тырмап үтте.

...Авыл халкын ничәмә-ничә ел буе куркытып та, үгетләп тә карадылар. Тик яшь хакимияткә карата беренче елларда халык күңелендә борынлый башлаган ышаныч, тормышның алда вәгъдә ителгәннән шактый ерак булуын, авыл кешеләренең тормыш-көнкүреше начарайганнан-начарая баруын аңлаган саен, көннән-көн бетә килде. Шуңа күрә инде диннән бизеп килүче халык, әһәмиятен аңлап бетермәсә дә, протест йөзеннән булса кирәк, авылның бердәнбер мәчетен сүттермәде.

Ул вакытта авыл советы рәисе вазифаларын башкаручы Харис ничек итсә итте — чираттагы гомум җыелышта мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Җәмәгать! Әйдәгез, турыдан-туры сөйләшик әле. Безнең бүгенгәчә хәл ителмәгән тагын бер әйберебез калды. Ул да булса — мәчет...

Зал тынып калды.

— Аңлыйсыз булыр, мәчетне сүтми торып, безгә көн күрсәтмәячәкләр, — дип дәвам итте Харис. — Йә, ник карышасыз? Дөресен әйтегез инде, үзегезгә дә кирәкми бит ул. Мине көн саен райкомда талкыйлар. Район күләмендә Түбән Ушмы белән безнең авылда гына мәчет тырпаеп тора.

Авыл советы рәисе, сөйләвеннән туктап, «Йә, кем нинди фикердә?» дигән сыман, авылдашларын күздән кичерде. Тик шундук үз фикерен ярып салырга ашыгучылар табылмады. Заманасы нинди икәнен берәүнең дә исенә төшереп тору кирәк түгел. Моңа кадәр бер-берсе өчен җан атар дәрәҗәдә якын булган, бер гаиләдәй иңгә-иң торып яшәгән булсалар да, бүген арада нинди адәмнәр пәйда булганлыгын бер Ходай үзе генә белә.

— Алай булгач, мәсьәлә...

Тик Харис җөмләсен тәмамларга өлгерми калды, авыл халкы бөтенләй көтмәгән хәл булды. Залның иң уртасында, карт әнисе янәшәсендә утырган Хәмит сикереп диярлек урыныннан торып басты да, түм-түгәрәк булып акайган күзләрен Харискa төбәп, тавышын күтәрмичә генә, ләкин бөтен кеше ишетерлек итеп ярып салды:

— Син, энем, ул мәчетне үзең төзеткән идең мәллә? Инде күпме гомер шапырынасың шуны «сүтик» дип. Башка эшең юктыр, билләhи. Комачаулыймыни соң ул сиңа?

Харис җавапны озак көттермәде:

— Комачаулый шул, Хәмит, комачаулый... — диде ул, инде шул арада соравын онытып өлгергән, әнисенең пәлтә сәдәбен боргаларга керешкән мәхлукка күз ташлап һәм борын астыннан гына мыгырданып алды: — Карале, тик кенә утыр әле син анда, кысылма, синнән

башка да проблемалар муеннан. — Харис янә залга күз йөртеп чыкты. — Йә, ник дәшмисез?

Авылдашларның башлары аска иелде. Хәмит кабат урыныннан торды. Тик бу юлы ул бер сүз дә әйтмәде, әкрен генә рәт араларыннан чыгып, сәхнә ягына, Харис утырган өстәл тарафына атлады.

— Гайшә әби, — дип кычкырды Харис Хәмитнең әнисенә. — Тый әле шушы мәхлугыңны, зинһар. Ачу килгән чак...

Ул арада сәхнә янына чыгып җиткән Хәмит залга таба борылып басты.

— Тыңламагыз моны, — диде ул тыныч кына, кулы белән авыл советы рәисе ягына ишарәләп. — Иблис коткысына бирелгән бу...

Авыл башлыгы була торып, Харис мондый мәсхәрәне күтәрә алмады — утырган урыныннан сикереп торып, Хәмиткә селтәнде. Әллә ни каты сукмаган кебек тоелса да, Хәмит сәхнәдән залга мәтәлеп төште. Харисның кызу канлы икәнлеген белеп-күреп яшәсәләр дә, көтелмәгән хәлдән залдагылар бер мәлгә югалып калдылар. Бераздан, Хәмит баш артын учы белән уа-уа идәннән күтәрелә башлагач кына, залда җанлану сизелә башлады. Әле бер, әле икенче почмактан, ниһаять, хисләрен ирекка җибәргән, Хәмит кебек Ходай бәндәсенә кул күтәрүдән дә чирканмаган Харисны эт итеп сүккән тавышлар ишетелде.

Ярамас эш эшләп ташлавын Харис та төшенде. Шулай да гафу үтенеп торуны кирәксенмәде.

— Кисәттем бит. Нигә һаман тыгыла ул?..

— Минем дә, улымның да каргышы, ләгънәте гомер буе озата барсын үзеңне, тфү!

Шушы сүзләр белән Гайшә әби, Хәмитне җитәкләп, клубтан чыгып китте...

Хәмит каш астыннан гына Хариска карап утыруын белде.

— Ярар инде, Хәмит, патша заманында булган нәрсәләрне искә төшереп утырмасаң... Әйдә, көйрәтеп җибәр, ичмасам. — Харис, йөзен сакал-мыек баскан авылдашының күзләренә туптуры карап, елмайгандай итте.

— Бик беләсең килсә, мин сиңа абый кеше...

Хәмитнең бу сүзләрен ишеткәч, Харисның йөзе җитдиләнеп калды. Төбенә кадәр янып бетә язган «кәҗә мөгезе»н тәкергәләп сүндерде дә койма буенда үскән кычыткан арасына ташлады. Торып басты.

— Ярар инде, үпкәләмә, кечкенәдән шулай күнегелгән бит, беләсең...

— Синең урында булсам, бу авылга кабат аяк басарга да батырчылык итмәс идем мин. Син бу авыл өчен ят бәндә, энем.

Харис көтелмәгән сүзләрдән каушап китте. Аның уенча, сугышка кадәр авыл өчен байтак эшләр эшләгән, фронтта фашист илбасарларын дөмбәсләгән кешене, кем генә булмасын, болай каршы алырга тиеш түгел иде. Кәефе кырылды. Күзләрен акайтып, Хәмиткә дәште:

— Авызыңны үлчәп ач! Алты ел элек бер тапкыр сукканга үчләшеп утырмасаң... Таптың вакыт...

— Ул чагында минем хаклы булуымны соңрак үзең дә аңладың бугай аңлавын. Тик миңа караганда әнием ныграк рәнжеде, шуңа күрә сине кичерә алмыйм. Әнине рәнҗеткән өчен. Мине генә түгел, бөтен авылны җәберләдең бит син, имансыз, хәтерең тузаннарын сөрт...

Харисның хәтере әллә ни калын тузан астында калмаган. Авыл халкы белән күпме генә тарткалашсалар да, ахыр чиктә мәчетнең сүтелми калуын яхшы хәтерли. Изге йорт, манарасы тәмам череп ишелеп төшкәнче, авыл уртасында торды. Манара очындагы сары ай гына шул көннәрдә юк булды. «Аны Харис үзе менеп алган» дигән сүзләр дә йөрде авылда берара. Билгеле, чынлыкта, монда авыл советы рәисенең турыдан-туры катнашы юк иде. Ул кырыгынчы елны фин сугышына киткәндә идарә эшләрен башка берәүгә тапшырып йөргәндә генә ачыкланды — айны мәчет янәшәсендә яшәүче Зиннәт карт алып яшергән булып чыкты.

Авылдашларын җәберләүгә килгәндә, кемне дә булса тиргәгән, кайвакыт начар сүзләр ычкындыргалаган икән — каны кызган, ачу килгән чакта булгалагандыр инде дип кенә уйлады Харис. Ә болай... Кеше өлешенә кергәне, кемне дә булса кыйнаганы, Хәмиткә сукканнан соң хәтта бер генә адәми затка да кул күтәргәне булмады...

— Нәрсә бытылдыйсың син? Ник кәефне бозасың? Синең фәлсәфәңне тыңлап утырырга дип кайттыммыни мин фронттан?! Халыкны җәберләдең, дип, арттырып җибәрәсең, яла ягасың бит, Хәмит. Җавап бирергә туры килмәгәе.

Хәмитнең гаҗәпләнүе йөзенә чыкты.

— Син моны чынлап әйтәсеңме соң, энеем?! Куркытма син мине. Нәрсә син, кемне дә булса рәнҗетер өчен, аны кыйнау кирәктер дип уйлыйсың мәллә?

Харис, өч елдан артык җәһәннәм читендә дошманнарны дөмбәсләп, ниһаять, туган авылына аяк баскан ир, үзен беренче булып каршы

алган «ярты акыллы» Хәмитне һәм күңелсез хатирәләрне шушы урында калдырып китәргә теләгәндәй, кулын гына селтәде дә биштәрен җилкәсенә асты.

— Кайтыйм мин, — дип, олы урамга, туган йортына таба атлады...

* * *

Җилкапканы тавыш чыгармыйча гына ачып керде Харис. Аяк очларына басып дигәндәй өйалды баскычына килеп җиткән генә иде, ишек ачылып та китте, аннан Харисның олы улы — тугыз яшьлек Нурулла атылып чыкты. Әтисенең өй турына кайтып җиткәч тә керергә кыймыйча капка төбендә йөткерә-йөткерә тәмәке көйрәтеп торганын күргән икән.

Малай, «Ур-ра!» кычкырып, әтисенең муенына асылынды.

— Ур-ра, әтием кайтты! Герой әтием! — дип, әле бер кысып кочаклады Нурулла, әле Харисның орден-медальләрен тоткалап карады.

Еллар буе бер күрешергә, кочаклап иркәләргә тилмереп, чит җирләрдә зар-интизар булып яшәгән кеше өчен шул хыялларының тормышка ашуын нинди бәхет белән чагыштырып булыр икән?! Харисның күзләреннән шатлык яшьләре тәгәрәп чыкты.

Бу күренеш Нурулланы аптырашта калдырды.

— Бәтәч, әти, нигә елыйсың? Берәр җирең авыртамыни? — Харис җыерчыклар баскан бите буйлап тәгәрәшеп төшкән күз яшьләре чылатырга өлгергән мыегын сыпырып алды. Үзенең дә күзләре дымлана төште, сулышы ешайды.

— Юк, юк, улым. Авырмыйм мин. — Харис

улын тынычландырырга ашыкты. — Сине, шушындый дәү улымны күргән бәхеттән, күзгә черки кергәнен дә сизми калганмын.

Нурулланың йөзе тынычланып калды.

— Карале, чынлап та зур булгансың син, улым, каяле... — Харис улын җиргә бастырды. — Бүтәннәр өйдәме соң? Уяндылармы әле?

Нурулла баскыч бусагасына утырган әтисе янәшәсенә чүгәләде.

— Әни төнгелектән күптән түгел генә кайтты әле, бәбәйләр янына ятып йокыга китте бугай. Наташа апалар уянды инде...

— Нинди Наташа апа ул, улым? — диде Харис, сәерсенеп.

Сүзнең кем турында барганлыгын, ниһаять, Нурулла сөйли башлагач аңлады...

## 6

Атлы гаскәр авылга кергәндә, караңгы төшкән иде инде. Алдан чабулаучы җайдаклар, бормалы-сырмалы урамнарны үтеп, басуга чыгып җиткән генә иде, арттан эскадрон командирының боерулы тавышы яңгырады:

— Эскадрон, тукта! Төнне шушы авылда үткәрәбез.

Караңгы яңа гына төшсә дә, йорт тәрәзәләрендә яктылык-фәлән күренми. Тынлык. Хәрбиләрнең атлары гына ара-тирә пошкырып куя. Харисның взводы авыл читендәге, башкаларга караганда шактый иркен күренгән йортка таба юнәлде. Тик хуҗалар ишек шакыгач та җавап бирергә ашыкмадылар. Шактый вакыттан соң гына сукыр лампа кабыздылар булса кирәк, соры төстәге өленге белән капланган тәрәзәдә тонык кына яктылык күренеп китте.

Ишек артында хуҗа хатын тавышы ишетелде:

— Кем бар анда? — диде ул чиста урыс телендә.

— Бу без, апа, фронтка баручылар, — дип җавап кайтарды Харис. — Төнне кунып чыгарга иде.

Ишекнең эчке ягында тынлык урнашты. Берара басып торганнан соң, Харис кабат ишекне дөбердәтергә тотынды.

— Ач инде, фәлән-төгән!

Көне буе ат өстендә чапкан хәрбиләрне тизрәк ял иттерү чарасын күрергә кирәк иде. Шуңа күрә взвод командиры төче телләнеп тормады, урысчасын-татарчасын бергә кушып сүгенеп җибәрде.

Ишекне карт кына хатын ачты. Җилкапка янында атларын җитәкләп басып торучы кораллы ирләрне күреп каушап калды булса кирәк, хуҗабикә сүзсез калды. Аннары гына, хушына килеп, җайдакларны өйгә дәште.

— Сез безне ачуланмагыз инде, егетләр, ишекне дөбердәтә башлагач та, бандитлар дип куркып калдым. Андый-мондый хәл булса, кем яклар мине? Берүзем бит, берүзем... — Хуҗабикә сөйләнә-сөйләнә чәй хәстәрләргә керешә. — Картым элекке авыл советы председателе, бандитлар кыйнап киткәч, озак кына урын өстендә ятты, узган айда җан тәслим кылды... Ике балам белән бергәләп маташабыз инде шунда...

Сугыш чорында Украинада гына түгел, хәтта Татарстанның үзендә дә җинаятьчелекнең үсүен яхшы белгәнгә, Харис бу гаилә өчен аеруча авыр хатирәләр турында сүз куертып торуны кирәк тапмады.

Өстәлгә сызгырып торган самавыр, нинди-

дер тоның сыеклык тутырылган зур шешә, кирпеч кадәрле ысланган чучка мае менеп кунаклады. Егетләр, күзләрен ялтыратып, берберсенә карашып алдылар.

— Сыйланыгыз, егетләр, сыйланыгыз. Бар булганы шул инде...

Хуҗабикә өстәлгә кырлы стаканнар чыгарып куйды.

— Мин балалар янына кереп чыгыйм әле...

Ул балалары йоклап яткан якка кереп киткәнне көтеп кенә торгандай, егетләр өстәлнең нәкъ уртасына куелган алагаем зур шешәдәге данлыклы украин горилкасына «һөҗүм» башладылар. Аларның кыйланмышларын карап тору Хариска кызык тоелды: егетләр кырлы стаканны тутырып утлы суны бер сулышта йотып куялар да иписез-нисез чучка мае кабалар. Ул йөзләрендәге канәгатьлек!

— Командир, әйдә берне генә булса да тотып куегыз инде. Юкса безгә читен бит.

— Юк, юк, егетләр, рәхмәт. Мин озак еллар сугышканнан соң мондый дошманны бер җиңдем инде. Сез дә чамалагыз, иртүк атка атланасыгыз бар.

Взвод командиры, егетләрнең ашына таракан булып төшмәс өчен, урыныннан торып, йорт эчен караштырырга кереште.

Хуҗабикә озак тормады. Мич аралыгыннан чыгып, хәрбиләр янына килеп утырды.

— Борчыдык инде сезне, ачуланмагыз, апа. Йокыгызны бүлдек...

— Кая инде ул йокы... Бераз хәл алыйк дип кенә яткан идек инде. Иртүк торып җыенырга кирәк бит. Безне ил эченәрәк күчерәчәкләр... Анда безне кем көтеп торган ди тагын. Бездән башка борчулары булмаган ди... Туган-тумачаларыбыз да юк бит, ичмасам, шуларга гына

күченеп торып идек тә... Туган җирне ташлап китүләре авыр икән лә ул. Мондый хәл килеп чыгар дип кем уйлаган бит. Әти-әниебезгә туган туфракны ташлап беркая да китмәскә ант биргән идек тә... Аларның каберләрен шул явыз фашистларга калдырыйммы?..

Хуҗабикә юешләнгән күзләрен яулык чите белән каплады.

Сүзне икенче тирәгәрәк күчерергә кирәклеген аңлап, Харис сорап куйды:

— Балаларыгыз зурлармы соң?

Балалар сүзен ишеткәч, хатын җанланып киткәндәй булды. Сулкылдавыннан туктады.

— Кызым инде быел мәктәпне тәмамлады, унсигезе тулды. Улым, нәнием дә нык ярдәм итә, бөтен эшкә кулы ята...

Шуны гына тыңлап торган диярсең, мич башыннан кара чәчле малай сикереп төште. Әнисе янына килеп, аның беләгеннән кочаклап алды да, күзләрен тутырып, Хариска карап тора башлады.

— Командир! — Хәрбиләрнең берсе пышылдап кына Хариска дәште. — Ял итеп аласы иде бит.

Харис хуҗабикәгә текәлде.

— Хәзер, хәзер, — диде хуҗабикә, ни турында әйтергә җыенганнарын сүзсез дә аңлап һәм, мич артына кереп, ястык-юрган ише әйберләр алып чыкты. Ул арада малай Харис янына ук килеп утырды.

— Син Буденныймы? — дип сорады ул, командирның мыегына ишарәләп.

Харис көлеп җибәрде, оч-очлары кармакныкы кебек кайтарылып торган кап-кара мыегын сыпырып куйды. Малайны күтәреп алдына утыртты да:

— Нәрсә, охшаганмы?

Малай аптырап анының күзләренә текәлде. «Һе, ничек инде ул? Үзенең мыегы бар, башкалар командир дип кенә дәшә, киеме дә шуныкы төсле...»

— Каян беләсең син Буденныйны, егет? — диде Харис, малайны кочагына алып.

— Белмәскә! Бөтен малайлар Буденныйга охшарга тырыша, аның белән бергә фашистларны дөмбәсләргә хыяллана. Бер дәрестә укытучы апа күрсәткән иде рәсемен. Нәкъ сиңа охшаган. — Малай, Харисның кочагыннан котылырга теләп, тартылып куйды. — Минем дә синең кебек, атка атланып, фашистларны кылыч белән тураклап йөрисем килә...

Өстәлне стенага табарак этеп, бөтен бүлмәнең буеннан-буена урын җәелде. Харис йокы алдыннан саф һава сулап керү нияте белән ишегалдына чыгып китүгә, малай тиз генә мич артына йөгерде. Яшен тизлеге белән мич өстендәге ятакка менде дә тыныч кына йоклап яткан апасын җилтерәтергә тотынды.

— Наталка, Наталка, тор әле... Беләсеңме безгә кем килде?!

Апасы канәгатьсез генә ыңгырашып куйды да икенче якка борылып ятты. Малайның тынычланырга исәбендә дә юк иде, апасын төрткәләвен белде.

— Җитте инде сиңа! Иртүк торасы бар, башымны катырма әле. Тагын шул Буденный белән саташасыңдыр инде...

Апасының бу сүзләре малайны тәмам аптырашта калдырды.

— Ничек белдең син аны, Наталка? — диде ул, ихлас гаҗәпләнеп һәм пышылдауга күчте. — Нәкъ үзе!.. Буденный... Ышанмасаң, үзең кара.

— Ну... — Энекәшенең саташып уянганлы-

гына иманы камил булса да, Наташаның башка чарасы калмады — тавыш чыгармаска тырышып, мич өстеннән төште дә, киемнәрен булдыра алганча рәтләштереп, аралыктан чыкты.

— Исәнмесез, — диде ул, инде чишенеп йокларга ятарга җыенучы солдатларны күздән кичереп.

Әлбәттә, Буденныйга аз гына охшаган кеше дә юк иде алар арасында. «Әй, бу маңка малайны! — дип уйлап куйды Наташа. — Хыялый, саташкан...»

Ишек ачылып китте һәм аның каршында тагын бер ир-ат пәйда булды.

«Ул! Буденный үзе! Шул ук сызылып киткән кара мыек, шул ук гимнастерка, биленда кылычы. Ул күзләре... Якыннан бигрәк тә матур икән үзләре... Ходаем, нәрсә турында уйлыйм мин?!»

Наташа, үзенең уйларыннан үзе оялып, бит алмаларының чөгендердәй кызарганын тойды. Йөзен тизрәк шәл чите белән каплап, ишегалдына чыгып йөгерде.

Харис баскан урыныннан кузгала алмыйча озак басып торды. Әле генә йөгереп чыгып киткән кызның сылу гәүдәсе, һушны алырдай чибәр йөзе, оялчан зәңгәр күзләре турында уйлады ул.

Шул мизгелдә туган авылы, хатыны, өч баласы күз алдыннан йөгереп узды. «Минекеләрнең, ачлы-туклы яшәсәләр дә, күне-төне коточкыч авыр эштә булсалар да, бер юанычлары бар ичмасам — алар үз туган җирләрендә, якташлары, кардәш-ырулары белән. Боларны исә иртәгә озын-озак юл, билгесезлек көтә. Туган җирсез калган бу кешеләр, бу сылукай кая барыр, кемгә сыеныр?..»

Харисның уйларын инде чишенеп юрган астына кереп чумган хәрби бозды:

— Все, егетләр, бетте командир!

Солдатлар дәррәү көлешеп алдылар.

...Харис уянганда, таң беленеп килә иде инде. Хуҗабикә әллә бөтенләй йокламаган тагын, юлчылар уянганчы кайнар чәй әзер иде. Хәрбиләр аяк өсте генә сыйландылар да йорттагыларга рәхмәт сүзләре әйтә-әйтә чыгып киттеләр. Бераздан аларның атлары, авыл читен соры тузанга күмеп, көнбатышка таба юл алды. Хуҗабикә, чыгып китәр алдыннан Харис тоттырган кәгазь кисәген учына кысып, капка төбендә алар артыннан кул болгап калды...

* * *

«Димәк, Наташалар монда! Минем өйдә!..»

Харисның күңелен нәрсәдер кытыклап алды, тәне буйлап ток йөгереп узгандай булып китте, тыны кысылды...

— Улым, су алып чык әле, — диде ул, башкалар ишетмәсен дигән кебек ярым пышылдап кына. — Тик шауллама, яме, уянмасыннар.

Нурулла кереп киткәч тә, ир уй-фикерләрен, ишеткән-күргәннәрен тәртипкә китерергә кереште. Бер яктан караганда, аның күңеле сугыштан исән-имин кайтып, газиз улларын, туган авылын кабат күрү бәхетеннән иркәләнсә, сылу кыз Наташаның да алар өендә яшәве шатлыклы, ләззәтле кичерешләрне икеләтә арттырды кебек...

Өйалды ишеге баскычта уйланып утыручы Харисның сыртына килеп бәрелде.

— Ай, — дигән тавыш ишетелде эчке якта.

Харис сикереп торды. Саклык белән генә

ишекне ачты. Анда, өйалдында, кайчандыр үзен Буденный дип атаган малай белән аның апасы, элеккечә күз явын алырдай сылу гәүдәле Наташа басып тора иде.

— Буденный?! — Елмаеп үзләренә карап торучы таныш йөзне күреп, малайның түм-түгәрәк күзләре маңгаена менде.

— Нихәл, кавалерист? — диде Харис, малайга олыларча кул биреп. — Үсеп буламы?

— Була-а, — диде малай татарчалап. «Нигә шулай дип сорый икән бу абый?» дигәндәй, йөзенә аптыраган кыяфәт чыгарды.

— Исәнмесез, абый!

Монысын Наташа әйтте. Кызның тавышы да гәүдәсенә, буй-сынына бик ятышлы, искиткеч матур, ягымлы булып ишетелде Хариска. Кулын малайга биргән килеш басып торганлыгын бераздан гына аңышты ул. Бит алмалары кызарды.

Харис, әллә кайлардан, йөрәгенең иң ерак почмагыннан бәреп чыккан хисләрен тыярга тырышып, кыюсыз гына кызның йомшак, җылы учын кысты. Күз карашлары очрашты.

— Исәнме, Наташа!..

Шул вакытта чүмеч белән салкын су күтәреп Нурулла чыкмаган булса...

## 7

Сугыштан кайтып берничә көн үтүгә, Харисны элекке эш урынына билгеләп куйдылар. Тормышлар әкренләп үз калыбына керә башлады. Авыл советы рәисе булгач, гаилә дә азык-төлеккә интекмәде. Авыл тормышына хас булганча, сирәк-мирәк кенә булса да, аларның яшәешенә көнләшеп караучылар табылды. Тирә-юньдә имеш-мимешләр тарала башлады.

Харис көне-төне кайдадыр югалып йөрсә дә, Галия күңеленә ире турында шик кертмәскә тырышты.

«Көнләшәләр, — дип кенә кабул итте Галия ире белән Наташага кагылышлы гайбәтләрне. — Нишләп, өч баласы була торып, марҗа белән чуалсын ди ул?»

Галия үзе белән бер табактан ашаучы, бер түбә астында яшәүче нәкъ шул кызның Хариска гыйшык тотуын, аларның көн дә диярлек икәүләшеп аулакка — урманга йөрүләрен, белгеле, күз алдына да китерә алмады. Чынбарлыктан ерак, ай-һай ерак иде шул аның уйлары...

...Әүвәл, сугыш вакытында танышканда ук, Харис белән Наташа арасында бер-берсенә карата ниндидер сәер тартылу барлыкка килде. Моны Харисның хезмәттәшләре дә сизгән иде. Язмышны алдан планлаштырып булмаячагын яхшы аңласа да, чибәр кыз белән кабат очрашуга өмет итеп, аларга үзенең авылдагы адресын калдырып киткән иде. Шул кәгазь кисәгендә күрсәтелгән авылга гына түгел, Харисның үз йортына ук урнашканнар...

Салкын һәм эңгер-меңгерле кыска көннәре белән кыш үтеп, күңелгә якын яз килде.

«Урманнарга бай бу төбәк. Гомер буе шушындый гүзәл табигатьле урында яшәү бәхетенә ия бу Мамадыш халкы. Татарстан халкы. Ә бездә, Украинада...»

Наташа янәшәдән атлап баручы Харисны онытып ук җибәрде булса кирәк, урманга карап кычкырды:

— Мин си-не я-ра-там!

— Мин дә-ә-ә! — дип сузды Харрис, шаярып.

Кыз сискәнеп китте. Янында кеше барлыгы исенә төшеп, бит алмалары кызарды. Каш астыннан оялып кына Хариска карап куйды.

— Гафу ит, Харис абый, онытылып киттем...

— Ярар инде, Наташа, оялма миннән шулхәтле. — Ир канәгать елмаеп куйды. — Нинди абый булыйм ди мин сиңа?! Чит кеше түгел бит...

Шул вакыт Наташа бөтенләй көтмәгән хәл булды. Харис кинәт кызны кочагына кысты да пәп итеп кенә битеннән үбеп алды.

Саф соклану, рәхәтлек хисләре тамырларны көмеш ут белән тутырды... Бер кочак белән чикләнгән дөнья... Йомылыр-йомылмас керфекләр артында ниндидер очкын... Тынлык... Кызның кичерешләрен нинди сүзләр белән генә аңлатып була соң?!

Карашлар бер-берсенә береген калды. Наташаның баштарак куркып калган, усаллана башлаган кебек тоелган күзләрендә ике бөртек яшь тамчысы пәйда булды. Ул да булмады, иреннәр ирен белән көрәшергә тотынды...

Урман авызында шул рәвешле озак кына басып торганнан соң, Харис, Наташаны тагын кочагына кысып, йөзенә текәлде. Кызның күзләрендә әле генә кичергән хис ташкыны чаткылары күренсә, иреннәрендә мәгълүм канәгатьлек турында кычкырып торучы елмаю чәчәк аткан иде.

Бераздан барысы да кабатланды. Бер-берсен табышкан, бер-берсеннән башка яши алмаячакларын, андый тормышның мөмкин түгеллеген, мәгънәсезлеген аңлаган ике йөрәк арасында гасырлардан гасырларга кабатлана торган хисләр, кичерешләр...

Харис үзен аңын югалтыр, йокыга китәр, акылын җуяр дәрәҗәдә хис итте. Сәер, бу уйлар аңа да ниндидер рәхәтлек бирә иде. Иң рәхәте — хәзерге минутта үз кочагында гүзәл, нәфис яшь кыз гәүдәсен тою...

Ирнең күңелендә Наташа белән икесенә генә кагылышлы әллә нинди планнар, хыяллар бөреләнде.

— Ай!..

Кинәт Наташа ирнең кочагыннан читкә тартылды.

Харис аның бу хәрәкәтенә әллә ни игътибар да итмәде кебек, уйлары белән көрәшүен дәвам иттерде.

«Шулай да уйланырлык нәрсәләр җитәрлек, Харис дус. Бу Наташа, бик яшь булуына карамастан, шундый сизгер, дәртле күренә... Тик рухи яктан, эчке тойгылары мәсьәләсендә, ул әле дә ябык кабырчык эчендәге мәрҗән булып кала бирә...»

Ул моны чираттагы «мәхәббәт көрәше»ннән соң, Наташа аның кочагыннан арынып икенче якка борылып баскач аңлады. Ир авыр сулап куйды. Бу мизгелдә хәтта кыз аңа бөтенләй чит-ят кеше кебек тоелып китте...

Ләкин мондый икеләнүләр озакка бармады. Сугыш тәмамланды. Чираттагы күмәк җыелышта авылга эвакуацияләнеп килгән гаиләләрне кабат туган якларына озату турында сүз кузгатылды...

* * *

Төшке аш вакыты иде. Район үзәгенә барышлый, берәр чынаяк чәй эчеп чыгармын дип, Харис өенә кагылырга булды. Алты һәм дүрт яшьлек уллары гына өйдә иде. Наташа ишегалдында кычыткан турый.

Харис тиз генә өйгә кереп чыкты да Наташага таба юнәлде. Гадәтенчә, арттан килеп, аның нечкә биленнән кочып алды. Мыегы белән кызның муенын кытыклады. Тик ни өчендер бу

юлы Наташаның йөзендә элеккечә шатлык, канәгатьлек тойгылары чагылмады. Ул гына да түгел, Наташаның күзләреннән яшь бәреп чыкты.

«Гаҗәп. Сәбәбе нидә икән?»

Харисның аңа төбәлгән аптырашлы күзләрендә шул сорау кычкырып тора иде.

Кыз ирнең үзенә текәлеп карап торуын шәйләп алды.

— Минем бөтен «проблемалар»ымның бары тик бер генә сәбәбе бар: мин яратырга тиеш булмаган, хакым булмаган кешене артык нык яратам икән, — диде ул, бераз тынычлангач, ярым пышылдап. — Ике ут арасында бәргәләнәм димме.

«Бәтәч, — дип уйлап куйды ир, кем бакчасына таш ыргытылганын чамалап. — Нигә аны башка кешеләр алдында сиздерергә соң инде? Балалар килеп чыкса...»

Әллә ни җитдигә алмаса да, кызның сүзләре аның күңел кылларын селкетеп куйды.

— Ир-ат халкына бер нәрсә аңлашылып бетми, — дип дәвам итте кыз, үзалдына сөйләнгәндәй. — Имеш, нигә бу хатын-кыз бөтен нәрсәне йөрәгенә шулкадәр якын ала? Энәдән дөя ясамаса... Югыйсә күрештең, очраштың, гыйшык-мыйшык... Иртәгәсен дөньяны кабат берни булмагандай кабул итү бик авыр микәнни соң? Нигә кирәк артык сүзләр, эчпошыргыч акыл сатулар, зарланулар, хис-мис дип сөйләнүләр?..

Харисның мондый эчтәлектәге зар-интизарларны моңарчы да ишеткәләгәне бар. Шуңа күрә бу сүзләрне колак тирәсеннән генә уздырып җибәрергә тырышты. Чөнки белә — кыз ялгыша. Әллә белеп, әллә белмичә... Бу мәсьәләдә Харис Наташага үз фикерен, үз каланча-

сыннан караганда дөрес дип исәпләгән фикерне әллә ничә кат төшендерергә маташты. Күрәсең, кыз гына анның фикерен һаман кабул итә алмый, үз туксаны туксан.

— Юк, кайсы гына яктан уйлап караганда да, син бу очракта хаклы түгел.

Харис кызның күзләренә төбәлде. Наташаны соңгы арада бик еш бимазалый башлаган бу авыр уйлардан арындырырга кирәк икәнен яхшы аңлый ул. Сүзне икенчегә бору ягын карады.

— Җаныкаччаем, — диде ул, гөнаһсыз кыяфәт чыгарып. — Әйдә, мине озатасыңмы? Мамадышка барып кайтам.

Наташа аңа усал итеп карап куйды.

— Әй, сиңа сөйләсәң дә инде... һаман шаярган буласың.

«Аһ, бу күзләр! Аларга карагач, шаярмас җиреңнән шаярырсың, акылыңны җуярсың. Кара инде, ул күзләрдә нинди усаллык булсын ди? Минем тарафтан нинди дә булса тәкъдим ишетергә тилмереп кенә тора бит алар — әнә ничек елкылдап, ялтырап куйдылар!»

Ирнең уйларын раслагандай, икенче мизгелдә үк кыз инде өйалды ишеге янына бер кадакка элеп куелган пинжәге белән мәш килә башлады. Киенеп бетерде дә Харискa таба борылды.

— Бармыйсыңмыни?!

Бармаган кая!..

Башта сүзсез генә атладылар.

— Бик зур гөнаһка батып беттек. — Кызның үз туксаны туксан — әйләнә дә кайта бер темага. — Шулай икәнен дә яхшы беләм, тик...

Харисның исә бу турыда кат-кат сөйләшеп баш ватасы килми.

— Ә нәрсә соң ул гөнаһ? — дип бүлдерде ул

кызны. Түш кесәсеннән тәмәке алып капты, ашыкмый гына аңа ут элде.

Наташа бу сорауга үзенчә әзер иде.

— Безнең арадагы мөнәсәбәт үзе үк зур гөнаһ бит инде.

Харис аның ни әйтәсен сүзен сүзгә белә. Шуңа күрә аңа аптырамады да, үпкәләмәде дә, ачуланмады да.

— Ярату гөнаһ була димени, тилекәй?! Үзем әйтимме соң? — Тәмәке тоткан кулын селки-селки аңлатырга кереште. — Мин, беләсең, атеист кеше. Шулай да... Дини кешеләр, кара халык фикеренчә, безне Алла бар иткән. Ярар, булсын да ди. Гөнаһ ул менә шул Алланың урынын биләргә, аңа тиңләшергә омтылу. Ә син телгә алган «хыянәт-җинаять» ише гамәлләр — вак мәсьәлә. Моны дин әһелләре хәтта үзләре дә әйтә. Шуңа күрә тәмуг дигәннәреннән куркырга кирәкми. Кеше ожмахта кылган гөнаһлары өчен монда, җир-тәмугка куылган, ди Библия. Җирдә яшәү — тәмуг газабы кичерү. Гөнаһың бетте исә яки кичерерлек дәрәҗәдә аз икән, шул чагында гына Алла кешене үз хозурына, ожмахка ала. Димәк, кеше гөнаһлары беткәч үлә булып чыга. Минем, мәсәлән, үләсем килми әле...

Наташаның авызы ачылып калды.

— Ай, ни сөйлисең син, Харис?!

Аның йөзендә чын-чынлап курку чаткылары чагылып китте.

Харис сүзне кабат башка сукмакка кертеп җибәрүне хәерле тапты.

— Наташенька, әйдә бу турыда уйламаска тырышып кара әле... Киттек, кибеткә кереп чыгабыз.

— Нигә?

— Тәмәке бетте.

Шулай дигән унайга, Харис, кесәсендә кармаланып, тәмәке кабын тартып чыгарды. Кыз, яртылаш кына бушаган капны күреп, кашларын җыерды.

— Хәзер бушатабыз аны. Әле-е, Мамадыштан әйләнеп кайтканчы... Иртәгәдән ташларга исәп. Малайларга да шулай дидем әле. Кхо-о! — Харис, каты гына йөткереп куйгач, тәмәкесен учлары белән җилдән ышыклый-ышыклый, ут элдерде.

Шактый араны сүзсез генә бардылар. Һәркем үз уйларына чумган иде.

«Җир йөзендә минем эчке дөньямны аңлардай бер генә җан иясе дә юк микәнни? Нигә әле мин, абзарга куып кертелгән мал шикелле, ашап, һава сулап, йоклап кына яшәргә тиеш? Киң тоелган шушы дөньяда минем тормышка ашыра алырдай хыялларыма аз гына да урын юкмыни? Булганны югалту озак түгел, аның өчен санаулы мизгелләр дә җитә. Файдаланып каласы иде, файдаланып...»

— Карале, Наташенька, минем тәкъдимем бар.

Кызның күзләрендә кабат ихлас кызыксыну чаткысы балкып китте.

— Нинди? — дип, күзләрен тутырып, Хариска төбәлде.

Ир Наташага карап елмайды.

— Әй, ярар, кибеттән чыккач әйтермен...

Кибеттән чыккач, салмак кына адымнар белән олы юлга таба атладылар. Сүзләр сүзгә ялганды. Наташага бигрәк тә Харисның әйтергә теләгән «тәкъдиме» тынгылык бирмәде.

— Мин сине яратам, Наташа!

Кыз абынып егыла язды. Моңа кадәр ишеткәләгән булса да, бу юлы әлеге сүзләр ничек-

тер үтә серле яңгыраган кебек тоелды аңа. Йөзе җитдиләнде. Карашы кабат Харисның күзләрендә беректе.

— Шаярма, Харис! Көлмә минем хисләремнән, зинһар. Беләсең бит инде: бер-беребезгә карата нинди генә мөнәсәбәттә булсак та, без атлап чыга алмый торган киртәләр дә бар... — Наташаның күзләре яшьләнде. — Синең эштән кайтуыңны зарыгып көтәм. Көннәрне көч-хәл белән, этеп-төртеп уздырам мин, ышанасыңмы шуңа?! Ышанмыйсыңдыр шул. Ә кич белән, син эштән кайткач, үз хисләрем өчен кинәт кенә гарьләнеп куям — син бүтәннәрне, хатыныңны күргәч ныграк шат буласың... Минем сүзләргә каршы килергә кирәкми, үзең әйтмешли, күзләре дә сата шул кешене. Шундый мизгелләрдә мин үземне-үзем кимсетәм кебек тоела. Әгәр мин читкәрәк атласам, чынлыкта син үзең үк шат буласың бит. Ә миңа... кая барып бәрелергә белмәгәндә, бернинди артык сүзләр дә, артык сораулар да кирәк түгел, бер мизгелгә җылы итеп иңнәреңә башымны куеп тору да җитә иде. Ә сине бары үз кәефең, аның кырылуы, аңа мин сәбәпче булуы гына борчый.

— Минем хакта болай әйтү дөреслеккә аз гына да якын килми бит. Үз кәефем генә борчымый мине. Һәм минем нинди адымга әзер икәнлегемне нәкъ менә хәзер әйтергә уйлаган идем...

Харис, ялт-йолт кына тирә-якка күз төшереп алды да, кеше-кара юклыгын белеп алгач, кызны кочагына кысты.

— Наташенька, мин сине генә яратам. Мин... синең белән китәм...

Сөйгәне авызыннан мондый сүзләр ишетермен дип Наташа күз алдына да китерми иде. Ышанырга да, ышанмаска да белмәде.

«Нәрсә бу? Харисның чираттагы шаяртуымы? Мине тынычландырырга тырышуымы? Кичә генә Галия апа белән киләчәккә әллә нинди планнар корып утыралар иде бит, ә бүген... Их-х!..»

Харис берара тын гына торды да:

— Ярар, матурым, Мамадыштан кайткач сөйләшербез бу хакта, яме, — дип, олы юл чатына туктаган машина ягына йөгерде...

* * *

Шаяртмады Харис. Шул рәвешле авылдан чыгып китүенә унбиш елдан артык инде. Сугыш тәмамлангач туган якларына юл алган украин гаиләсенә ияреп чыгып киткән иде. Нишлисең бит, тәкъдир дигәннәренә буйсынмый хәл юк — авылдашлары, кардәшләре никадәр генә акылга китерергә тырышып караса да, малайлары күз яшьләренә буыла-буыла ялварса да, туган авылында калмады Харис. Өч газиз баласын, хатыны Галияне язмыш кочагына ташлап калдырырга мәҗбүр булды. Тик мәҗбүр булдымы соң? Бүтән кайтмаска вәгъдә биреп киткән иде дә бит...

...Украинага барып урнашуга ук, Наташа белән язылышып, гаилә корып җибәрделәр. Ел артыннан ел үтте. Әүвәл тормышлары җайлы гына барды кебек. Харисны, тәҗрибәле белгеч буларак, авыл советына рәис итеп куйдылар. Бер-бер артлы улы, кызы туды...

Ләкин бер карашка матур гына башланып киткән тормышның тора-бара рәте-чираты китте. Хариска нидер җитми иде, күңеле һич кенә дә тынычлык таба алмыйча интекте. Тәгәрәшеп үскән балаларына карап утырган вакытларында да, кичләрен, эштән кайткач, алар

белән идәндә ауный-ауный уйнаган чакларында да кинәт бер сәбәпсез кәефсезләнеп калучанга әйләнде.

Ирендәге бу аңлаешсыз үзгәрешләрне Наташа да сизенде. Кыю, тәләпчән холыклы булса да, мондый чакларда аның җаеннан гына торырга тырышты. Чөнки белә: Харисны көннән-көн куәтләнә барган сагыш бимазалый. Туган җир сагышы. Бөтенләй чит-ят тойгы түгел бит, Наташа да, вакытлыча гына булса да, туган нигезне ташлап китү газабын кичергән кеше.

Озак кына уйланып йөргәннән соң, Наташа ире белән ачыктан-ачык аңлашырга кирәк дигән карарга килде. Баштарак Харис, сүзнең ни турында барачагын аңлап алгач та, әллә хатынына авырлык тудырасы килмәгәнгә, әллә узган гомерен чынлап та онытырга теләп, мондый сөйләшүне кирәк тапмады. Тик иренең сагыштан газаплануын, шул сәбәпледер, күрәсең, үзенә карата салкыная баруын күреп белеп торган Наташа моны болай гына калдыра алмады, көннәрдән бер көнне кабат сүз яңартты:

— Харис, синең миңа берәр сүз әйтәсең килмиме?

Эш кәгазьләре белән мәш килеп утырган ир башын күтәреп хатынына төбәлде.

— Нигә алай дисең?

— Мин бит сукыр түгел, барысын да күреп тоеп яшим. Сине нәрсәдер борчый.

Ир ягыннан җавап ишетелмәде. Харис хатынының ни әйтергә теләгәнен аңлап өлгермәгән иде, әлбәттә. Наташаның күзләренә сораулы караш ташлады.

— Соңгы вакытларда болай салкынаюыңның сәбәбен дә чамалыйм...

Харис аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде.

— Туктале, нәрсә уйлап чыгардың инде тагын?

Тавышын күтәребрәк әйтеп ташлавын үзе дә аңлады булса кирәк, Харис кәгазьләренә текәлеп тынып калды.

— Әйе, барысын да чамалыйм, — дип дәвам итте Наташа. — Соңгы араларда тупасландың. Авылыңны, хатыныңны, балаларыңны сагынасың, беләм. Тик... әйдә, Харис, ачыктан-ачык сөйләшик, без бала-чагалар түгел.

Харис бу сөйләшүгә әзер түгел иде. Шуңа да сүзне икенчегә борырга маташты.

— Әйдә, булмаган нәрсә турында баш катырма әле. Миңа булыш, менә бу кәгазьләрне рәткә китерик...

Тик Наташа сүзне башка нәрсәгә бору турында уйлап та карамады. Үзен җәфалаган сорауга төгәл җавап табарга булды.

— Ниндидер сәбәпләр эзләп маташма, Харис, турысын әйт. Алдаганны җенем сөйми. Синең, минем белән араны өзеп, элекке хатының янына кайтып китәсең киләме?

Харис шаркылдап көлеп җибәрүен абайламыйча да калды. Наташаның күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп чыкты.

— Менә сиңа мә! — Ир, урыныннан торып, хатынын кочты. — Юләркәй, нишләп мин сине, балаларны ташлап китим ди?!

— Анда да бар бит алар синең...

Ир җилкәсен генә сикертеп куйды.

— Булса ни. Аларның монда ни катнашы бар? Миңа син генә кирәк, хохлушкам минем...

Наташа шундук сулкылдавыннан тукталды. Иренең күзләренә төбәлде.

— Чынлапмы?.. Ташламыйсыңмы?..

Харис сөеклесенең маңгаеннан үбеп алды.

— Юк, ташламыйм, вәгъдә бирәм... Тик авылга кайтып килер идем...

Наташаның гәүдәсе тетрәнеп куйды, курыкынган күзләре белән кабат иренә текәлде.

— Борчылырлык сәбәп юк, — дип, хатынын тынычландырырга ашыкты Харис. — Авылымны, туган йортымны, кардәшләремне, әти-әниемнең каберен күреп килим мәллә дигән идем. Сагындым... Син рөхсәт итмәсәң, беркая да бармыйм...

Наташа Харисның сумкасына әбәтлек ризык салды.

— Алай булгач, мин сиңа... — Хатынның күзләрендә хәйләкәр чаткылар чагылып китте. — Кайткач әйтермен...

Эшкә барышлый, Харис авыл читендәге калкулыкка менеп төшәргә булды. Ничәмә-ничә ел шушында яшәп, әллә бер дә менеп караганы булмады, әллә кайчандыр менеп тә онытылган... Иң югары җиренә менеп җиткәч, туктап калды.

«Кара, моңарчы бер дә игътибар ителмәгән, таң атканда бу авыл да ярыйсы гына икән үзе...»

Инде яктырып бетә диярлек, шулай да күпчелек өйләрнең тәрәзәләрендә әле тонык кына ут чагыла. Тынлык. Ниһаять, кайсыныңдыр эте ялкау гына өреп куйды. Аңа авылның икенче башыннан бер әтәч сәлам бирде. Харис, сумкасын баш астына салып, яшел чирәмгә сузылып ятты да күзләрен йомды.

«Их, туган авылым! Ни генә әйтсәң дә, сагындырасың шул... Ничек шулай икән ул, кайда гына яшәсәм дә, кайларда гына йөрсәм дә, синең хатирәләр яши, онытылмыйсың. Юкка гына шагыйрьләр дә туган җиргә, аның гүзәл

табигатенә дан җырлап әсәрләр иҗат итмидер, җырчылар аңа багышлап моңлы, җырлар сузмый торгандыр шул. Алар да, үзләренчә, туган якның кадерен белеп яшәргә, аннан аерылмаска өндиләр... Аерылмаска, шайтан алгыры!.. Тормыш юллары син уйлаганча гына булса икән ул. Кемдер гомеренең азагына чаклы туган ягында, туган табигать кочагында яшәү бәхетенә ия, ә кемнедер аяусыз тормыш җилләре ерак-еракларга илтеп ыргыта. Кайберәүләр, азмы-күпме вакыт үткәннән соң булса да, кендек каны тамган туган туфрагына кабаттан аяк басу шатлыгын татыса, кемдер мәңгелеккә ят төбәкләрдә калырга мәҗбүр. Мин дә кайтырмын, авылым, вакытлыча гына булса да кайтырмын! Каршы алырсыңмы син, кабул итәрсеңме мине, адашкан улыңны?..»

Күңеленә кергән уй-хисләре, ватык патефон тәлинкәсе кебек, бер сүзне кабатларга тотынды: «Улыңны... Улыңны...»

«Улларым! Мине улларым көтә бит!.. Наташа... Ә нәрсә Наташа? Ул аңлый мине. Хәлемә дә керергә тиеш!..»

## 8

...Шундый уйлар, шундый хыяллар, шушы сагыш алып кайтты аны туган авылына. Ә нәтиҗәдә ничек килеп чыкты? Көтмәгәннәр бит, беркем дә көтмәгән аны монда. Харис артык бу авылда...

— Әйе-е-е, Хәмит, — дип сузды ир һәм янында басып торучы картның өс-башын, сакалмыек баскан йөзен, тирән җыерчыклар белән чуарланып беткән кулларын, сәләмә киемен күздән кичерде. — Каргадың син мине-е.

— Юк, мин түгел. Үзең...

Хәмит сүзен әйтеп бетермәде. Урам башында нәни бала күтәргән бер ир-ат пәйда булгач: «Әнә Нурулла үзе дә кайта», — диде дә, кулларын артка куеп, вак-вак адымнар белән генә якындагы тыкрыкка кереп югалды.

Бала күтәргән егет, дөрестән дә, Нурулла иде. Харисның олы улы.

Унбиш ел буе күрмәсә дә, берсеннән-берсе кечкенә өч баласын, үзен сугыштан зарыгып көтеп алган хатынын хыянәтчел рәвештә ташлап киткән бу кешене тиз таныды Нурулла. Сүзсез генә кул биреп исәнләштеләр. Сүзсез генә туган нигезләренә, Нурулла өенә таба атладылар.

— Әти, — диде Нурулла, капка төпләренә кайтып җиткәч, — сөйләшеп алыйк әле.

«Әти» сүзен ишеткәч, Харисның күңеле тулды. «Ул мине әтисе дип таный. Таный!.. Ул бит ир-ат, мине аңларга тиеш...»

Капкага терәп ясалган эскәмиягә барып утырдылар. Харис, түш кесәсеннән тәмәке кабы чыгарып, Нуруллага сузды. Улы баш тарткач, аның кулында нәни бала да булуын искә алып, үзе дә бераз икеләнеп утырды. Тик озак түзә алмады, рөхсәт сорап, Нурулланың күзләренә текәлде.

— Тарт, тарт, мин Фәнияне әнисенә биреп чыгам, — дип, Нурулла өйгә кереп китте.

Ул да булмады, кире чыгып та җитте.

— Әти, әйдә, керик. Әни дә кайткан...

...Сүз башлый алмыйча, һәркем үз уйларына батып байтак утырдылар.

— Әти! — Сүзне Нурулла башлады. Ул бу сүзне әйткәч, барысы да сискәнеп киттеләр. Әнисенең кинәт йөзе үзгәргәнен ачык күрсә дә, Нурулла игътибар итмәскә тырышты. —

Кем генə, нинди генə булсаң да, минем өчен əти инде син...

Харис белəн Галиянең күзлəре очрашты. Кодрəтеннəн килсə, җир тишегенə кереп китəр иде Харис бу мизгелдə. Нəфрəт катыш җирəнү чаткыларыннан ялтырап торган күзлəр ирнең бəгырен өтеп алды...

— Дөресен əйтим, шулкадəр вакыттан соң кайтып күренерсең дип уйламаган идек, — дип дəвам итте Нурулла. — Үзең дə күреп торасың, монда сине көтмəделəр.

— Улым!.. — Харисның тамагына төер утырды, күзлəре яшьлəнде.

Нурулла, үзе дə искəрмəстəн, пыскып торган учакка бер кочак коры мамык ташлагандай кабынып китте.

— Нəрсə «улым»? Унбиш ел буе кайда идең син? — дип җикерде ул Хариска. — Син, сугыш ветераны, өч малаең армиягə киткəндə кайда булдың? Хəзер без кирəк булдыкмыни? Син ташлап киткəн өч баласына азык юнəтеп йөреп, əниебез бер кулсыз калганда нигə монда түгел идең?..

Харис сискəнеп китте. Галиягə, аның бер карашка башка сəламəт кешелəрдəн берни белəн дə аерылып тормаган кулларына карап куйды.

— Галия!.. Берьялгызыңа гына авырга туры килгəндер, булдыра алсаң гафу ит.

Үзен бик нык рəнҗеткəн, авыр чакта ташлап киткəн, ачыктан-ачык хыянəт иткəн кеше белəн сөйлəшəсе килмəгəнлеге көн кебек ачык. Хатынның җавабы тупас яңгырады:

— Нишлəп ялгыз булыйм ди мин?! Аллага шөкер, балавыз сыгып, мескенлəнеп утырырлык түгел!

Нурулла саклык белəн генə əнисенə күз

төшереп алды. Галиянең төсе качты, күзләреннән яшь тамчылары бәреп чыкты.

Харис тынып калды. Алга таба әңгәмә нинди төсмер алачагы да, биредә үзенә якты чырай күрсәтелмәячәге дә күренеп тора. Шулай да, бар булган кыюлыгын туплап, тамагына утырган зур төерне йотып, кем әйтмешли, «ятып калганчы атып калырга» булды. Ирнең сүзләре барысын да гаҗәпкә калдырды.

...Галия үз колакларына үзе ышанмады. Гомер буе язмышның коточкыч канатларында тибрәнгән хатын бу ирнең чиктән тыш оятсызлыгына, шулкадәр михнәтләр «бүләк итеп» тә, әле һаман нидер өмет итүенә таң калды.

— Нәрсә, хәзер тегендәге ике баланны да шулай мәсхәрәләргә, ятим итәргә булдыңмыни инде?!

— Бөтен кәефне бетердең! — Ирнең тузга язмаган сүзләрен тыңлап утырудан гаҗиз булган, түземлеге тәмам төкәнгән Нурулла урыныннан ук сикереп торган иде, үзен кулга алып өлгерде, яңадан утырды. Харисның күзләренә туп-туры карады да, бәгыренә үтәрлек итеп, теш арасыннан гына: — Әти, кит син моннан. Бүген үк. Һәм башка кайтып йөрмә, — дип өстәде.

Сания әтиләренең тавышыннан куркып аралыкта сулкылдый башлаган балаларын тынычландырып килде дә саклык белән генә кабат ире янына барып басты. Кулларын аның җилкәләренә куйды.

— Әтисе, балаларны куркытасың, котырма инде!

— Котырмассың ди монда... Ә, әти, ни, танышлыгызмы соң әле? — Нурулла, күзләрен кыса төшеп, Хариска текәлде. — Бу минем

хатыным була. Сания... Син кызыгып йөргән Миңниса белән Мөнирнең уртанчы кызлары. Хәтерлисеңме, син «халык дошманы» дип атаган, үз кулың белән НКВД җәлладларына тотып биргән теге Сабир белән Зәки оныгы!

## 9

«...Ник кайттым мин авылга? Ахыры шулай булачагы билгеле иде ләбаса. Кем инде унбиш елдан соң кайтып шундый сүзләр белән шаяра?! Их, Харис, Харис... «Кичерсәгез, кайтам», янәсе. Кем тарткандыр теленнән. Бик кирәк идем ди мин анда! Андагы сүзләрем Наташага килеп ирешсә диген әле син. Картаймыш көнендә бөтенләй урамда калмагаең!»

...Харис күзләрен йомып кәнәфидә утыра иде. Янына Наташа килеп чүгәләде.

— Харис, нишләп әле син авыл турында берни дә сөйләмисең?

Ир, сискәнеп, күзләрен ачты. Бераз сүзсез генә утырды. Ниһаять, түшәмгә текәлгән килеш, теләр-теләмәс кенә әйтеп куйды:

— Кирәкми, әйдә бу турыда сөйләшмик әле, Наташенька.

Аннан соң, ниндидер мөһим бер нәрсә исенә төшкәндәй, кисәк кенә тураеп утырды да хатынына таба борылды.

— Карале, Наташенька, хәтерлисеңме, син миңа нәрсә әйтәм дигән идең әле? Мин авылга кайтырга җыенганда...

Мизгел эчендә хатынының бит алмалары кып-кызыл булды.

— Мин... тагын бәби көтәм.

Харис шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Сүзсез генә хатынын кочты.

— Харис, бер сүз әйтсәм ачуланмассыңмы?

Наташаның бу сүзләрен ишетеп сагаеп калса да, ир тыныч кына сорап куйды:

— Нишләп ачуланыйм ди инде, юләркәем! Нинди сүз ул?


— Кызыбыз туса, исемен Галия дип кушыйк, димәкче идем... — Хатын иренең күзләренә карап елмайды. — Ни дисәң дә, сугыш чорында безне үз йортына алган, актык ризыгын бүлешкән, ахыр чиктә сине миңа бүләк иткән кеше бит...

Кинәт бөтен дөнья бер мизгелгә дөм караңгылыкка чумды: Харис күзләрен учлары белән каплады. Ул да булмады, култык асты сулкылдарга тотынды: сугыш еллары хатирәсе — йөрәк янында берегеп калган кургашын кисәге кузгалып куйды.

Ир куркынган күзләре белән хатынына төбәлде. Бераздан исә, күкрәген тотып, күзләрен чытырдатып йомды да тынып калды...

«...Кызыбыз туса?!»

# Хикәяләр



# Җан тартмаса...

*(Чын хикәя)*

Көз уртасы. Коен яңгыр ява. Мамадышка бара торган олы юл чатында, ялгыз усакка сөялеп, алтмыш яшьләрдәге бер апа басып тора. Кулында зур гына төенчек.

— Нихәл, Сания, шәһәргә барышмы? — дип дәште аны шактый ерактан танып алган берәү.

— Синең хәер-фатихада, Гаяз абый... Барып кайтырмын дип махсус ял сораганыем, — диде Сания, ул арада янына ук килеп җиткән кешенең сәламенә җавап кайтарып.

Гаяз абый, учын каш өстенә куеп, күктәге куе болытларга күз төшереп алды.

— Тапкансың вакытын...

— Нишләмәк кирәк, иртән гел аяз иде дә бит, — диде Сания. — Техникасы да булмас инде аның. Әллә җәяүләп кенә китәргәме дип торам әле менә.

— Шулай бик ашыгычмыни эшең?

— Соң, ашыгычмы дип, болай әллә ни эшем дә юк үзе. Бер уйлагач барасые инде...

Гаяз абый беравык сүзсез генә Саниягә текәлеп карап торды.

— Мондый яңгырда техникасы булса да барып җитүең икеле, — диде ул, ниһаять, инде тәмам юешләнеп беткән Санияне чын күңелдән кызганып. — Сер булмаса, нигә шулай ашкынасың инде Мамадышка?

— Хәтимә апа картлар йортында ята бит, Гаяз абый. Хәлен белеп кайтыйм дигәнием...

Гаяз абый янә Саниянең күзләренә сәерсенеп карап куйды.

— Нәрсә сөйлисең син, кызый? Ул Хәтимәнең кемлеген бөтен кеше белә. Аның аркасында никадәр кыен ашавыгыз да сер түгел. Нужәли шул хәлләрдән соң да...

* * *

— Әни, минем укытучы буласым килә...

— Соң, кызым, ничә мәртәбә әйттем бит инде, рәтебез юк, дип. Бала-чага булма, зинһар. Инде болай да...

Әнисеннән шундыйрак җавап ишетәчәген чамалаган иде Сания. Шуңа күрә сүз көрәштереп тормады, чиләк-көянтәсен күтәреп, чишмәгә китте.

Әле өченче сыйныфта гына укып йөргән энесе Рамил Зәкияттәйнең чишмәгә терәп үк диярлек үргән читән буйларындагы кычыткан гаскәрен сыек чыбык белән тар-мар итеп йөри иде.

— Бәләкәй апа, анда Рәис күренмәдеме? — диде Рамил, Санияне чишмә янына килеп җиткәч кенә абайлап.

— Юк, — диде Сания коры гына. — Тырай тибеп йөрисең шунда. Рәис синең шикелле ялкау түгел лә. Әтисе белән умартадан бал суыртадыр әле. Йә тауга, бозауларына печәнгә дип менеп киткәндер.

Әнисенең сүзләреннән кәефе кырылган иде шул, Рамиле тагын юк-бар белән баш катыра...

Рамил чыбыгын уңга-сулга селтәвен белде.

— Суырткан ди Рәис бал! Хәзер чыгам дигән иде лә ул. Болынга төшмәкче иек без аның белән. Юага.

Шул чагында Саниянең күңелендә бер план пешеп өлгерде. Озак уйлап тормыйча, чиләкләренә су тутырды да кайту ягына юл алды.

— Рамил, әйдә икәү киттек болынга, — диде ул, энесенә дәшеп. — Быел ташудан соң минем дә бер генә тапкыр да төшкәнем юк бит әле.

— Ә Рәис? — Рамилнең дә болынга бик төшәсе килә дә, иптәшен бирергә бирдә көтәргә сүз бирде шул. — Бәләкәй апа, давай мин Рәисләргә кагылып чыгам да синең арттан куып җитәм, яме...

Ташу киткәнгә атна-ун көн генә әле. Түмгәктән түмгәккә сикерә-сикерә беренче сыртка барып җиттеләр. Әйләнә-тирә тоташ сазлык-баткаклык булса да, авыл халкы телендә «беренче сырт» дип атала торган бу озынча утрауда коп-коры икән инде. Ерак түгел генә «икенче сырт» куаклыклары күренеп тора. Ә юа елның-елында шушы сыртта гына күп үсә. Саниянең әнисе әйтмешли, ник чалгы белән чапмыйсың шунда.

Юа тутырылган арыш капчыгын Рамил күтәрә алмады. Җилкәсенә күтәреп салуы Саниягә дә җиңел булмады. Беразын бушатырга да уйлаган иде башта, тик туктап калды. Алдан уйланган ниятен тормышка ашырасы бар бит. Юа никадәр күбрәк булса, файдасы да шулкадәр зур булачак.

Сания белән Рамил, кайтырга чыкканчы, юакузгалак иште үләннәр белән тамак ялгап алдылар.

— Нишләттмәкче буласың бу хәтле юаны, апа? — Рамил үлән белән шыплап тулган капчыкка ишарәләде.

— Хәсән абый бүген Мамадышка барам дигәние, мине дә алмас микән? — диде Сания үзалдына гына сөйләнгәндәй һәм аягына торып басты. — Әйдә тизрәк, китеп бармасын тагын.

«Ник бармакчы апасы Мамадышка? Нишләп миңа әйтми икән? Мин дә барырыем ул Мама-

дышка». Рамил апасына каш астыннан гына күз ташлады.

Әле генә быты-быты сөйләнеп кайткан Рамил тынып калгач, анның ни турында уйлаганын Сания шундук чамалап алды.

— Әни җибәрсә, син дә барырсың, — дип, энесендә өмет чаткылары уятты. — Миңа иптәш тә кирәк бит...

Авыл әллә ни ерак булмаса да, авыр капчыкны күтәреп-өстерәп дигәндәй кайта торгач, шактый вакыт үткән. Алар авылга килеп кергәндә, Хәсән абый, маңгаенда йолдызны хәтерләтеп балкып торган ак табы булган атын җигеп, Мамадышка бара торган олы юлга чыккан иде инде. Еракта ук нидер кычкыра-кычкыра үзенә таба килгән Сания белән Рамилне искәреп, Йолдыз кушаматлы атын туктатты:

— Тр-р, малкай... Нәрсә, күршеләр? Печәнгә төштегезме?

Сания, ниһаять, Хәсән абый янына килеп, авыр капчыгын арба тәгәрмәченә сөяде. Үз үтенечен әйтте. Күрше балаларын моңарчы бер тапкыр да үпкәләтмәгән Хәсән абый бу юлы ни әйтергә дә белмәде. Бераз тавыш-тынсыз гына утырды да, бер төпле фикергә килеп, балаларга дәште:

— Әйдә, күршеләр, сикерегез арбага. Әниегез белән сөйләшеп карыйк...

Өйләренә кайтып җиткәнче Сания Хәсән абыйга үзенең ниятләрен аңлатып өлгергән иде инде. Шуңа күрә сүз Хәсән абый белән Миңниса апа арасында гына барды, ә балалар бер читтә кайнашты.

Әниләре башта кырт кискән иде дә, Хәсән абый: «Үзем күз-колак булырмын», — дип катват ышандыргач, ризалашты тагын. Балалар-

га дәшеп, тиз генә киемнәрен алмаштырырга кушты, үзе аларга, юлда тамак ялгарга дип, төенчек әзерләргә кереште...

Йолдыз, карап торышка әллә ни кодрәтле күренмәсә дә, шактый җитез ат икән. Бер сәгать чамасы үтүгә, авылныкыннан бөтенләй диярлек аермасы булмаган Мамадыш шәһәренең торак йортлары күренде.

Саниянең бу шәһәргә беренче генә баруы түгел. Былтыр бер тапкыр әнисенә ияреп базарга килгән иде. Шулай да дулкынлана иде ул. Бер ел эчендә шактый үзгәргән Мамадыш. Яңа йортлар, кибет, тагын нindидер корылма пәйда булган. Ә монысы нәрсә икән?..

Ул бина яныннан үткәндә, Йолдыз бераз адымын акрынайткан кебек тоелды Саниягә. Борынын гаҗәеп тәмле исләр кытыклый башлагач, авылдан чыгып киткәч үк арбага түшәлгән йомшак, коры печәнгә ятып изрәп йоклап киткән Рамил дә уянды. Күзләрен уа-уа торып утырды да чебиләнеп бетә язган аякларын арба читенә салындырды. Як-ягына карана башлады.

— Әнә тобырша астында чишмә суы бар.

Рамилнең нәрсә эзләгәнен чамалый иде Хәсән абый.

— Болыннан кайтканда нык кына арылган, — диде Рамил, акланган кыяфәткә кереп һәм Хәсән абый күрсәткән урыннан табып алынган зур гына шешәдән салкын су йотты. — Мамадыш шушымыни инде?

Мамадыш шәһәре дип аталган бу район үзәгенә түгел, якын-тирәдәге кечкенә мари, керәшен авылларына да аяк басканы юк иде әле кечкенә Рамилнең. Шуңа күрә әйләнә-тирәне җентекләп күзәтте.

Билгеле, иң беренче булып, апасыныкы кебек, аның да игътибары әле генә күпереп

пешкән шпи исләре аңкып, узгынчыларны үзенә тартып торган бинага юнәлде.

— Пикәрни ул, балалар, ипи комбинаты, — диде Хәсән абый, аларның сүзсез соравына җавап биргәндәй. — Тик кыйбат шул ипекәе. Кыйбат... Но-о, малкай...

Ашказанын кызыктырып торган бу урыннан тизрәк китүне кулай күргән Йолдыз да хуҗасы Хәсән абыйның хәленә керде, күрәсең, — тизлеген бермә-бер арттырды.

— Кара, монда трактор да безнең авылдагы кебек берәү генә түгел икән... Монысы машинадыр инде. Шәп чаба бу... — Ымсындырып торган ипи исе сизелми башлагач, бер мәртәбә авыр сулап куйды да Рамил тирә-юньне күзәтүен дәвам итте. — Ни, Хәсән абый, Кәримә апа ничек шундый зур тимер тракторны йөртә ала икән ул?

Авылга сугыш башланыр алдыннан кителгән бердәнбер тракторны «йөгәнләгән» күршеләре Кәримә апа турында иде бу сүз.

— Соң, сугышка китеп бетте бит бөтен ирләр. Тракторда эшли алырлыклары кире кайта алмады, минем ишеләрнең белеме юк, — диде Хәсән абый, үзалдына сөйләнгәндәй. — Менә Мамадышка шул сорау белән баруым да инде минем бүген.

Балаларның сораулы күзләре Хәсән абыйга текәлде.

— Тракторчылар курсына керергә исәп...

Мамадыш базарына шәһәр эченнән әллә ни ерак барасы түгел икән. Төшке аш вакыты узып бара иде инде. Шулай да халык күп. Дөрес, игътибар беләнрәк караганда, халыкның күпчелеге сатучылар икәнлеге күренә. Нәрсә генә саттмыйлар монда. Берәүләре үз товарларын кычкыра-кычкыра мактый, берәүләре, сатасы

әйберләрен алларына җәеп салып, тын гына утыра...

Хәсән абый Сания белән Рамилне базар капкасы янында ук калдырды.

— Менә монда яхшырак булыр, балалар, — диде ул, юа тутырылган капчыкны базар коймасына сөяп. — Бөтен кеше шушы урыннан уза... Ике-өч сәгатьтән кайтырбыз.

Хәсән абый үз йомышы белән китеп барды, ә Сания капчыктан үлән тартып чыгарды да аларны учка сыярлык кечкенә бәйләмнәргә аера да башлады...

— Кызым, бу нинди үлән? — дип сорады юан гына гәүдәле бер апа, Сания алдына тезелгән «бәйләм»нәргә ишарәләп.

— Юа бу, апа, — диде Сания, үзенең бит алмалары кызаруын тоемлап.

— Нәрсәгә ярый соң ул? — Юан апа бер йомарлам юаны, кулына алып, әйләндергәләп карады.

— Соң, ашыйлар инде аны, — дип сүзгә кысылды кечкенә Рамил, йөзенә «шуны да белми торган кешеләр бар микәнни?» дигән аптыраулы кыяфәт чыгарып.

Юан апа әле Рамилгә, әле учындагы үләнгә сәерсенеп карап куйды. Бераздан:

— Күпме тора инде? — дигән сорау белән Саниягә текәлде.

Саниянең күңелен бер мәлгә курку хисе биләп алды. Юлда ук өйрәнеп килгән иде бит югыйсә — кешеләр белән сөйләшкәндә үзеңне ничегрәк тотарга, нинди сүзләр әйтергә, каушамаска... Монда килеп баскач, гел икенче икән шул. Бер мизгелгә кыз бөтенләй югалып калды. Бит алмалары гына түгел, колак яфракларына кадәр чия кебек кызарып чыкты, тез буыннары калтырана башлады.

— Ике тиен, апа, — диде ул, бераздан бөтен батырлыгын бер ноктага туплап.

Юан апа ни өчендер, күзләрен кыса төшеп, янә бер кат Саниянең төс-кыяфәтен күздән кичерде.

— Әйдә болай итәбез, кызым, — диде ул. — Башта бер тиенгә алып ашап карыйм, әйеме, аннан инде, юньле нәрсә булса, тагын алырмын.

Тирә-юне болынлыклардан гына торган Нократ елгасы буендагы Мамадышта яшәсә дә, гомерендә ул болыннарга чыкканы булмаган, юа, кузгалак ише үләннәрне кабып карамаган шактый олы яшьтәге юан апа Саниянең «товар»ын гаҗәпләнүдән күзләрен түгәрәкли-түгәрәкли мактарга тотынды:

— И-и, кызым, хәтәр тәмле икән бит бу! — диде ул, бер-бер артлы юа үсентеләрен каба-каба. — Карале, бу шулай хәзер ашарга гына ярыймы соң?

Юан апаның беренче булып бер уч юа сатып алуы, «сатучы» белән иркенләп, ачылып сөйләшә башлавы Саниягә дә кыюлык өстәде. Йөзенә чыккан кызыллыкның эзе дә калмады.

— Юа ул, апа, суган кебек. Хәтта икенче исеме дә кыргый суган әле аның. Ашка салырга була, бәрәңге пешергәндә... Тозлап куйсаң да тәмле...

Юан апаның учы бераздан бөтенләй бушап калды. Күзләре кабат кысыла төште.

— Бер тиеннән бирәсеңме, тагын бишне алам...

Сатулашып тормады Сания, биш уч юаны берәр тиеннән бирде. Киткәндә, бу юан апа авызыннан үзенә атап әйтелгән рәхмәт сүзләре йөрәгенә май булып ятты кызның. «Булсын, бер тиеннән сатсам да шактый акча җыела-

чак бит, — дип уйлады ул. — Бер капчык бит әле ул юа».

Юа сатуы болай ук җиңел, хәтта рәхәт булыр дип уйламаган иде Сания. Бер сәгать чамасы вакыт эчендә ярты капчык калды. Алъяпкыч кесәсендә бер, ике, өч тиенлек тимер акчалар шактый җыелды. Аның янәшәсендәге әбинең дә сәүдәсе ярыйсы гына бара — куырылган көнбагыш тутырылган капчыгы шактый кечерәйде.

Сания: «Хәсән абый ашыкмаса ярар иде», — дип уйлап кына куйган иде, алар янында ике малай пәйда булды. Берсе, озынрак буйлысы, көнбагыш сатучы әби каршына тукталды. Әбинең сукрануына игътибар да итеп тормастан, акча-фәлән биреп тормыйча гына уч тутырып көнбагыш алды. Икәүләшеп Сания белән Рамил янына килеп бастылар.

«Нәрсә сата икән бу кызыкай?» диптер инде, шактый вакыт сәерсенеп карап тордылар.

Ул арада Саниянең бер абыйга юа сатып җибәрүен, акчасын алъяпкыч кесәсенә салып куюын шәйләп алган малайларның кечкенә буйлысы, ниһаять, телгә килде:

— Син нишләп монда печән сатып утырасың? Каян килдең?

Саниянең күңелен курку биләп алды.

— Телеңне йоттың мәллә, кызый?

Монысын озынчарак буйлысы сорады.

Бөтенләй пошаманга төшкән Сания, ярдәм эзләп, як-ягына каранды. Якын-тирәдә ник бер кеше булсын! Тегеләр дә кеше-фәлән юк вакытны көтеп торганнар, күрәсең.

Кайчан җитешкәндер: әле генә янәшәдә кызган көнбагыш сатып утырган әби дә, ярылаш бушаган капчыгын җилкәсенә элеп, базар эченә кереп бара иде.

Сания бөтенләй коелып төште. Алда үзен ни көтәчәген чамалап, чарасызлыктан күзләренә яшь килде.

— Кара, брат, бу чәчби безне гүпчем кешегә санамый бугай, — диде кыска буйлы малай, иптәшенә таба борылып. — Җавап бирергә исәбендә дә юк.

Озын буйлысы Саниянең каршысына ук килеп басты. Җиргә, яулык өстенә тезеп куелган үлән «бәйләм»нәренә күрсәтеп, кабат тыныч кына:

— Нинди печән бу дип сорыйлар синнән, — дип сорады.

— Юа, — диде кыз, карашын җирдән алмыйча гына.

— Юа? — Малай сәерсенеп куйды. — Кем юа, нәрсә юа?!

Икәүләп шаркылдап көләргә тотындылар. Аларның да юа ашап караганнары юк иде, күрәсең.

— Ашап карыйсызмы соң?

Ниндидер авылдан килгән бер кызый тарафыннан мондый мыскыллау сүзләре ишетербез дип башларына да китермәгән «шәһәр малайлары» бер мәлгә аптырашып, тынып калдылар.

«Ниндидер печән ашатмакчы бит әй! Юк, мондый мәсхәрәне болай гына калдырып булмый...»

— Син нәрсә, кызый актыгы, бездән көләргә уйладыңмы? Сыер мәллә без сиңа?

Шул сүзләр белән озын буйлы малай иске чабаталы аягы белән Санияне күкрәгеннән этеп җибәрде. Кыз, артында торган капчыкка сөрлегеп, аркасына егылды. Ул да булмады, малайлар Саниянең алъяпкыч кесәсеннән чирәм арасына тиен акчалар тәгәрәшеп төшкәнен күреп алдылар.

Алардан куркып, Рамил елый башлады.

— Оһо, бу спекулянтның акчасы да бар икән әле, — дия-дия, кыска буйлы малай коелган акчаларны чүпләргә тотынды.

Чирәм арасындагы акчаларны җыеп бетереп кесәсенә салып куйгач, һич көтмәгәндә, Саниянең өстенә сикерде.

— Каяле, бай кызый, безнең белән дә уртаклаш әле, — дип сөйләнә-сөйләнә, Саниянең карышуына карамастан, кулын аның алъяпкыч кесәсенә тыкты.

Сания аны бөтен көченә этеп җибәрде. Алъяпкыч кесәсен ерта язып тартылып чыккан учта шактый акча бар иде. Ул тиеннәр дә малайның чалбар кесәсенә кереп чумды...

— Аһ, анаңны!..

Йодрыкларын селки-селки, базар капкасына Хәсән абый якынлашып килә иде.

Талаучы малайларны мизгел эчендә җир йотты.

Юа сатып җыелган акчаның шактый өлешен үзләштерергә өлгергән булып чыкты теге малайлар. Сания, күз яшьләренә буыла-буыла, калган тиеннәрне барлап, санап карады. Бер сумга якын калган. Монысы да авыл өчен зур акча, билгеле, шулай да...

Ничек кирәк, шулай тынычландырды балаларны Хәсән абый. Тагын бер сәгать чамасы сатып утырдылар да, бар булган әйберләрен җыйнап, кайту ягына таба юл алдылар...

Юл буе уйланып кайтты Сания.

«Әйтергәме инде бу малайлар турында әнигә? Әйтсәм, башка җибәрмәячәк, әйтмәсәм...»

— Син, кызым, моннан соң болай сак бул инде, — диде Хәсән абый, Саниянең уйларын укыгандай. — Күреп-сизеп торам: икеләнеп калдың.

Бер караганда, монда йөрсәң, күпме генә булса да, акчалы буласың. Миңа да комачауламасые ул. Вакыт кына җитми шул. Ә икенче яктан, шул вакыт мин килеп җитмәсәм?! Шул шул, дөньясында әрәмтамак, кабахәт бәндәләр дә җитәрлек. Ятим баладыр дип тә, ачлыктан интегәдер дип тә тормыйлар...

Сания бер сүз дә әйтмәде. Капчык төбендә калган юа белән «тамак ялгап» алгач та, өлкәннәр шикелле, ат арбасына сузылып ятып йоклаган Рамилнең чәчләреннән сыйпап куйды.

— Ярар, — дип куйды Хәсән абый, үзалдына сөйләнгәндәй генә. — Берсекөнгә Рәкыя апаңны да алпарырмын. Бергәләп утырырсыз, яме, кызым. Зурларсыз булмый шул андый җирдә, булмый... Но-о, Йолдызкай...

Балаларының Мамадыштан шактый акча белән кайтуына Миңниса апа чиксез куанды. Сүзнең кабаттан Саниянең укытучы булу теләгенә әйләнеп кайтачагын чамалап булса кирәк, кызы биргән акчаларны, тиененә кадәр санап, кулъяулыкка төенләп, караватт астындагы әрҗәгә салып куйды.

— Кирәге чыгар, боерган булса, — диде ул. — Кызым, бик арымаган булсаң, Хәсән абыеңа кереп чык әле. Сезне Мамадышка алып барган өчен бәхилләми ярамас, чәйгә чакыр. Рәкыя апаң белән керсеннәр.

Мамадышта күргән-кичергәннәренең бөтенесен дә төкми-чәчми сөйләп бирергәме, юкмы дип баш ватып утырганда, «Хәсән» сүзе колагына иштелеп киткән Рамил бөтенесен бер мизгелдә хәл итеп тә ташлады:

— Хәсән абыйны яратам мин. Ул булмаса, тегендә... — диде дә тыелып калды. Нәни бала диген инде үзен, шундук сүзне икенчегә борып

та куйды: — Тырактырчы булырга тели икән ул. Үскәч мин дә тырактырчы булам, әни.

Ана күңеле сизмиме соң, Миңниса апаның йөзе шундук үзгәрде. Саниягә карап, саклык белән генә:

— Нәрсә булды Мамадышта? — дип сорады.

Саниягә шәһәр малайлары турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирергә туры килде. Үзе әнисеннән күзен алмады. Миңниса апаның йөзе күзгә күренеп каралып килде.

Хәсән абый шул вакытта килеп җитмәсә, балалары белән нәрсә булачагын күз алдына китерептер инде, бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Катып калгандай бераз басып торганнан соң, хәлсезләнеп, әкрен генә урындыкка чүгәләде.

— Юк, кызым, — диде ул, бераз тын гына утырганнан соң. — Башка барып йөрисе түгел. Акчасы да кирәкми, ачка үлмәбез әле, иншаллаһ.

Миңниса апаның тирән җыерчыклар белән әйләндереп алынган күзләреннән яшь тамчылары бәреп чыкты...

Икенче көнне Санияләргә кунаклар килде. Мамадыштан. Әнисенең туганнан туган Хәтимә апасы икән. Үзе белән ике баласын да иярткән.

Алар ихатага килеп кергәндә, Сания белән Рамил бәрәңге бакчасында чүп утыйлар иде. Капка төпләрендә җигүле ат күргәч, ишегалдына үзләре чыктылар. Һәм...

Күзләренә ышанмыйча торды Сания белән Рамил: ишегалларында Мамадышта аларның акчасын талап качкан малайлар!

Сания әнисе белән ике арада булган кичәге сөйләшүне исенә төшерде. Инде үзенә Мамадышта бәйләнүчеләрнең Хәтимә апа малайлары булып чыгуын да әйтсәң...

— Курыкмагыз, әләкләргә җыенмыйм, — диде ул, Мамадыш кунакларына каш астыннан сөзеп кенә карап.

...Әнисенең туганнан туган Хәтимә апасы, Саниянең Мамадышта уку теләге барлыгын белгәч, ике дә уйлап тормыйча:

— Миңниса, кызыңа торак эзләп баш ватма, бездә яшәр, — дип ычкындырды. — Минем Сафа белән Шәрип тә күз-колак булыр үзенә...

— И-и, Хәтимә апа. Сиңа һич кенә дә мәшәкать ясыйсы килмәгән иде бит...

— Күр инде, нинди мәшәкать булсын ди?! Үз туганыңа да булышмасаң тагын. «Сез — безгә, без — сезгә» дигәндәй. Авыр чакта безне коткарып калганыгызны онытасым юк...

* * *

Хәтимә апа телгә алган вакыйганы Сания дә яхшы хәтерли.

Караңгы төшеп килә иде инде. Кыз, Дүсмәт авылыннан, мәктәптән кайтышлый, еракдан ук үзләренең капка төпләрендә олаулар торуын күрде. Адымнарын акрынайтты. Өч кеше олаудагы капчыкларны ашыга-ашыга Санияләрнең ихатасына ташый. Якыная төшкәч кенә әтисен танып алды.

— Әти, нинди...

Кыз соравын биреп өлгермәде.

— Бар, кер, кызым, — дип бүлдерде аны әтисе, ярым пышылдап кына һәм, чираттагы капчыкны җилкәсенә күтәреп, мал абзарына кереп китте.

Миңниса апа да Саниянең соравын җавапсыз калдырды.

— Ярар, кызым, безнең эш түгел, ир-атлар үзләре карар, — диде дә, сарык тиресеннән

тегелгән җиңсез камзулын җилкәсенә элеп, тышка чыгып китте...

Әти-әнисенә ияреп керүче абый Миңниса апаның Мамадыштагы җизнәсе Галимулла булып чыкты. Сания аларның нәрсә турында сөйләшкәннәрен белми калды — өйгә керен, әле өсләрен чишенеп тә өлгермәгәннәр иде, әнисе аңа чишмәдән тиз генә су алып кайтырга куште.

Сания кайтканда, Галимулла җизнәсе өйдә юк иде инде. Өстәл уртасында самавыр җырлап утыра.

— Әйдә, кызым, бер чәйләп алыйк әле, — диде әтисе, Сания сулы чиләкләрен мич каршына китереп куйгач. — Аннан соң утын ярырга чыгасы булыр...

Гадәттәгечә, гөлҗимеш тамыры кайнатмасы эчәргә әзерләнгән Сания, әнисе ясап китергән чәйне тәмләп карагач, аптырап китте. Мондый хуш ис аңкып торган тәмле чәйне үз гомерендә бер генә тапкыр эчкән иде ул моңарчы. Хәтере ялгышмаса, әле Рамил энекәше туганчы ук. Әнисе аралыктан җәйләүгә салып кызыл билле прәннекләр дә алып чыгып алдына куйгач, шиге калмады: әле генә аларда кунак булган теге абый күчтәнәчләре булырга тиеш. Ул прәннекнең тәмлелеге! Мондый тәмле ризыкларның алар йортында түгел, авыл кибетендә дә булганын хәтерләми Сания.

Кызык инде: әле бүген иртән генә черек бәрәңге кәлҗемәсе дә эләкмәгән кыз, бай балалары кебек, кызыл билле прәннек ашап утыра!

Кунакның Галимулла исемле булуын, әнисенең Мамадышта яшәүче туганнан туган Хәтимә апасының ире икәнлеген белеп алгач, күңеленнән Галимулла җизнәсенә рәхмәт укы-

ды Сания. Шул ук вакытта бәгырен, бик аз вакытка гына булса да, шәһәр халкыннан көнләшү хисе тырмап алды...

Кичке караңгылыкта Галимулла җизнәсенең нинди капчыклар алып килүен һәм ни өчен аларны мал абзарына ташуларын барыбер аңламады Сания. Аптырагач, күңелендә борчу уяткан бу сорауга җавап эзләп, икенче көнне абзарга да кереп карады. Тик сәер: күпме генә эзләсә дә, ул капчыкларны тапмады.

Шактый вакыт узгач кына, ул әлеге серле вакыйганың төп сәбәбен белде. Әтисе белән әнисенең сөйләшкәне очраклы гына колагына эленеп калды.

Бик салкын иде ул көннәрне. Гомер булмаган хәл: әтисе инде икенче көн рәттән күлдән бер балык та тотмыйча кайтты.

— Әллә Хәтимә апаларның запасыннан алабызмы соң бераз? Соңыннан өстәп куяр идек әле...— дигән иде Миңниса апа.

— Юк, — диде Мөнир абый, кискен каршы төшеп һәм, бу сөйләшүгә нокта куйганын аңлатып, урыныннан кузгалды. — Көн дә болай булмас әле, иншаллаһ.

Сүзнең теге төндә мал абзарына ташылган капчыклар турында барганлыгын Сания дә аңлады. Әтисе белән әнисенең үзара сөйләшкәнен сәерсенеп тыңлап утырган кызларыннан һаман да сер яшереп утыруның кирәге юк дип тер инде, Миңниса апа Саниягә дәште:

— Теге вакытны аптырагансыңдыр, кызым. Мамадышта бик каты тикшерү башлангач, Хәтимә апалар кибетләрендәге товарны яшерми булдыра алмаган. Бердәнбер туганнары бит, безгә алып кайтмыйча, кая куйсыннар инде тагын? Ходайга мең шөкер, моңарчы безгә сәвитләр тимәде...

Шулай да капчыкларның төгәл кайсы урынга яшерелгәнен әйтергә ашыкмады Миңниса апа. Сания моны шактый вакыт үткәч, дөньялар бераз тынычланып, Галимулла җизнәсе яшерелгән малын кире алып китәргә дип кайткач кына белде. Бактың исә ике дистәгә якын тутырылган капчык икмәкне, мал абзарының бер кешенең дә уена керми торган урынына, идән астындагы тирән базга күмеп куйган булганнар!

Саниянең күңел түрендә исә, борын төбендә шулкадәр икмәк була торып, ачлыктан үзләре ни дәрәҗәгә җитсәләр дә, аннан бер уч ярма алмыйча түзгән әти-әнисенә карата гаҗәпләнү катыш хөрмәт хисләре көчәйде. Бу вакыйгалардан соң байтак вакытлар узгач та, кечкенә энесе Рамил белән аралашканда, тормышка чыгып, үз балалары тугач, аларга да әледән-әле горурланып сөйләде ул бу хакта...

* * *

«Бар бит, шөкер, дөньяда игелекле кешеләр», — дип уйлап куйды Сания, Хәтимә апаның сүзен ишеткәч, һәм, ни дип җавап кайтарыр икән дигәндәй, әнисенә текәлде.

Миңниса апа, башта бераз икеләнебрәк торгандай итсә дә, озак карышмады:

— Барып карасын инде алайса. Булмаса, кайтыр...

Саниянең куанычы эченә сыймый иде. Шатлыгыннан күзләре дымланды. Аның бу халәтен башкалар күрмәсен диптер инде, тиз генә өстәл артыннан торып, тышка чыгып йөгерде.

Ишегалдында энесе Рамил, гадәттәгечә, үзалдына нәрсәдер сөйләнеп, уйнап йөри иде. Сания, өйдән атылып чыгуга, энесен кочып алды:

— Ур-ра, Рамил, мин тиздән Мамадышка китәм! Укырга!

Рамил апасының ни өчен шулхәтле шатланганын аңларлык дәрәҗәдә түгел шул әле:

— Ычкындың мәллә, кит әле моннан, — дип кычкырды ул, читкәрәк талпынып.

Сания куанычыннан үз-үзен кая куярга белмәде.

— Их син, юләр малай, — дип, Рамилне кабат кочагына кысты ул. — Аңлыйсыңмыни син?!

— Нигә аңламаска?! Мамадышка китәм дисең бит. Шунысы гына кызык, каядыр укырга барам дип кем шулай шатлана инде?! Монда авыл мәктәбе дә туйдырды әле...

Сания үзен һаман да аңлый алмаган кечкенә энесенә үпкәләгәндәй итте:

— Әй, синең белән сөйләшеп торган мин юләр... Башың яшь шул әле.

Шулай диде дә, кырт борылып, өйләренә кереп китте...

* * *

...Мамадыш шәһәрендәге педагогия училищесына керү өчен имтиханнарга кадәр кабул итү комиссиясендә әңгәмә-конкурс үткәреләсе икән.

Документлар тапшырырга килгән көнне танышкан кызлар, училищега керү өчен имтиханнар түгел, иң беренче чиратта шушы әңгәмә әһәмиятле, дигән иде. Бу көнне көтә-көтә, Сания пошаманга төште.

«Күрше авыл мәктәбенә йөреп алган белем генә җитәрме? Керә алмыйча кире кайтырга туры килсә? Йа Ходай, ояты ни тора!»

Саниянең күз алдына күрше Дусмәт авылына йөреп укыган вакытлар килде...

— Каян алыйм мин сиңа шулкадәр акча?!

Үпкәләсәң дә, үпкәләмәсәң дә, чарам юк, кызым. Бүтән укыта алмыйм мин сине. Йортта ярдәмче дә кирәк...

Миңниса апа кызы Саниягә ул чагында да нәкъ шулай дигән иде...

Билгеле, кечкенә чагыннан ук балаларын мөмкин кадәр күбрәк укырга өндәп килгән әнисе авызыннан мондый сүзне ишетүе җиңел булмады Саниягә.

«Шулкадәр акча!»

Күрше авылга йөреп укый торгач, өч ай эчендә ике сумга якын акча киткән икән шул. Дөрес, әрәмгә дә туздырылмады үзе — иптәш кызыннан яртылаш чиста дәфтәр, бер савыт язу карасы сатып алырга туры килде. Беркөнне ятимнәр йортына ярдәм өчен дип акча җыйганнар иде, бирми кая барасың...

Ничек кенә булмасын, шунысы хак: Саниягә азмы-күпме белем бирәм дип, гаилә бюджеты ике сумга кимеде. Ә ул акчаны табуның никадәр авыр икәнлеген Сания үзе дә яхшы аңлый.

Ничек итсә итте Сания, көнаралаш кына булса да дәресләргә йөрде, укуын бөтенләй ташламады.

Ике арадагы җиде чакрымны үткән чагында сукмак урман читеннән уза. Юлда тап булган корыган үләннәрне, көздән калган вак кыргый алмаларны янчыгына тутыра барды. Сирәк кенә булса да, әнисеннән өшегән черек бәрәңге кәлҗемәсе дә эләккәли иде. Өйдә киптерелгән җиләк-җимешләр дә бар барын, тик аларын әнисе бирми — «әҗәл даруы» гына шул. Ярый әле энесе Рамил белән алабута орлыгын байтак җыйганнар иде, әнисе шул орлыктан пешергән «ипи»нең тәмлелеге!

Баерак ата-аналы балалар һәрвакыт шушы ипине ашап карарга кызыга торганнар иде.

Үзләре исә бодай оныннан пешерелгән ипи белән сыйлыйлар.

Беркөнне үзе көн буена ач торса торды, бай кызларыннан алган ипи кисәген өйгә дә алып кайтты Сания. Төенчегендәге ипи сыныгын күреп, әнисе куркуга калды. Миңниса апаның күз карашында бер генә сорау ярылып ята иде: «Каян алдың?»

Сания әнисенә барысын да сөйләп бирде. Байларның алабута күмәченә кызыкканын, ялына-ялына сорауларын...

Миңниса апа бераз тынычлангандай итте. Шулай да канәгатьсезлеген күрсәтми кала алмады.

— Кызым, бу гамәлең, билгеле, гөнаһ эш түгел, — диде ул, тирән сулыш алып. — Тик башка болай эшләмәсәң яхшырак булыр. Сиздермә, сер бирмә, безнең мохтаҗлыкта яшәгәнне белмәсәләр, кулайрак булыр. Бабаңның ни өчен сөргенгә озатылуын, әтиеңнең гомер буе кагылу-сугылуын беләсең. Аллам сакласын, явыз телле бәндәләр әйтер тагын: «Кеше алдап икмәк җыя», — дияр. Хурлыгы ни тора?!

* * *

Нәселле балыкчы иде алар. Авылда бер үк вакытта мулла вазифаларын башкаручы бабасы Сабир да, әтисе Мөнир дә болындагы күлләрдән балык тотып кайталар, беразын Мамадышка алып барып балык заводына тапшыралар, планнан артып калганын авылдашларына бушлай өләшә торганнар иде.

...Көннәрдән бер көнне, иртәнге якта, Саниянең әнисе ишегалдында тавыкларга җим биреп йөргән бермәлне, капка төбенә җигүле ат килеп туктады.

— Тр-р, малкай!

Ул да булмады, капканы тибеп кенә ачып, ишегалдына өч ир-ат килеп керде. Берсен шундук танып алды Миңниса — Миңнехан малае Харис. Яшь колхоз бригадиры. Әле кайчан гына Миңнисаның үзен озатып йөргән егет. Кыз үзе дә битараф түгел иде мәһабәт гәүдәле бу егеткә. Тик Миңнисаның әтисе аларның бергә булуларына каршы төште. Халык арасындагы имеш-мимешләргә караганда, «Миңниса белән безнең араны бозсаң, башыңа җитәм!» — дип янаган булган Харис Сабир абыйга.

Ул вакыйгадан соң байтак вакыт узгач, Миңниса күрше егете Мөниргә кияүгә чыкты...

— Сабир абый өйдәме? — диде Харис, Миңнисаның күзләренә туры карарга базмыйча гына. — Чыксын әле.

— Әти кулгә төшеп киткән иде, төш җитәрәк кенә кайтыр инде. — Миңниса Харисның каршына килеп басты. — Нишләп минем белән исәнләшми дә башладың син?

Егетнең бит алмалары кызарды.

— Әтиеңнән сора, — дип мыгырдады ул.

— Мөнир дә өйдә юкмы әллә? — дип сорады «кунаклар»ның берсе, сүзгә кушылып.

Миңнисаның карашы усал кыяфәтле абыйга күчте. Читтән килгән кеше булырга охшый, авылдашлары арасында кайчан да булса мондый төксе адәм булганлыгын хәтерләми Миңниса.

— Соң, ул да әти белән китте инде...

«Кунак» нәрсәдер мыгырдап аяк астына төкерде. Миңнисаның күңелен мизгел эчендә ниндидер курку хисе өтеп алды.

— Ярар, — диде «кунаклар»ның икенчесе коры гына. — Төшке аш вакытын чамалап килербез. Киттек әйдә. Колхоз рәисе янына кереп, без дә тамак ялгап алыйк...

Әтисе белән ирен бу кешеләр нигә эзләгәнен Миңниса аңламый калды. Балык сорап йөриләр дисәң, кыяфәтләре, үз-үзләрен тотышлары бер дә андыйга охшамаган.

«Кунаклар» капка төбенә чыгып атка утыруга, Миңниса өйгә ашыкты. Бәлки, әнисе берәр нәрсә белә торгандыр?

Сабир бабай кулга алынганнан соң, Мөниргә дә көн бетте. Иртәгесен үк Мамадышка, балык заводына чакыртып, эштән азат иттеләр, өйләрендә өч көн буе тентү үткәрделәр. Өйнең астын өскә китереп бетерсәләр дә, теләгән әйберләрен таба алмадылар, күрәсең, ахыр чиктә, аты-юлы белән сүгенеп, тентүне туктаттылар.

Сабир бабай әлеге китүеннән кире кайтмады. Авыл халкы арасында аны Мамадышта күргән кешеләр дә булган — Саниянең бабасын һәм тагын берничә кешене, пароходка утыртып, каядыр алып киткәннәр.

Эшсез калган Мөнир кайларга гына барып карамады. Тик, кем ишеген генә шакыса да, ачык чырай күрмәде ул. «Халык дошманы» буларак кулга алынган Сабирның кияве Мөниргә колхозда да, башка урында да эш табылмады.

— Әнисе, балалар, әйдәгез, киңәшләшеп алыйк әле, — диде көннәрдән бер көнне Мөнир абый, кичкырын гаиләсен җыеп. — Алга таба болай яшәп булмый.

Миңниса апа нәрсә әйтә ала инде — биләүгә төрелгән кечкенә Рамилне күкрәгенә кысты да сагаеп кына Мөнире үзе нәрсә әйтер икән дип көтте.

Гаилә башлыгының, чынлап та, бер нияте бар булып чыкты.

— Миңа авылдан китәргә туры килер, мөга-

ен, — диде Мөнир тыныч кына. — Син моңа ничек карыйсың, Миңниса?

Саниянең әнисе ни әйтергә дә белмәде. Авылда иренә көн беткәне күренеп тора. Кая барып сугылырга белми аптырап йөреп, чиргә сабышты бит инде.

— Соң, әтисе, башка әмәл юктыр дисеңмени инде? — дип кенә җавап кайтарды хуҗабикә һәм чарасызлыктан үксеп елап җибәрде.

Гаилә башлыгы шактый вакыт сүзсез утырды.

— Юк, башка чара юк!

— Ә балалар? Аларны төяп кая барып була соң хәзер?

Мөнир торып басты.

— Мин, әнисе, үзем генә китим дигән идем...

Көтелмәгән сүзне ишетеп, Миңниса тораташтай катып калды.

— Ничек инде? — Хуҗабикәнең бөтен тәне калтырап куйды. — Тукта, уйла әле рәтләп, без нишләргә тиеш монда синсез?

— Берәр кая барып урнаша алсам, соңрак сезне дә кайтып алырмын дим...

Миңниса тагын тынып калды. Яулык чите белән күзләрен сөртеп алды да, сүзсез генә торып, аралыкка кереп китте. Бераздан кабат аның сулкылдаганы ишетелә башлады.

— Әнисе, елап берни дә майтарып булмый. — Мөнир хатыны ягына таба ике адым атлады. — Китәргә булдым инде. Рәнҗеп калма, зинһар. Мин яныгызда булмасам, сезне дә бик битәрләмәсләр...

Саниянең әтисе, үз теләге белән күрше авыл ирләренә ияреп, Сабирны һәм тагын миллионлаган әллә кемнәрне ирексезләп җибәргән Ерак Көнчыгыш якларына, Сахалинга ук китеп барды...

* * *

«Кулак оныгы», «хәерче» кебек сүзләрне еш ишетергә туры килде Саниягә. Ничек кенә авыр булмасын, җидееллык мәктәпне тәмамлап чыкканчы укырга йөрде. Укытучылар да, көнаралаш кына килеп йөрүенә карамастан, тырыш кызны һәрвакыт мактап тордылар. Көндәлеген бишле билгеләре генә бизәде.

«Авыл авыл инде ул, аның мәктәбендә дә кайбер фәннәрдән укыту чамалы гына булгандыр, — дип үзалдына сөйләнде Сания, һаман әңгәмә-конкурс турында уйланып. — Кул астында өстәмә китаплары да юк бит аның, ичмасам».

Сафа белән Шәрип теге вакытны авылга кунакка кайткач үзләрен «сатмаган» Саниягә булдыра алганча ярдәм кулы сузарга тырыштылар. Бу юлы да көне буе уйланып утырганын шәйләп алган Шәрип аның янына килеп басты.

— Нәрсә, сеңелкәш, борчуларың бар мәллә? — дип сорады ул Саниядән.

Кыз сискәнеп китте.

— Уф, син икәнсең әле. Куркыттың, — диде Сания, авыр уйларыннан беразга арынып. Аннары, үзалдына сөйләнгәндәй, тыныч кына дәвам итте: — Конкурстан куркам мин. Укырга керергә теләүчеләр хәтәр күп икән. Үтеп булырмы, юкмы?..

— Сине дә алмасалар инде, — диде Шәрип, кызны тынычландырырга теләп. — Гел бишлегә укыган кыз бит син.

— Аңа гына карамыйлар ди шул анда. — Сания авыр сулап куйды. — Рус телен шәп белергә кирәк ди. Ә мин русча иркенләп сөйләшә дә алмыйм... Их, һичьюгы, грамматика кагыйдәләрен өйрәнергә китабы да юк бит аның...

Икенче көнне үк Шәрип Саниягә кайдандыр рус теле грамматикасы буенча дәреслек алып кайтып тоттырды.

— Мә, балавыз сыгып утырма монда, иптәш малайның апасы биреп торды. Вакытың бар, өйрән кагыйдәләреңне!..

Конкурс көне килеп җитте. Әңгәмәгә беренче булып керде Сания.

Зур гына залда рәт-рәт булып өстәл-урындыклар тезелеп киткән. Алгы якта тагын бер киң өстәл. Өч кеше утыра.

— Кто ты? — дип сорап куйды кырыс кыяфәтле бер абый, Сания керер ишекне ябуга.

Кыз, каушаудан телен көч-хәл белән әйләндереп, исем-фамилиясен әйтте.

Өстәл артындагылар бер-берсенә карашып алдылар. Залда тынлык урнашты.

— Ну, что молчишь, рассказывай, — диде теге кеше кинәт.

Инде тынлыкка күнегеп, үз-үзен кулга алырга өлгергән Сания көтелмәгән сораудан сискәнеп китте.

— Аңламадым, нәрсә сөйләргә соң? — дип, комиссия әгъзаларының күзенә төбәлде.

— Рассказывай, девушка, зачем ты именно здесь? Что ты хочешь от нас?

«Ничек инде, минем монда укырга керергә теләвем көн кебек ачык бит. Нишләп мыскыллыйлар болар мине?» дигән уй йөгереп узды кызның башыннан. Ачуы кабарды, бер-ике чәнечкеле сүз әйтеп, ишекне шапылдатып чыгып китәргә дигән фикер дә борынлый башлаган иде, тыелып калды.

Бар булган кыюлыгын җыеп, кырыс кыяфәтле абыйның күзләренә туп-туры карап:

— Хочу стать учительницей. Я знаю, что

здесь готовят хороших учителей, — дип сөйли башлады.

Шушы беренче очрашуда ук мондагы укытучыларның яхшы педагог булуларына ышанычы ялап алгандай юкка чыкса да, салам кыстырмыйча мөмкин түгел иде. Комиссия әгъзалары күңеленә дә аның җавабы хуш килде, күрәсең, өчесенең дә йөзләре яктырып киткәндәй тоелды Саниягә.

Чиратлашып, сорау арты сорау бирделәр. Сания исә тотлыкмыйча, салмак кына җавап бирер барды.

— Заметно, что знаний у тебя достаточно, — диде, ниһаять, комиссия рәисе. — Давай, девушка, теперь поговорим о твоем происхождении. Кто твои родители?

Ни өчендер бу сорауны ишетүгә, кинәт Саниянең бит алмалары кызарды.

«Нәрсә сөйләргә? Бабай, әти турында дөресен әйтергәме? Ничек кабул итәрләр икән?»

— Что молчим опять?

Ата-бабасының нәселле балыкчылар булганлыгын сөйли башлаган Санияне комиссия рәисе бүлдерде:

— А вот здесь указано, что твой дед был репрессирован как враг народа, — диде, кулындагы бер кәгазьне селкеп. — Что ты на это скажешь?

Сания кабат каушап, икеләнеп калды. Тынлыкны комиссия рәисе бозды:

— Ну?

Бабасының һәм әтисенең чынлыкта да балыкчы булуын кабатлады Сания. Көннәрдән бер көнне бабасын, өйдәге туганнарына аңлатыпнитеп тормыйча гына, ихатага килеп кулга алулары, әтисенең Себер якларына эшкә чыгып китүе турында белгән кадәресен сөйләп бирде.

Залда кабат тынлык урнашты. Бераздан Саниягә чыгып торырга куштылар. Ярты сәгать чамасы вакыт эчендә училищеда укырга теләүче биш-алты үсмер комиссия аркылы үтеп өлгерде. Ниһаять, аны да кабаттан залга чакырдылар.

— Сеңлем, бик озак киңәшкәннән соң, без шундый нәтиҗәгә килдек, — диде комиссия рәисе. — Әзерлегең начар дип әйтеп булмый, тик әлегә җитәрлек түгел. Особенно рус теленнән. Училищеда укуы гаять авыр булачак. Аннан соң, бабаңның биографиясе дә... Кыскасы, кабул ителү-ителмәү мәсьәләсе бер атнадан гына төгәл билгеле булыр...

Саниянең күңелен мизгел эчендә шомлы тойгы биләп алды. Күкрәк турын нәрсәдер яндырып үткәндәй булды, күз аллары караңгыланып китте.

— Нигә... хәзер үк әйтмисез? — Сания аздан гына кычкырып җибәрмәде.

— Син аңларга тиеш, бала-чага түгелсең, — дип тынычландыргандай итте аны комиссия рәисе. — Син генә түгел бит монда. Башта калган претендентларны да тикшереп чыгарга тиешбез...

Күзләреннән бәреп чыккан кайнар яшь бөртекләрен комиссия әгъзалары шәйләп алганчы дип, залдан тизрәк чыгып китүне хуп күрде Сания...

«Димәк, эш әле монда конкурста да түгел икән, — дип уйланды ул үзалдына. — Бабайның биографиясен катыштырмакчылар. Юкка гына азапланам микәнни соң монда керәм дигән булып, йа Ходай? Нишләргә? Авылга кайтып китәргәме, бер атна көтәргәме? Ә аңарчы ничек яшәргә?..»

«Ничек яшәргә?» дигән сорауны үз-үзенә бик

тә урынлы куйды Сания. Барысына да Хәтимә апа сәбәпче. Беренче көннәрдә бик тә кунакчыл, төче телле тоелган хуҗабикә көннәрнең берендә, алмаштырып куйдылар диярсең, кинәт үзгәрде дә куйды. Үзара сөйләшкәндә-аралашканда моңарчы тоемланган ягымлылыкның, ихласлылыкның ни сәбәпледер әсәре дә калмады.

Хәтимә апаның үзенә карата мөнәсәбәте кискен үзгәрүнең сәбәбен һич кенә дә төшенә алмады Сания. Ә көннәрдән бер көнне, Хәтимә апага күптәнге ахирәте кич утырырга килгәч...

Бераз авыртып торгач, вак-төяк өй эшләрен башкарып чыкты да, аз гына булса да ятып торырга уйлаган иде. Хуҗабикә әллә Саниянең өйдәлеген онытып җибәрде, әллә ул ишетсен өчен махсус әйтте. Бу сүзләр соңгы арада борчыган сорауларга төгәл җавап табарга ярдәм итте.

Баштарак тормыш-көнкүреш, гаилә хәлләре турында сөйләшеп утырдылар карчыклар. Дөресрәге, хуҗабикәнең ахирәте сөйләде, ә Хәтимә апаның ара-тирә генә «әйе», «менә малай» дип кыстырып куйганы гына колакка ишетелде. Хуҗабикәнең башка чарасы юк иде шул: хәле ахирәтенеке кебек мактанырлык, авыз тутырып сөйләшерлек түгел — тормыш терәге, Галимулласы, шәһәр уртасындагы кибете ябылгач, күпләп акча эшләү нияте белән, хатыны һәм ике баласын Мамадышта калдырып, Урта Азия якларына чыгып китте. Сирәк-мирәк кенә хаты, посылкалары килеп торса да, аның кайчан да булса бөтенләйгә яннарына кайтырына өметләнми дә Хәтимә апа.

— И ахирәткәем, әйдә, сөйләшмик әле шулар турында. Ир-атны җенем сөйми. Урамнан барганда корсакларын киереп, ирләрен култыклап йөрүче хатыннарны күрсәм дә үземне кая

куярга белмим. Мескеннәр, минем кебек язмышка дучар булачакларын беләмени алар?!

Ахирәте сүзне Хәтимә апаның авырткан темасыннан читкәрәк алып китү ягын карады.

— Синдә бит әле кунак та бар. Сания ничек соң, булышкалыймы, ичмасам?

Шушы сорауны гына зарыгып көткән диярсең, Хәтимә апа төкерекләрен чәчә-чәчә сөйләргә тотынды:

— Булышкан ди сиңа! Әрәмтамак кына бит ул! Артык кашык. Беренче көннәрдә вак-төяк йомышларны үти иде әле, ичмасам. Хәзер бетте, ник бер кыл кыймылдатсын. Көне-төне китап укуын белә. Прафисыр булырмын ди торгандыр инде... И-и, ахирәткәй, белмисең генә, безнең бөтен нәселгә тап төшерде бит аның бабасы. Шул кулак аркасында минем әти дә күпме кыен ашады. Ник ризалаштым икән, ичмасам шул кызны үз йортымда торарга. Кем генә тарткандыр телемнән. Кунакка кайткач, әллә нинди төче сүзләр әйтелә инде ул. Миңниса шуны чынга алды бит.

— Ну, гел синдә тормас әле, боерган булса. Кердеме соң инде училищега?

— Тагын бер атна-ун көннән генә билгеле була, дигәние. Белмим инде, кулак оныгын алырлар микән, ай-һай. Нишләргә дә белгән юк, тикгомалга кеше баласын тагын ун көн буе ашатып яткызасы да килми бит, ахирәткәй. Үземнең ике айгырыма да муеннан кирәк әле монда...

Никадәр генә белемле, сәләтле булса да, училищега керү мәсьәләсендә бабасының биографиясендәге «кара тап»ның ерып чыкмаслык саллы каршылыкка әверелгәнлеген яхшы аңлый иде Сания. Тик «өметсез — шайтан гына» дигән-

дәй, күңеле моңарчыниндидер могҗиза көтте: «Бабай ялгышлары өчен мин җавап тотарга тиеш түгел бит!..»

Училищедан кайтып барышлый, Сания базарга сугылып чыгарга булды. Авылдашларын очратып, алардан күңелсез хәбәр ишетте: әнисе, чишмәгә суга барган җиреннән таеп егылып, аягын имгәткән.

Сания конкурс нәтиҗәләрен көтеп тормаска булды. Икенче көнне үк училищега барды да, бөтен кешене аптырашта калдырып, документларын кире алды.

Хәтимә апасына карата туган нәфрәтен дә яшереп кала алмады. Барлы-юклы әйберләрен төйнәп куйды да аш бүлмәсендә мәш килүче Хәтимә апа янына чыкты.

Хуҗабикә Саниягә кырын күз белән генә карап куйды да, «Тагын нәрсә кирәк моңа миннән?» дигән уйга килептер инде, үзалдына нәрсәдер мыгырданып алды.

— Хәтимә апа, — дип тыныч кына башлады сүзен Сания. — Мине үз өеңдә яшәткәнең өчен рәхмәт сиңа. — Хуҗабикә сагаеп калды. Саниянең Хәтимә апасына беренче тапкыр «син» дип дәшүе иде бу. — Сиңа әйтәсе сүзем бар, Хәтимә апа, — дип дәвам итте кыз. — Нигә син... теләсә кемгә минем турыда пычрак сөйлисең ул?

Хәтимә апа аның тарафыннан мондый сүзләрне көтмәгән иде, берни аңламаган кыяфәттә Саниягә карап торуында булды. Кыз, хуҗабикәнең эченә корт төшкәнен сиземләсә дә, уйлаганын әйтеп бетерергә кирәк тапты.

— Синнән берәр нәрсә сораганым булдымы? Нишләп мине әрәмтамак дип атыйсың? Җитмәсә, кеше алдында. Өй эшләреңне эшләп барам... Шушы гомер үз йортыңда яшәтеп,

хәтта чәй өстәленә чакырганың да булмады. Аңа үпкәләмим. Бик беләсең килсә, хәтәр нык ачыккан вакытларымда да өстәлегездәге бер телем ипиегезне авызга алмадым мин... «Кулак», имеш. Шул «кулак» сине, синең иреңне саклап калып Себер китте... — Саниянең күзләре яшьләнде. Бәгыреннән рәнҗүле сүзләр ташып чыкты. — Хәтта тавыкларга чыгарып ташлаган бәрәңге кабыкларыңны да ашарга батырчылык итмәдем... Ярый әле ашамаганмын, Ходай саклаган үземне. Юкса хәзер аны да кире чыгартыр идең... Ник мине шулай рәнҗеттең?..

Моңа кадәр тыныч холыклы булып күренгән кыз авызыннан бу сүзләрне ишетермен дип һич башына да китермәгән иде хуҗабикә, тәмам югалып калды. Җавап итеп нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачкан гына иде, Сания төенчеген алды да, ишекне шапылдатып ябып, урамга чыгып йөгерде...

* * *

— И Гаяз абый, нихәл итәсең инде, туганыбыз бит. Ничек язмыш кочагына ташламак кирәк?!

— Да-а, — дип сузды Гаяз абый. — Булса да булыр икән үпкә тота белми торган кешеләр! Синең урында башка берәү булса, билләһи...

— Әллә кайчан булган нәрсәләр өчен үпкә, үч саклап ни мәгънә инде, бер карасаң? Заманасы шундый булгандыр инде. Кем генә ялгышмас... Аның каравы бүген, Ходайның биргәненә меӊ шөкер, гөрләп яшибез, Гаяз абый. Шатланып туя алмыйм. Армиядән гарипләнеп кайтса да, гомер буе көтүче генә булып эшләсә дә, Нурулла белән биш бала үстереп кеше иттек. Төрлесе төрле якта яшәсә дә, атна-ун көн

саен кайтып, хәлләребезне белешеп, хуҗалыкта ярдәм итеп китәләр. Исән генә булсыннар инде... Ә Хәтимә апа янында беркеме дә юк бит хәзер. Галимулла абый теге китүеннән кайтмады. Бер малае былтыр гына вафат булды, икенчесенең кайдалыгын белүче юк... Ничек ташлыйсың инде аны?

Гаяз абый аңа сокланып карап торды.

— Бигрәк изге күңелле син, күрше, — диде ул һәм, бераз тормыш-көнкүреш хакында гәпләшеп алгач, хушлашып, Саниягә соклануын яшермичә, үзалдына сөйләнә-сөйләнә китеп барды...

# Сабантуй

Кайчандыр бала чакта сыйныфташлары белән үзләре утырткан яшь наратларга тотына-тотына Маһуб тавының иң биек җиренә менеп җиткәнче, берничә мәртәбә туктап хәл алырга туры килде аңа.

«Гомер дигәнең шылт та иттмичә узып китә икән шул, — диде ул, көрсенеп. — Ә бит мондый текә тауларга да йөгереп кенә менә торган идек. Их-х...»

Ул яшел чирәмгә сузылып ятты да зәп-зәңгәр күк йөзендә салмак кына сәяхәт кылучы ак мамык-болытларга текәлде. Кинәт кенә кемнедер сөзәргә әзерләнгән үгезне хәтерләтүче бер болыт артыннан ялт итеп сикереп чыккан кояш нурлары күзләрен йомарга мәҗбүр итте. Ир, йөзен учлары белән каплап, бармак араларыннан гына аска, авыл тарафына күз ташлады һәм... үзенең бу сәер кыланмышыннан кызык табып, ихластан көлеп җибәрде. Янәшәдәге нарат ботагына кунып, аны күзәтеп утырган саескан пырхылдап очып китте. Аңа күрше агачлардагы кошлар кушылды.

Бераздан әйләнә-тирә тагын тынып калды. Маһуб тавының иң биек ноктасында әле дә елмаеп утыручы ирнең игътибары тулысынча тау итәгендәге авылга юнәлде.

Әллә кайда, авылдан биш чакрым ераклыктагы болын читендә утлап йөрүче сыер көтүе кул сузымында гына кебек. Тукта, монысы нәрсә? Анысы да сыер икән. Мөгаен, көтүдән качкандыр, кызу-кызу адымнар белән авылга таба атлый.

«Кызык хәзер, маллар көтүдән качып китсә дә, артыннан килүче юк. Уйлап та бирмиләр.

Ышаныр тапшыр син менә шул көтүчегә газиз малыңны. Ә бит элек...»

Әхәткә ун яшь кенә иде бугай әле. Нәкъ сабантуй көнне көтү чираты аларга туры килде. Еларга житешеп, сыерларны чират буенча көтү тәртибен эт итеп сүгә-сүгә, әтисенә ияреп, болынга төшәргә туры килде аңа. Бервакыт, төшке аш тирәсендә, биштәренә әнисе тыгып җибәргән түгәрәк ипине түшенә терәп кисәргә җыенган гына иде, күрше Гыйлемхан абыйларның мүкләк ала сыеры әйбәт кенә чирәм чемченеп йөргән җиреннән, корт чаккандай, тотты да инешкә сикерде.

Ул да булмады, чакыруга-кычкыруга игътибар итеп тормыйча, инешнең аргы ягындагы болынга, куе булып үсеп утыручы агачлыкка кереп тә китте.

— Бар, улым, алып кил әле шул мүкләкне, — диде Әхәтнең әтисе.

Малай, бата-чума дигәндәй, инеш аркылы чыкты да Гыйлемхан абый мүкләге кереп күздән югалган агачлыкка таба йөгерде.

Сыер хәтле сыер ничек чыга алгандыр бу чытырман аша, ә менә Әхәткә шактый газапланырга туры килде.

Агачлар, тал куаклары артында — киң печәнлек. Ләкин күршеләренең ала мүкләге монда юк иде. Берара уйланып, колакларын шомрайтып торганнан соң гына игътибар итте — печән таптамаган, сыер эзе бөтенләй юк!

— Тү-ту-ту, — дип чакырып карады Әхәт.

Сыер тавыш-тын чыгармады. Малайның күңелен шомлы уйлар биләп алды. Як-ягына карана-карана, әрле-бирле чабарга тотынды. Ләкин Гыйлемхан абыйларның мүкләге беркайда да күренмәде.

Әхәтнең күзләреннән яшь атылып чыкты.

Гарьләнерсең дә. Гомердә булган нәрсәме — Әхәткә бөтен авыл халкы үзләренең малларын ышанып тапшырган, ә ул... Ояты ни тора бит әле аның.

Малай, агач төбенә чүгәләп, үксеп елый башлады.

— Бәтәч, улым, нишләп балавыз сыгып утырасың монда? Нәрсә булды? — диде Әхәтнең әтисе. Шактый вакыт югалып торган улын эзләп килгән.

Малай тагын да катырак елый башлады.

— Әти, мин... ул сыерны... тапмадым бит... э-э-э...

Ата кеше, иңеннән авыр йөк төшкәндәй, ухылдап куйды.

— Ух, Аллага шөкер, бер-бер хәл булдымы әллә дип торам.

Әхәт, елавыннан кинәт туктап, әтисенә күтәрелеп карады. Әтисе, берни булмагандай, елмаеп тора.

— Ну, ничек инде? — диде ул, әтисенең шундый хәлдә дә тыныч кала алуына ихлас гаҗәпләнеп. — Гыйлемхан абыйга нәрсә дип әйтербез? Ул мүкләк өчен без җаваплы ла бүген.

Әтисе улын кочагына сыендырды.

— Маладис, улым, җаваплылыкны аңлый торган кеше булып үсәсең, — диде ул, үзалдына сөйләнгәндәй тыныч кына. — Үзеңнекен генә түгел, кеше малын да үзеңнекедәй сакларга кирәк... Әйдә киттек. Сыерлар ял итәргә ятты. Учак ягып, бәрәңге тәгәрәтеп алыйк. Мүкләк... син монда кереп китүгә үк кире чыкты ул. Кигәвен-мазар тешләгән булгандыр, чытырманлыкка сыртын кашырга гына кереп чыккандыр...

— Аh, мүкләк тәре!

«Шулай. Элек һәр кеше үз эшенә җаваплы карый иде. Ә бу сыерны бар дип тә белүче юк.

Ярый инде авылга таба атлый, сазлыкка, болынга түгел. «Сыер ашаган җиренә кайта ул» диләрме әле? Исән-имин генә кайтып җитсен...»

Әхәт, авыл тирәләрен күзәтеп утыра-утыра, көн сүрелүен сизми дә калды. Кинәт салкынча җил исеп куйды. Текә тау итәгендә берберсенең кочагына сыенып утыручы агачлар үзара пышылдашып алды.

Тәнгә үтеп кергән салкыннан бала йоннары кабарса да, Әхәт торып китәргә ашыкмады. Урман-кырларны, болынны, күл буйларын айкап чыкканнан соң, аның күзләре, ниһаять, авыл урамнарын барларга керешге.

Бөтен авыл уч төбендәге кебек. Тулып агучы инеш буенда иртәгә сабантуй булачак. Озын колга бастырып куелган, бәйрәм буласы мәйдан тирәли тәбәнәк эскәмияләр тезелгән...

Шул вакыт авыл уртасындарак бер әтәч кычкырып куйды.

«Безнең авылның әтәчләре дә сәер инде, караңгы төшкәндә кычкыра. Кая, кемнеке икән?»

Кемнеке булсын инде?! Әхәт бу йортны шундук таныды. Элек-электән ни сәбәпледер сәер кешеләр исәбендә йөргән Бибинур апа ихатасы башкалардан нык аерылып тора. Искереп, кыйшаеп беткән, зурлыгы да хәзерге хәллерәк кешеләрнең мунчасы хәтле. Бибинур әбинең бакый дөньяга күчеп киткәненә дә хәйран вакыт диләр инде. Хәзер аның моңарчы Себер якларында гомер кичергән кызы кайткан икән. Олы яшьтәге бу апа: «Минем гомергә җитәр әле, боерган булса, әнинең дә истәлеге булыр», — дип, яңа йорт күтәртеп тормаган. Кыяфәте дә, үз-үзен тотышы да нәкъ Бибинур әби, ди.

Әхәт кечкенә чакта Бибинур әбине олысы да, кечесе дә «Бибкәй» дип кенә йөртте. Матур гына бит инде югыйсә, әй уртәлә иде

әбиең шуңа. Урманнан чыршы-нарат сумаласы алып кайтып, шуны кайната иде ул. Авыл малай-шалайлары, кыз-кыркыннар гына түгел, өлкәннәр дә Бибкәй сагызын чәйнәп йөрде. Бер шырпы кабы зурлыгындагы сагызны биш тиенгә сатты әбиең.

«И-и, булган инде заманалар, — дип, үзалдына елмаеп куйды Әхәт. — Шуны соң үзебез алып кайтып кайната алмый идекме? Ялгыз карчык башлыча шуның белән көн күрә иде, ризыгыннан коры калмасын, дигәннәрдер инде. Алай дисәң, үзебез дә кайнатып карадык инде ул сагызны, тик барыбер Бибкәйнеке ничектер тәмлерәк шикелле иде. Үз рецепты булгандыр инде. Ипие дә...»

Авыл халкы ипине дә еш кына пикәрнидән түгел, Бибкәйдән сатып ала иде. Аеруча түгәрәк ипиен. Бибкәй ипи пешергән көн үзенә күрә бер бәйрәм төсен ала иде. Гаҗәеп тәмле итеп пешерде ул күмәчне...

— Бәтәч, кордаш, нишләп утырасың монда берүзең? Кунакка кайтканыеңмыни?

Агачлар арасыннан сыйныфташы Рафаил килеп чыккач, Әхәт сискәнеп китте. Җитез генә аягына торып басты. Бер дә уйламаганда бәхет кошы тотып алгандай шатланып, авызын ерып килүче Рафаилне кочып алды.

— Брат, нихәл? Күрешмәгәнгә егерме ел гына бардыр, әй...

Рафаилнең йөзе җитдиләнеп калды.

— Кая, бир әле берне, — диде ул, Әхәтнең күлмәк кесәсеннән күренеп торган тәмәке кабына ымлап. — Минеке өйдә калган.

Икәүләп тәмәке кабыздылар.

— Нәрсә, ахир, сабантуйга кайтырга булдыңмы? Маладис, дөрес эшләгәнсең. Әти-әниләр инде исән түгел дип, кайтмый йөрергә яра-

мый. Туган нигезне бөтенләй оныттырмый торган бердәнбер бәйрәм инде ул сабантуй, — дип сөйләп китте Рафаил, тәмәке исеннән ләззәтләнеп күзләрен йомгач. — Кара, кордаш, давай иртәгә миңа! Куян итеннән шашлык манчыйбыз. Энекәшең белән кил. Аһа?

Иртәгәсе көнен планлаштырмаган иде әле Әхәт. Өздереп җавап бирергә ашыкмады.

— Мине бит, тегеннән кайткач, колхозга алмадылар. Тоттым да куян үрчетә башладым, — дип дәвам итте Рафаил. — Шуларга яшел үлән чүпләп йөрим әле менә.

Рафаилнең кулындагы пакет яшел үлән белән тулы иде.

«Тегеннән кайткач...»

Сыйныфташының исерек килеш машинага утырып кеше таптатканын ишеткән иде Әхәт. Сигез елга япканнар егетне. Тулысынча утырып чыккан. Күрше авыл кызына өйләнгән, дип сөйләгән иде энесе бервакыт Рафаил турында.

— Гаиләңнең хәлләре ничек соң? — дип сорады ул Рафаилдән, аны-моны уйлап тормыйча.

— Ике ел инде. Икенче кызыбызга ике яшь тулган көнне китте...

Рафаил тынып калды. Әхәтнең йөрәген нәрсәдер чеметеп куйды.

— Карале, ахир, энекәш тә берни сөйләмәде, нәрсә булды соң? — дип сорады Әхәт саклык белән генә һәм Рафаилнең күзләренә текәлде.

— Синең энекәш авылга төн кунарга гына кайта бит. Йә ишетмәгәндер, яки сөйлисе килмәгәндер... Гаилә исемле иде минем хатын...

Рафаил янә тынып калды. Тәмәке төпчеген, төкергәндәй итеп, читкә ыргытты. Тау астында җәелеп яткан авылга шактый вакыт карап утырганнан соң гына сүзен дәвам итте:

— Коткарып кала алмадым Гаиләмне, Әхәт, — диде ул әкрен генә. — Теге чакта исереп таптаткан кыз баланың, аның әнисенең рәнҗеше төшкәндер инде... Гаиләне дә кибеткә, кызыбызга тәмнүшкә алырга дип чыккан җиреннән «КамАЗ» машинасы таптаган. Исән дә калган иде, тик, озак кына газапланып яткач, китеп барды. Кызы таптатып үлгән теге ана: «Минем рәнҗешем төшмәгәндер, кичердем бит инде мин Рафаилне», — дип сөйләнгән ди сөйләнүен. Ничек кенә булмасын, аның кызын да, минем Гаиләмне дә... кире кайтарып булмый инде хәзер... Алты, дүрт яшьлек кызларым белән өчәүләп дөнья көтәбез менә хәзер. Куян үрчетәбез...

Әхәт, сыйныфташы сөйләгәннәрне күз алдына китереп, тын да алмый тыңлап утырды.

«Сабантуй!.. Ел буе көтеп алган булабыз инде шушы көнне. Ә монда кемнәрдер кара кайгыга батып көн күрә. Ничәмә-ничә ел кайтмаган сабантуй ниемә кирәк булды инде миңа? Милли бәйрәм дигән булып, иртәгә ни йөзең белән күңел ачып йөрмәк кирәк? Милли бәйрәм диярлеге калса икән... Ник мендем, ичмасам, шушы тау башына?..»

Әхәт, сүзсез генә торып басты да чалбар артын каккалап, сак кына сыйныфташына дәште:

— Брат, син кайтасыңмы әле? Мин киттем. Тундыра башлады.

Рафаил, Әхәт белән саубуллашып, икенче сукмактан төшеп китте...

Әхәт Рафаилнең күңелендәге авыр хатирәләрне кабат кузгатып җибәрүе өчен төн буе үз-үзен битәрләде.

«Бәйрәм алдыннан гына теленне тыя белмәдең инде. Әллә кайдан, шәһәрдән кайтып...»

...Элегрәк тә сабантуйны башлап җибәрә алмый азапланалар иде. Әле халык әкрен җыела, әле җиңүчеләргә тапшырыласы бүләкләрне китереп җиткермиләр, әле җитәкчеләр соңара. Шуңа күрә Әхәт тә ашыкмады. Энекәше иртүк торып мунчага яккан икән, озаклап чабынып чыкты. Аннан соң ашыкмыйча гына сабантуй буласы урынга, авыл читенә юл алды.

Бер карасаң, гаҗәеп әдәпле инде бу авыл халкы. Ерак-еракларадан әллә нигә бер кайткан кеше булсын, көн дә күрешеп йөргән авылдашы булсын, янына туктап кул биреп күрешә, хәл-әхвәл сораша, үз йортына кунакка дәшәргә тырыша... Хәтта таң тишегеннән үк каяндыр аракы табып эчеп исерергә өлгергән адәмнәр дә, туган җиренә сирәк кайтып йөргән авылдашларын күреп алуга, әллә кайлардан аватүнә булса да килеп, кочакларга, нәрсәдер әйтергә маташа...

Сабантуй буласы мәйдан әйләнәсендә берәнсәрән генә карт-коры утыра. Халыкның күпчелеге бераз читтәрәк, кучмә кибетләр тирәсендә кайнаша. Кая карама, төркем-төркем булып ашап-эчеп утыралар. Сабантуйны алып баручы мәйданда ниндидер уен оештырып җибәрергә маташа. Микрофоннан күпме генә акырса-чакырса да, уенда катнашырга риза кешеләрне таба алмый, мескен. Аптырагач, микрофонын читкәрәк алып сүгенеп куйды да тобырша белән капланган трибуна артына кереп югалды.

— Нәкъ элеккечә үтә сабантуй, — дип елмайды Әхәт.

Ул арада бар халык район үзәгеннән сату белән килгән йөк машинасы янына җыела башлады.

Менә кайда икән ул сабантуй! Әле бәйрәм башланмаган да, инде район үзәгеннән китерелгән аракы сатылып та беткән. Соңгы ике

шешәне эләктерү бәхетенә ирешкән кешенең кулына сугып, аракысын төшереп ватканнар икән. Кара канга батып сугышырга тотынганнар. Бөтен халык, аларны әйләндереп алып, көлешә-көлешә күзәтеп тора. Ник берсе керсен араларына!

— Тфү!

Әхәт җан ачысы белән төкереп куйды.

«Сабантуй, имеш, әби-бабаларыбыз гомер бакый саклап килгән йолалар да, гореф-гадәтләр дә, милли бәйрәмнәребез дә нинди хәлгә калды... Менә тиле, — дип, янә үз-үзен тиргәп алды ул. — Бәйрәмгә кайттым, янәсе. Авыл сабан туен тамаша кылырга...»

Әхәт инеш буенда утыручы әбигә игътибар итте. Алдында ниндидер әрҗә. Тозлы кыяр һәм... сагыз сата.

«Бибкәйнең кызы шушы микән әллә?» дигән уй йөгереп узды Әхәтнең башыннан. Як-ягына каранып, Рафаилне эзли башлады. Шуны гына көткәндәй, Рафаил үзе пәйда булды. Аның да кәефе юк иде.

— Тукта, бергә кайтабыз, кордаш. Ни Алланы, ни мулланы санга сукмый торган мондый...

Рафаил сүзен әйтеп бетерә алмады, авыл ягыннан бер кыз баланың йөгереп килүен абайлап, туктап калды.

— Кара, минем олы кыз түгелме соң бу?

Ниндидер хәвеф-хәтәр буласын тойгандай, Әхәтнең дә йөрәге тынычсызланып алды.

— Әти, әти, — дип ярсыды йөгерә-йөгерә тыны кысылган кыз бала һәм Рафаилнең кочагына атылды.

Рафаилнең бөтен тәне калтырана башлады.

— Кызым, әйт, нәрсә булды, кызым? — дип җилтерәтте ул баласын. — Сеңлең кайда?

— Әти... ул анда...

Рафаил телсез калды. Кызын җилкәләреннән кысып тотып күтәргән хәлдә бераз басып торды да соравын кабатлады:

— Сеңлең кайда?

Кыз ярсып еларга кереште. Кучмә кибет янындагы ыгы-зыгы мизгел эчендә тынып калды. Барысының да күзе Рафаилнең кызында.

— Инешкә егылып төште, — диде, ниһаять, бала. — Безнең бакча артында...

Әти кеше кызын җиргә бастырды да авылга таба йөгерде. Әхәт, сабантуй бәйрәменә җыелган халыкның бер өлеше, хәтта әле генә сугышып яткан исерек ирләр дә, мизгел эчендә айнып, Рафаил артыннан чаптылар.

Сабантуйга җыенып чыгып киткәндә кат-кат әйтте бит югыйсә Рафаил: «Елга буена төшмәгез! Алла сакласын, ташу суы кызу ага», — диде. Алай дип кисәтеп торганчы, аһваһларына карап тормыйча, үзе белән бәйрәмгә ияртеп барган булса соң?! Беркөнне олы кызының, коймадан егылып төшеп, башы тишелгән иде. Ярасы төзәлеп беттмәгән дип, бәйләвен дә сүттермәде фельдшер апа. «Үзең генә бар инде, әтием, тик аракы эчмә», — дип, алты яшьлек кызы Рафаилне озатып калды. Их, нигә кирәк булды бу исерекләр туе аңа?!

Рафаил, йөгереп килгән уңайга, бакча артындагы инешкә сикерде. Әллә кайлардагы тау итәкләрен юып килгән инеш суының болганчыклыгына да, йөгереп керүгә үк тәннәрен куырып алган салкынлыкка да, аякларын көзән җыера башлавына да игътибар итмәде ул.

Нарасыен таба алмаган кайгыдан үз-үзен белештермәс хәлгә килгән ата җан ачысы белән кычкырырга тотынды:

— Балам, кызым!..

Суга чумып, пычракка, ләмгә батып кабат калкучы Рафаилне күзәтеп торучы халык арасында бала-чагалар да бар иде. Әллә аның кыяфәтеннән куркып, әллә кызганып елый башлаган балаларны инеш ярыннан читкәрәк куды-лар. Берничә минуттан кемдер ятьмә алып килде. Ян-якларына озын колгалар беркеттеләр дә инешне сөзә башладылар.

Ярдан ярга сөзә торгач, ятьмә тартылып куйды. Ләкин аны өстерәп чыгаргач, күңелләрдә борынлый башлаган нәни генә өмет чаткылары челпәрәмә килде — алагаем зур балык эләккән. Балыкны кире инешкә җибәрделәр.

Көзән җыерудан тәмам хәлсезләнеп егылган Рафаилне ярга өстерәп чыгардылар. Аякларын бераз угалап алгач, ир кабат суга сикерде.

Күпме генә эзләсәләр дә, бөтен инеш суын иләк аша уздырсалар да, бала табылмады. Рафаил салкын судан бер минутка да чыкмады. Үзләренең бакча артларын, аннары күпер астын айкап чыкты. Тик нарасые беркайда да юк иде.

«Әллә берәр урында ярга чыкканмы?» — дигән сүз колакка ишетелеп китте. Берничә кеше инеш ярларыннан эзләргә таралды. Ләкин Рафаилнең нәни кызы беркайда да күзгә чалынмады. Баланың кызыл кофтадан булганлыгын белгәч, кешеләрдә өмет чаткылары уянып алган тагын бер вакыйга булды. Тик кемдер шәйләп алган андый киемдәге нәни баланың да бөтенләй башка кыз икәнлеген тиз ачыкладылар.

Бөтен инешне аркылыга-буйга сөзеп чыксалар да, нәтиҗәсе булмады.

— Соң, ничек тапмаска була инде, җир йотмагандыр бит ул баланы...

Инеш ярына тезелешеп, ни эшләргә бел-

мичә аптырап калган авыл халкы бу сүзләр ишетелгән тарафка борылып карады. Әлеге дә баягы тозлы кыяр, сагыз сатып утыручы әби — Бибкәйнең кызы Гайшә карчык икән.

— Кайгыңны уртаклашам, улым, — диде ул, Рафаилнең җилкәсенә кулын куеп һәм, берара тын гына торгач: — Баланны табарбыз, боерган булса, — дип өстәде.

Гайшә әбинең күзләре яшьләнде. Яулык чите белән йөзен сыпырып алды да якында басып торучы бер хатынга дәште:

— Сеңлем, минем әни сөйли торган иде, элеккеләр суга баткан малларны, кешеләрне түгәрәк ипи ярдәмендә тапканнар, дип.

Рафаил кабат инешкә кереп китте.

— Шундый авыр минутта әллә нинди ырым-шырымнар турында сөйләнеп тормасаң ярамагандыр, — дип җавап кайтарды Гайшә әбигә теге хатын. — Бибкәй булсаң булырсың...

— Их, балалар, менә бөтен бәлаләр шуннан килә дә инде. Ата-баба йолалары белән исәпләшми башладыгыз шу-ул...

Әле дә булса, алга таба нишләргә белмичә аптырап, җилкәсеннән су эчендә басып торучы Рафаил дә, башка ирләр дә бу «әңгәмә»гә игътибар итмәде. Гайшә әби исә, катгый карарга килеп, уйлаганын тормышка ашырырга ниятли иде.

— Кая, берәрегездә яңа пешкән түгәрәк калач юкмы? — диде ул, тавышын күтәрә төшеп.

Инеш буе берара шау-шуга күмелеп алды, янә тынып калды.

— Әйе-е-е, — дип сузды Бибкәй кызы. — Хәзер каян килсен инде үз йортында ипи пешереп ашаучылар... Гөнаһ шомлыгына каршы, үзем дә әллә нишләп ялкауланганыем... Бик кирәк бит, әй. Табыгыз инде...

— Булмаса, мин район үзәгенә барып кайтыйм әле, хатын шунда пикәрнидә эшли бит, — диде, ниһаять, Әхәтләрнең бер күршесе һәм якында гына торучы машинасына таба йөгерде.

Әхәтнең күршесе кайтып җиткәнче унбиш минутлап вакыт үтте. Ни чарадан бичара дигәндәй, эзләүләр бер минутка да тукталмады. Яр буйларын кат-кат тикшереп чыктылар, күпер астында суны буып торган чүп-чарны ярга ташыдылар...

Кулына түгәрәк калач тоттырган Гайшә карчыкның хәрәкәтләрен авыл халкы тын да алмыйча, сәерсенеп карап торды. Күзләрен йомып, яр буена килеп басты. Яр читендә үк тукталып калды да баскан урынында өч мәртәбә әйләнде. Аннары, борын астыннан гына көйләп, ниндидер дога укыды да, күкрәгенә кысып томкан түгәрәк калачны саклык белән генә инешкә салды.

— Ныклап карагыз, оланнар, — диде әби.

Түгәрәк калач, батар-батмас булып, салмак кына инеш буйлап хәрәкәтләнә башлады һәм... туктап калды. Ул да булмады, бер урында боргалана башлады.

— Оланнар, карагыз әле, әнә шул урында, су төбендә нәрсәдер ята булыр, — диде Гайшә әби, түгәрәк ипи әйләнеп торган якка ишарәләп. Үзе, хәле бетеп, чирәмгә чүгәләде.

Ике ир, саклык белән генә кереп, ипи тукталып калган урынга юнәлделәр. Ниһаять, аяк астындагы чыбык-чабыкны, чүп-чарны каршы як ярга ыргыта-ыргыта килеп җиттеләр. Бераздан суга чумган җирдән башларын калкыттылар да, әле Гайшә әбигә, әле авылдашларына карап тора башладылар. Курку катыш аптыраш иде аларның күзләрендә.

Ниһаять, әкрен генә ярга таба атладылар.

Берсе... Рафаилнең күршесендә яшәүче Мәликә әбинең ике көн элек югалган кәҗә бәтиен кочаклап тоткан иде.

Ярда басып торучылардан кемдер көлеп җибәрде, кайсыдыр ачы итеп сүгенеп куйды.

— Әйтәм бит мин сезгә, бу Бибкәй сүзенә ышанып утырсаң, дип...

Монысын әби түгәрәк ипи сораган әлеге хатын әйтте. Бибкәй кызы Гайшә бу төртмәле сүзләрне әллә ишетте, әллә юк — әкрен генә торып аягына басты да Рафаилгә дәште:

— Улым, күңелем белән тоям, балаң елгада түгел...

«Ни сөйли бу карчык?!»

Рафаил, бу сүзләрне аңлап бетермәгәндәй, Гайшә әбинең күзләренә төбәлде. Яр буенда янә ыгы-зыгы башланды. Берсен-берсе бүлдерәбүлдерә, һәркайсы үз фаразын әйтергә тырышты.

— Җитте!

Рафаил бар көченә кычкырып җибәрде. Яр буенда тынлык урнашты.

— Әби, — диде Рафаил, Гайшә карчыкка дәшеп, — әйт әле, зинһар, син моны мине юатыр өчен генә әйттеңме?

Гайшә әби, күзләрен бераз кыса төшеп, Рафаилгә карап торды да:

— Әнә балакаең, улым, — дип, түбән очка илтә торган тыкрыкка таба ымлады һәм, борын астыннан гына нидер сөйләнә-сөйләнә, ваквак атлап китеп барды.

Тыкрыктан, бер нәни кызны җитәкләп, үз кызы кайчандыр Рафаилнең машинасы астында калып һәлак булган ана чыгып килә иде. Рафаил, яшен тизлегендә күпергә менеп, аларның каршысына йөгерде.

— И, Рафаил энем, үзең дә монда икән. Бәйрәмгә чыгып киткәнче яшелчәләргә су сибәрмен дип инешкә төшкән идем. Карасам, күпер астында, яр читендә бер бала елап утыра. Киемнәре шыр су. Синеке икән... Кайнар чәйләр эчеп, мунча кереп чыктык әле менә, әйеме, кызым? — дип, баланың аркасыннан сөйде апа.

# Бәхет пилмәне

«Декабрь азагы диген инде син моны! Сәгать өч кенә тулып китте югыйсә, урамда инде төнге караңгылык хөкем сөрә. Көннең иң кыска вакыты... Гомер булмаганны кышы да гадәттән тыш җылы килде быел. Әнә урамда әрле-бирле йөрүче узгынчылар арасында бер генә бүрек кигән кеше дә күренми. Ә бит бер ай чамасы элек кырык градуслы салкын иде. Шәһәрдә хәтта өшеп үлүчеләр дә булган, диләр. Мескен сукбайлардыр инде. Аңламассың бу табигатьне...»

Шыгырдап лифт ачылган тавыш Сания әбине уйларыннан арындырды. Карашын тәрәзәдән алып, ишеккә таба атлады...

— Әби, әби, без кайттык! — дип кычкырды нәни Зөһрә, ишектән керә-керешкә. Аның артыннан әнисе, Сания әбинең килене Илсөяр керде.

Карчыкның йөзе мизгел эчендә яктырып китте.

— Яле, кызым, сөйләп җибәр, — диде ул, оныгының пәлтәсен салдыра-салдыра. — Бүген бакчада ниләр эшләдегез? Рәхәт булдымы?

— Әйе, рәхәт булды. Уйнадык, рәсем ясадык, йокладык, — дип тезеп китте Зөһрә.

— Нинди рәсем ясадыгыз соң?

— Мин алма ясадым, Гүзәл — груша.

Гүзәл — күрше кызы, Зөһрә белән бер төркемгә йөри.

— Ярар, балам, бар, хәзер кулыңны юып, аш бүлмәсенә чык. Тамак ялгап алырбыз. Әниең дә ачыккандыр, — диде Сания әби, оныгының көдрәләнеп торган җирән чәчләреннән сыйпап.

— Бакчада нәрсә ашаттылар соң бүген, кызым?

— Без бүген бәхет пилмәне ашадык, — диде Зөһрә, аш өстәле янына килеп утыргач.

Сания әби берара аңышмыйча торды. Килененә сораулы караш ташлады. Зөһрәне балалар бакчасыннан алып кайткан Илсөяр эчкерсез елмаеп куйды.

— Нинди пилмән дисең син, кызым?

Зөһрә, «ничек аңламаска була инде?» дигәнне аңлатып, җилкәләрен сикертеп алды.

— Пилмән инде, тик аның ите юк иде.

— Ә-ә, пилмән ашаттылармыни? Аңламый торам тагын... Бәхет пилмәне сиңа эләктеме-ни, балам?

— Әби! — Зөһрәнең йөзе «һаман аңламыйсыңмыни?!» дип кычкырып тора. — Аларның бөтенесе дә бәхет пилмәннәре иде, мин ашап бетермәдем.

— Бүген төшке ашка чумар пешереп ашатканнар, — дип елмайды Илсөяр.

«Бәхет пилмәне». Сания әбинең күңелендә балачак хатирәләре яңарды. Сугыш тәмамланган елны булды бу вакыйга. Аның да әнисе беренче тапкыр пилмән пешергән иде. Пилмән бөтергәндә берсенең эченә камыр гына тутырып калдырган. «Андый пилмән эләккән кеше бәхетле булачак» дигәнгә чын күңелдән ышанган иде Сания ул чагында...

* * *

Төн уртасы. Ай яктысында берәү чалгы белән печән чаба. Бер-ике селтәнә дә, туктап, якягына күз ташлый. Аның янәшәсендә — тугызун яшьләрдәге кыз. Ул әлеге хатын чапкан печәнне ат арбасына салып бара.

— Әни, туктале, тәмәке исе килгән кебек, яхшы чакта китик мәллә? — диде кыз, әни-

сенә таба борылып, һәм әле генә тоткан куянны арбаның төбенә салып, яшел печән белән каплады.

Тиз генә җыенып, арбага менеп утырдылар да урман читенә чыгып киту ягын карадылар.

Кыз ялгышмаган икән: алар юлга чыгуга, ат каршында йөзен сакал-мыек баскан, авызына тәмәке капкан берәү пәйда булды. Акрын гына килде дә, авызлыгыннан тотып, атны туктатты.

— Тр-р, малкай... Нишләп йөрисез, урман пәриләре? — дип сүз катты ул.

Көтелмәгән очрашудан куркып калган кызның тәннәре калтырана башлады.

«Урман каравылчысы булса, нишләргә? Теге вакытны тоткач, елый-елый ялынганга гына «соңгы тапкыр» дип кызганып җибәргәние...»

Кыз, кулын яңа чапкан печән астына тыгып, куянны капшап карады.

— Ник дәшмисез, курыктыгыз мәллә?

Җавап юк. Аннары гына, бераз тынычлана төшкәч, әни кеше арбадан сикереп төште һәм таныш булмаган адәмгә таба атлады.

— И-и, Микулай, син икәнсең әле, куркып үлә яздык, — дип, тегене кочып та алды.

Бу хатын ягыннан мондый адым булырын күз алдына да китермәгән адәм үзе дә югалып калды булса кирәк, йомшак тавыш белән:

— Ни, төн уртасында урманда нишләп йөрисез, дим, — дип кенә сорап куйды.

— Бик йөрмәс идек тә, колхоз атларына иртәнгә печән кирәк бит. — Хатын тәмам тынычланып өлгергән иде, тавышы көр чыкты.

Минневафа апа төн уртасында юлларына каршы чыгучы бу кешенең урман каравылчысы түгеллеген белә. Николай исемле күрше мари

авылы кешесенең сугышка бармыйча урманда качып ятканын ишеткәне бар иде.

— Күршеләр, мине монда күргәнегезне әйтмәссез инде, яме, — диде Николай.

Кыз да, аның әнисе дә бу турыда уйлап та карамадылар, билгеле. «Төн уртасында урманда нишләп йөрдегез әле?» — дип, үзләренә бәйләнсәләр? Сугыш чорының үз законнары: үз малына түгел, колхоз атлары өчен булса да, караклык өчен җәза каты булачак. Аннан соң үзләренең дә бик күп туганнарын ирексезләп сугышка алып киттеләр. Кайберләренең үлгәнлеге турында хәбәр дә бар инде.

«Әйе, бу кеше, ичмасам, исән-сау йөри әле, ә бүтәннәр...»

— Бүген колхоз атлары чишмә буенда гына икән, анда барып йөрмим инде, үзегез белән су юкмы соң?

Миңневафа апа ат арбасындагы кечкенә агач кисмәктән калай кружка белән су алып Николайга бирде.

— Төнлә кемнәр генә йөрмәс урманда, сак булыгыз, — дип озатып калды аларны качкын...

— Әй, Микулай, йөрми нишлисең?! — диде Миңневафа апа, авыр көрсенеп. — Атларга иртән ашатырга печән кирәк бит. Тәүлегенә 200 грамм фураж бирелә. Аның белән генә ат туйдырып буламыни? Күтәрәмгә калды малкайлар. Эш атлары бит: сукага, тырмага җигәрлек итеп тәрбияләргә кирәк. Үземнекеләр булмаса да, мин җавап бирәм шул алар өчен. «Ат бер ятса тормый» диләр...

* * *

Көн буе, төн буе әнисенә ияреп урманда эшләп йөрсә дә, үз ихаталарына кайткач, Са-

ниянең арыганлыгы юып алгандай юкка чыкты. Тәрәзәдән күрше кызының чиләк-көянтә күтәреп чишмә сукмагыннан атлап баруын күреп алды да урамга чыгып йөгерде. Хафизә су тулы чиләкләрен өйгә кертеп куйгач, икәүләшеп тауга киттеләр. Авылны төнге караңгылык иңләп алгач кына кайтты Сания. Бусагадан атлап керүгә, өй эче ниндидер тәмле искә күмелгәнлеген тойды. Кызыксынулы күзләрен мич тирәсендә кайнашучы әнисенә төбәде.

— Утыр, кызым, — дип елмайды Миңневафа апа. — Бәйрәм итеп алыйк әле...

Сания әнисенең сүзләрен аңлап бетермәде.

«Бәйрәм?! Әллә әти кайтканмы?»

Як-ягына каранып алды, тиз-тиз атлап мич тирәли әйләнеп чыкты. Өй эчендә Сания белән әнисеннән башка адәм заты юк иде. Кыз күңелендә борынлый башлаган, дүрт ел элек сугышка киткән әтисен күрү өмете челпәрәмә килде...

— Нинди бәйрәм, әни? Сабан туе әллә кайчан үтте бит инде...

Сугыш башланганнан соң авыл җирендә сабан туеннан башка нинди дә булса бәйрәм булганын хәтерләми ул.

Миңневафа апа печән чапканда чалгы астына килеп кергән куян итеннән пилмән пешергән иде.

— Бүтән мондый бәхет эләгәме, юкмы — туйганчы ашап калыйк әле, кызым, — диде ул, Сания алдына авыз суларын китерердәй тәмле ис таратып, парланып торган зур гына тәлинкә куеп.

Ашка турап салыр өчен яз көннәрендә читән буенда шытып чыккан кычытканны да күрше малайлары-кызлары белән сугыша-сугыша җый-

ган Саниянең бу хәтле тәмле ризыкны моңа кадәр ашап карау түгел, ишеткәне дә юк иде. Эченә бер чеметем генә йомшак куян ите салынган, юка камыр белән төрелгән ризыкның исеме дә кызык кына икән: әнисе аларны «пилмән» дип атады...

Инде тәлинкәдә биш-алты гына пилмән калды. Чираттагысын авызына кабып чәйни башлаган иде, кинәт тукталып калды. Саниянең гаҗәпләнүле күзләре әнисенә төбәлде. Миңневафа апа, яңагына таянып, елмаеп, кызын күзәтеп утыра иде.

— Нишләп туктап калдың, кызым? — диде ана, хәйләкәр елмаеп.

Кыз алга таба нишләргә дә белмәде — йотаргамы, әллә төкереп ташларгамы?

— Монысының тәме икенче, әни... Ите юк бугай...

Ана кеше чын-чынлап гаҗәпләнгән кыяфәткә керде.

— Шулаймыни, балам? Сиңа чыктымыни? Аша, аша, анысы бәхет пилмәне аның...

Сания камырны теләр-теләмәс кенә йотып җибәрде...

— Ә нәрсә ул бәхет пилмәне, — дип сорарга булды ул, тәлинкәсе бушап калгач.

— Менә шул пилмәнне ашаган кеше бик бәхетле була, кызым, — диде Миңневафа апа. — Иншаллаһ, сине дә бәхет читләтеп узмас...

Хуҗабикә, бушап калган тәлинкәләрне өстәлдән алып куеп, чәй әзерли башлаган иде, кинәт ишек дөбердәтә башладылар. Миңневафа апаның күкрәк турын нәрсәдер чеметеп үтте. Кулындагы кайнар чәйле чынаягы идәнгә төшеп челпәрәмә килде. Ул да булмады, өй ишеге ачылып китте.

Бусагада — авыл советы рәисе Һадиулла.

«Исәнме-саумы» юк, керә-керешкә иснәнергә, як-ягына каранырга тотынды.

— Нихәл, Һадиулла, — диде Миңневафа апа, үз-үзен кулга алып.

— Тә-әк, нәрсә ашыйсыз?

Авыл советы рәисенең сәламләшергә исәбендә дә юк иде. Әле дә булса иснәнеп торуын белде. Карашы әле генә Миңневафа апа юарга дип бер читкә алып куелган тәлинкәләргә береген калды.

— Әһә, итле пилмән?! Тә-әк, ит каян алдың, каян урладың? — Һадиулла Миңневафа апага каш астыннан гына сөзеп карады.

— Кит инде, Һадиулла, әстәгъфирулла. Авызыңнан җил алсын, нинди урлау сөйлисең син? — Авыл советы рәисенең сүзләре Миңневафа апаны бөтенләй аптырашта калдырды.

— Мин ул хәтле үк миңгерәү түгел! Синең сыерың да, сарыгың да, хәтта кош-кортларың да юк. Признавайся, каян чәлдең?..

— Соң... колхоз атларына печәнгә баргач, чалгы астына куян кергән иде...

Һадиулланың күңеленә кемне дә булса рәнҗеттмимме икән дигән уй килеп тә карамады.

— Әһә, бик кызык, — дип дәвам итте ул, түм-түгәрәк рәвешкә кергән күзләрен Миңневафа апа тарафына төбәп. Саниягә шул чагында аның карашы хәтта «җинаять өстендә тотылган» әнисенең күзләрендә генә тоткарланып калмыйча, бәгырен үтәли тишеп чыгадыр кебек тоелды.

— Нәрсә, ул куянны үзең үстергән идеңме әллә?

— Ю-юк...

Миңневафа апа җилнең кайсы якка таба искәнлеген төшенә башлады.

Ул арада Һадиулла, пычракка баткан чабатасын да салып тормастан, ишекле-түрле йөрергә тотынды.

— Син, кулак кызы, артыңны кысып кына яшисе урында... Ул куянның колхоз басуында, колхоз урманында яшәгәнен белдең бит. Бик яхшы белдең. Колхоз җирендә ашап үскән мал кемнеке була?!

Миңневафаның күзләреннән яшь тамчылары тәгәрәшеп чыкты. Аңа кушылып, Сания елый башлады.

— Соң, чалгы астына үзе килеп керде...

Һадиулла аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде.

— Булса ни?! Махсус үтергәнсең димим бит әле... Колхоз идарәсенә алып кайтып бирергә тиеш идең. Болай томана кешегә дә охшамагансың үзең, колхоз малын урлап ашарсың дип, башыма да китермәгән идем...

Авыл советы рәисе, кинәт борылып, ишекне тибеп кенә ачты да олы-олы атлап чыгып китте...

* * *

«Бәхет пилмәне» пешереп ашаткан әнисен утыртып шул ук кичтә каядыр алып киткән өсте ябулы тарантас, ниндидер куркыныч кыяфәтле ир-атлар, авылдашларының мыскыллап көлүләре Сания әбинең күз алдында. Урманнан тотып кайткан куян өчен әнисен ике елга төрмәгә яптырган авыл советы рәисенә, очраган саен «карак, кулак» дигән сүзләр белән гөнаһсызга рәнҗеткән яшьтәшләренә хәтере калды аның. Шуңа күрәме, җае туры килмәдеме, инде тормышлар чагыштырмача рәтләнеп китсә дә, үз балаларына гомерендә бер генә тапкыр да «бәхет пилмәне» пешермәде...

— Әби, андый пилмәнне ашаган кеше чынлап та бәхетле буламы? — Зөһрәнең соравы Сания әбине уйларыннан айнытып җибәрде.

— Бәхетле була күр, балакаем, — диде Сания әби, үзалдына сөйләнгәндәй салмак кына тавыш белән. Моңсу елмаеп, янә оныгы Зөһрәнең җирән чәчләреннән сыйпап алды. — Без кичергәннәрне төшеңдә дә күрергә язмасын...

# Өмет

Дөрес әйткәннәр, әй: хатын-кыз, ялгыз калса, ничек тә түзә, тырышып-тырмашып яшәргә маташа әле ул, ә менә ир-ат... Караңгы базда берүзе калган чебен кебек — тегендә барып бәрелә, монда барып сугыла...

Хатынын югалту кайгысы бераз басыла төшкәч, Фәрит көннәрен шәһәр читендәге балалар йортында, шунда эшләүче күптәнге дусты Галим янында үткәрергә гадәтләнде.

Кайчандыр кешеләр утыртkан, бүген инде әкияти куе урманны хәтерләтүче наратлык эчендәге интернатка беренче тапкыр баруында ук алты-җиде яшьлек пешкән шомырттай кара күзле бер малайны үз итте ул. Килгән саен аны тәмле ризыклар белән сыйлады; бергәләп урман сукмаклары буйлап йөрделәр, кошлар сайравын тыңладылар. Малай да моңсу карашлы, чал чәчле бу абыйга, соңгы вакытларда балалар йортына еш килеп йөри башлаган Фәриткә, тиз ияләште. Аның тагын кайчан киләчәген Галим абыйсыннан алдан ук белешеп, иртә таңнан күзләрен тәрәзәдән алмыйча көтте...

Хатыны белән утыз ел бергә яшәсәләр дә, Фәритнең үз балалары булмады. Әминәсенең сәламәтлеге чамалы иде. Кайбер кешеләр үзен нәрсә көткәнен алдан ук сизенә диләр бит. Бәлки, Фәритнең хатыны да күңеле белән нидер сизенгәндер, үзе вакытсыз китә калса, баласының ятимлек тозагына эләгәчәген күзаллап, ире күпме генә үгетләп караса да, бала табарга батырчылык итмәгәндер.

— Мин Айзатны үземә уллыкка алыр идем, — диде Фәрит чираттагы килүендә интернат мөдиренә. Үзенең тормыш шартларын тасвир-

лап күрсәтте, малайның да аны чит итмәвен сөйләде.

Мөдир анын ниятенә каршы килмәде, озакка сузмыйча тиешле документларны барларга кушты...

Тагын бер-ике көннән Фәрит, әлегә бөтен кәгазьләрне әзерләп өлгермәсә дә, иртәнге автобус белән үк интернатка юл алды.

Болай да очын очка ялгап көн күргән ир аңлый: нияте барып чыккан очракта билбауны тагын да кысыбрак бәйләргә туры киләчәк. «Берәр җиңелрәк эш тапканда ярап торыр иде торуын» дигән уй да килде башына.

...Айзат интернатта юк иде. Фәрит сораулы карашын бер бүлмәнең ишек йозагы белән мәш килүче Галимгә төбәде.

— Арткы якта, бакчада уйный, — диде Галим, елмаеп. — Иртән торгач та синең хакта сорашты инде... Тик, зинһар, теге мәсьәләң хәл ителеп беттми торып, үзенә әйтмә, яме...

Әти-әнисе юклыгын, карт әбисе дә вафат булганнан соң инде бөтенләй ятим калганлыгын Айзат күптән аңлады инде. Башка балалар янына әледән-әле кем дә булса килгән көннәрдә тәмам боегып кала иде ул. «Нишләп иптәш малайларга-кызларга тәмле күчтәнәчләр, матур уенчыклар калдырып китәләр, ә миңа юк?» — дигән сорау борчыды аны андый вакытларда. Үзен кем дә булса табар, үз янына алыр дип көтте. Әбисе үлгәч, берникадәр вакыт күршедәге Лена исемле ялгыз хатын өендә яшәгән иде. Баштарак шул апа килеп моннан алып китмәсме дип өметләнгән иде. Әмма Лена апасы Айзат монда килгәннән бирле бер генә тапкыр да күренмәде.

Күптән түгел танышкан Фәрит абыйсы турында да уйламаска тырышып карады Айзат.

Тик уйлары шушы ак чәчле абыйга әйләнә дә кайта, күңелендә өмет уяна...

— Айзат!

Җиде яшьлек малай берьялгызы комлыкта агач машина белән уйнап утыра иде. Көтмәгәндә үз исемен ишетеп, сискәнеп китте. Каршысында бәхет кошы тоткан кешедәй елмаеп Фәрит абыйсы басып торганын күргәч, бер мәлгә югалып калды.

— Ис-сән-месез, — дип әйтә алды ул, ниһаять, тамагына утырган төерне йотып җибәреп. Уенчыгын ком өстенә куеп, торып басты. Үзе каш астыннан гына әүвәлгечә елмаеп торучы Фәриткә текәлде.

— Исәнме, Айзат! — дип кабатлады Фәрит. — Мин тагын синең янга кунакка килдем әле. Ярыйдыр бит?

Айзат җилкәләрен сикертеп куйды.

— Ярый, — диде ул тыныч кына.

Алар, җитәкләшеп, әкрен генә урман сукмагыннан атлап киттеләр. Фәрит Айзаттан интернат яңалыклары, тәрбиячеләр турында сораштырган булды. Малай, гадәтенчә, кыска җөмләләр белән генә җавап кайтарды.

Фәрит Айзатның киемнәренә игътибар итте. Бишмәте белән чалбары искереп беткән. Кайчандыр кара төстә булган ботинкасы да үз төсен әллә кайчан җуйганга охшый.

«Уйнаганда ярар, дип кенә киderделәр микән боларны?»

Фәритнең тәненнән салкын йөгереп узды.

— Айзат, әйдә минем белән шәһәргә... Сиңа яңа бишмәт, ботинкалар алырбыз.

Фәрит абыйсы чәчләренә кагылгач, Айзат атлап барган җиреннән шып туктап калды. Кабат Фәрит абыйсына каш астыннан гына

сөзен карап куйды да карашын сукмак читендәге кырмыска оясына күчерде.

— Миңа бернәрсә дә кирәк түгел, — диде ул коры гына.

Берара сүзсез генә атладылар. Ниһаять, Айзат:

— Абый, ә син тагын киләсеңме минем янга? Онытмыйсыңмы мине? — дип сорап куйды.

— Син нәрсә сөйлисең, улым?! Дусларны оныталар димени? Дуслардыр бит без?

— Әйе инде. — Айзатның авызы ерылды.

Фәрит интернат мөдиреннән Айзатны ике көнгә генә үзе белән җибәрүләрен үтенде. Аның малайны уллыкка алырга йөргәнлеген, кайбер кәгазьләрнең генә җитенкерәмәвен яхшы белгән мөдир каршы килмәде. Ике көннән малайны да, җитмәгән документларны да алып килергә сүз куештылар.

...Шәһәр урамындагы машиналар, трамвай, автобус тавышыннан Айзатның колаклары тонды. Маршрут автобусының салкынча салонына кереп утыргач, малай Фәрит абыйсының кулларын кысып тотты да тәрәзәдән шәһәр урамнарын күзәтеп барды. Выж-выж. Борын төбеннән генә төрле зурлыктагы машиналар йөгерешеп уза...

Фәрит абыйның шәһәр уртасында урнашкан фатиры бер генә бүлмәле булса да, Айзатка шактый иркен тоелды.

— Улым, әйдә, иң башта тиз генә юынып чыгыйк. Аннары капкалап алырбыз да йокларга ятарбыз. Вакыт соң бит инде. Син дә арыдың.

— Ярар, — диде Айзат гадәттәгечә тыныч кына һәм чишенә башлады.

Аның оекбашын күргәч, Фәрит аһ итеп куйды. «Бу тәрбиячеләр нәрсә карый икән?» дип уйлап алды ул, Айзатның табаны тишелгән носкины кулында әйләндергәләп.

— Яңа noскиларны Дамир талап алды, — диде Айзат, Фәрит абыйсының уйларын укыгандай.

— Тәрбиячеләргә әйтмәдеңмени?

Айзат, «юк» дигәнне аңлатып, башын селкеде.

Фәрит елмаеп куйды.

— Ярар, баш бәласе түгел, табарбыз. Әйдә юынырга!

Ярты сәгатьтән, Фәрит абыйсының чиста күлмәге белән трусигын киеп, Айзат кичке ашны ашады. Кайнаган сөт, йомырка сарысы болгатып пешерелгән макарон гына булса да, малайга кичке аш аеруча тәмле тоелды. Фәрит абыйсы күтәреп караватка илтеп салгач, баштанаяк юрганга төренеп, стенага таба борылып ятты.

— Йокла, улым, — диде Фәрит. — Йокла. Иртәгә шәһәрне карап кайтырбыз...

Төнге икеләргә чаклы Фәрит Айзатның киемнәренә аз гына булса да «кеше кыяфәте» кертергә маташып мәш килде.

Малай йокыга китә алмыйча озак ятты. Башында бертуктаусыз әллә нинди уйлар йөгерешә. Интернат исе аңкып тормаган чиста, йомшак урын-җир, җылы фатир, киләчәккә планнар корып, хыялланып йөргән урманнан кинәт кенә зур шәһәргә килү аңа әкият кебек тоелды.

Юрган астында яткан килеш тә Фәрит абыйсының үз янына килеп басуын, авыр сулаганын, сыйпаганын тойды.

Иркәләнеп озак ята алмады Айзат. Үзе дә сизмәстән юрган астыннан чыгып, Фәрит абыйсының кулларына чытырдап ябышты.

— Әз генә минем янда утыр әле. Мин хәзер йоклап китәм, — диде ул, күзләрен ачмыйча гына.

һәм, Фәритнең учын баш астына салып, йоклап та китте.

...Икенче көнне алар кибеткә киттеләр. Ул кибетнең зурлыгына, байлыгына, андагы шау-шуга гаҗәпләнде Айзат. Аеруча уенчыклар сатыла торган бүлек тирәсеннән тиз генә китә алмады.

Бу көнне Айзат җылы курткалы, яңа ботинкалы булды. «Канцтовары» бүлегенә кереп, альбом белән төсле карандашлар алып чыктылар.

Саф һавага чыккач та Айзат косып җибәрде. Көтелмәгән хәлдән Фәритне курку хисе биләп алды. Мондый халәттә нәни баланы тыгын автобусларда йөртергә ярамаганлыгын яхшы аңлап, кесәсендәге акчасын барлады да такси чакыртты. Фатирына күтәреп алып кереп, саклык белән генә урынга яткыргач, табибка шалтыратты.

— Озак йөргәннән, артык дулкынланудан гына күңеле болганган булырга тиеш, — диде табиб, Фәритне тынычландырып. — Бераз ятып торса, үтәр.

...Кибеттән алган альбомны бер ачты, бер япты Айзат. Ап-ак битләрен, бизәкле рәсем төшерелгән тышлыгын сыйпады. Фәрит абыйсы оста итеп очлап биргән карандашларны кабыннан бер бушатты, бер тутырды. Өйгә кайтып керүгә үк бераз рәсем ясый башларга ниятләгән иде дә, аны Фәрит абыйсы туктатты. «Талчыгып кайткач, әз генә булса да ял итәргә кирәк. Ишеттеңме табиб нәрсә дип әйткәнен?» — диде.

...Үзәккә үтә торган салкын, вак яңгыр ява. Автобуста җылы булса да, Айзатның бөтен тәне калтырана. Фәрит абыйсы: «Бүген үк кире кайтырбыз, синең документларны гына алабыз

да», — дип вәгъдә итсә дә, малайның кәефе кырылды.

Төшке аш вакытына интернатка килеп җиттеләр. Завхоз булып эшләүче Галим абый Фәриткә шатлыклы хәбәр җиткерергә ашыкты — Айзатны уллыкка рәсмиләштерү мәсьәләсе өстәмә кәгазьләрсез дә хәл ителгән. Мөдир генә урынында юк иде — шәһәргә киткән булып чыкты. Ә Айзатның документларын аннан башка бирәү дә бирә алмый икән.

Яңгыр туктагач, озак кына урманда йөреп кайттылар. Айзат инде кичке ашны да ашады, ә мөдир юк та юк. Фәрит малайны йокларга ятарга күндерде, иртәгесен кабат килеп үзе белән алып китәргә сүз бирде.

Мөдирне караңгы төшкәнче көтеп утырды Фәрит. Сәбәбе дә юк иде кебек үзе — тик кенә утырган җирдән күкрәк туры авырта башлады. Кинәт хәле бетте, күз аллары караңгыланды. Йөрәге моңарчы да шулай «шаяргалап» ала торган иде, шуңа күрә бу турыда уйламаска тырышты.

Мөдирнең инде бүген интернатка кайтмаячагын аңлап, иртәгә иртүк килү уе белән, Фәрит урыныннан кузгалды.

Шәһәргә кайтып җиткәндә төн уртасы якынлашып килә иде инде. Таксида хәле тагын да начарайды. Шофер, Фәрит яшәгән йортка килеп җиткәч, ярдәмгә аның күршесен чакырды. Ике ягыннан кочаклап, Фәритне фатирына кертеп яткырдылар. Участок табибы янәшә йортта гына яши. Күршесе аны чакырып китерде. Табиб Фәритнең өченче мәртәбә йөрәк өянәге кичергәнлеген ачыклады, нindидер уколлар ясады да «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртты.

— Хәлең шаяра торган түгел, абзый, хастаханәгә бармыйча булмас, — диде табиб.

Фәрит Айзат өчен борчылды. Күршесеннән иртәгә үк интернатка барып малайны монда алып кайтырга, үзе аякка басканчыга кадәр күз-колак булырга сүз алды.

«Ашыгыч ярдәм» машинасында өянәк кабатланды...

Айзат Фәрит абыйсын иртә таңнан ук көтә башлады. Интернаттан беркая да чыкмады. Төшке аш якынлашкач, берничә мәртәбә йөгереп чыгып, юлны күзәтте.

Фәрит абыйсының күршесен шундук таныды ул. Аның машинасы интернат янына килеп туктагач та күңеленә шом керде. Тыныч кына исәнләште дә аның артыннан керде. Күрше абый мөдир бүлмәсендә озак утырды. Айзат, ишек каршына, стена буена чүгәләп, көтте дә көтте.

Ишек ачылды. Бүлмәдән мөдир, Галим абыйсы һәм Фәрит абыйсының күршесе чыкты. Аларның йөзләренә карауга, Айзат ниндидер начар нәрсә булганлыгын сизенде. Күзләреннән яшь бөртекләре атылып чыкты.

— Айзат! Җыен, шәһәргә китәбез, — диде Галим абыйсы тыныч кына.

— Мин күптән әзер бит инде, — дип җавап кайтарды Айзат.

Аның күңеле шәһәргә, Фәрит абыйсы янына ашкынды. Тизрәк барасы иде дә ачыклыйсы иде: нигә аны алырга Фәрит абыйсы үзе килмәде икән?

Юл буе бер авыз сүз сөйләшүче булмады. Бары тик шәһәргә кергәч, вокзал яныннан үтеп барганда гына, Фәритнең күршесе Галимгә дәште:

— Өйгә өлгермибез инде, туры тегендә барыйк...

Җыйнак кына итеп салынган ике катлы бина

өстенә эре хәрефләр белән «Кафедра патологической анатомии» дип язылган. Инде укырга өйрәнгән булса да, Айзат бу сүзләрнең мәгънәсен аңламады. Шул йорт каршына туктадылар. «Шушында гына утырып тор!» — диделәр дә Фәрит абый күршесе белән Галим абыйсы, Айзатны машинада калдырып, тимер ишектән кереп киттеләр.

Алар кире чыкканчы ишектән күзен алмады Айзат. Менә тимер ишек кабат шакылдап ачылды. Ләкин чыгучылар арасында Айзат Фәрит абыйсын күрмәде.

— Әйдә, кайтып килик, — диде Фәрит абыйсының күршесе.

Айзат берни дә аңламады. Шәһәр үзәгендәге таныш йортка килеп җиткәнче, куркынган күзләре белән бер Галим абыйсына, бер Фәрит абыйсының күршесенә карап утырды.

Фатир ишеген күрше абый ачты. Фәрит абыйсының өйдә дә юклыгын күреп, Айзат Галим абыйның күзләренә төбәлде. Галим абыйның күзләре яшьләнгән иде.

— Фәрит абыең юк, — диде ул, Айзатның чәчләреннән сыйпап.

Айзатның да күзләреннән яшь бәреп чыкты.

— Ә кайда ул?..

Малай карават янына килде. Әкрен генә иелеп, карават астында яткан альбомын, карандашларын тартып чыгарды. Фәрит абыйсы алып биргән җылы курткасын салып ташлады. Караватка утырды.

Галим абый аңаниндидер ягымлы сүзләр әйтте, чәчләреннән кат-кат сыйпады... Тик Айзат берни дә ишетмәде, аңламады.

— Фәрит абый кайчан кайта инде?..

# Сукбай

Кайнар торба шартлавында аның тамчы да гаебе булмады югыйсә. Торак-коммуналь хуҗалыкның слесарь-сантехниклары подвалга төшкәндә, үзенең гадәтләнгән почмагында йоклап ята иде. Сантехникларга үз гаепләрен кемгә дә булса сылтап калдырырга җай чыкты. Ансат бит. Аларга ышанмыйча, ниндидер «сасы бомж» сүзен чынга алып утырмас бит инде түрәләр!

— Пычрак тәре... Әрәмтамак... Инфекция... Алкаш... Кешенең бәйрәм кәефен бозып ятмасаң монда...

Сантехниклар подвалдан өстерәп чыгаргач та, аның өстенә төрле яклап җирәнгеч сүзләр ява башлады.

— Су торбасы шартлауда минем катнашым юк, — дип аклана башлаган иде, бер сантехник йодрыгы белән сукбайның йөзенә сугып җибәрде. Мизгел эчендә ишегалды тынып калды. Ул да булмады, сантехникларның икенчесе, подвалда калганы күренде. Кулында — «гаепле»нең йоклаганда аска сала торган ертык бишмәте. Подвал ишегеннән чыгуга, бишмәт сукбайның йөзенә таба очты.

Подвал ишегенә йодрык зурлыгында асылмалы йозак куйдылар. Халык, «бөтен кеше эшләп ашаган заманда башкалар исәбенә көн күрүче әрәмтамак»ны сүгә-сүгә, берәм-берәм үз фатирларына таралды. «Ел буе көтеп алган бәйрәм алдыннан бик күп фатирларны җылы сусыз калдырган» кеше, аларны ялварулы күзләре белән озатып, ишегалдында япа-ялгыз торып калды.

«Аз гына гаебем булса да сүз әйтмәс идем, эчмасам. Кагылмадым бит, торба янына барганым да булмады... — Подъезд бусагасында үзалдына сөйләнеп утыручы «бомж»ның күзләреннән ачы яшь бөртекләре бәреп чыкты. — Их, кешеләр! Моннан кырык ел элек куелган ул черек торбалар өчен мин җавап бирергә тиешмени соң?»

Бер ай чамасы үзен сыендырган, инде туган йорт кебек кадерле урынга әверелә башлаган подвал ишегенә эленгән зур амбар йозагына текәлеп торды ул. Аннары карашы якында гына нәни баласы белән мәш килүче яшь әтигә күчте. Икәүләшеп ап-ак карда ауныйлар, бала чырык-чырык көлә...

Аның да бу нарасый кебек үз әтисе, аны бу дөньяга китергән газиз әнисе булгандыр. Нәни вакытында аның белән дә шушылай уйнаганнардыр, аңа белем биргәннәрдер. Кыяфәтенә караганда, бик яшь кешегә дә охшамаган. Кем белә, бәлки, үз гаиләсе, үз нарасые да булгандыр?.. Ләкин ул боларның берсен дә хәтерләми. Аңына килгәндә, җылы киемсез, канга батып салкын урамда ята иде. Чәчләренә әллә пычрак, әллә кан ябышып каткан, йөзе күгәреп чыккан. Кыйнап китереп ташлаганнармы аны, аракы шул хәлгә төшергәнме — монда ничек пәйда булганлыгын тәгаен генә үзе дә, бу йортта яшәүчеләр дә белми.

Шулай итеп, ул подвалда яши башлады...

«Әй» дип кенә дәштеләр аңа. Яшәргә кирәк бит: беренче көннәрдә, гарьләнеп булса да, шушы йортта яшәүчеләр эткә-мәчегә дип баскыч төбенә чыгарып ташлаган ризык калдыкларын ашап, шәһәр урамына хәер эстәргә чыга иде. Төрлечә мәсхәрәләп, кыйнап китүчеләре дә, вак тиеннәрен кызганмаучылары да булды. Кайбер

көннәрне ярты ипи алырлык «байлык» җыюга ирешә. Үзенең төс-кыяфәтеннән гарьләнеп, зур кибетләргә кермәде, ипине автобус тукталышларындагы кечкенә киосклардан гына алды...

Баштарак аның күңелендә ниндидер өмет чаткысы пыскый иде әле. Вакыт үтү белән хәтер кайтмасмы дип көтте ул. Инде ул өметне сүрелә башлагач, һичьюгы яңа документлар юнәтү турында хыяллана башлады. Бу мәсьәләдә аңа милиция генә ярдәм итә алачагын аңлап, шунда барып карарга дип ниятләде.

Тәртип сакчылары янына барып та йөрисе булмады, үзләре килеп җиттеләр. Кемдер «җылы су торбасын тишүе» турында хәбәр иткән булгандыр, күрәсең: ишегалдына милиция машинасы килеп туктады. Аннан бер милиционер чыкты да подъезд янындагы эскәмиядә уйланып утыручы сукбай янына килеп басты. Йөзен сакал-мыек баскан, иске бишмәт бөркәнгән адәмгә күз ташлагач, йөзен чытты. Әле кичә кич кенә чүплектә казынган сукбай юынырга да өлгермәгән иде — киеменнән әллә нинди исләр аңкып тора.

— Фу-у, с... — дип ямьсез итеп сүгенеп куйды милиционер. — Утыр машинага!..

«Сасы бомж»ны участокка алып килделәр. Иң беренче эш итеп, душ бүлмәсенә керттеләр. Салкынча су белән коенып чыккач, сукбай үз киемнәрен әле генә салып калдырган урыннан тапмады.

— Ярар, миннән оялмыйсыңдыр бит, утыр әйдә, — диде участок милиционеры, йөзенә елмайгандай төс чыгарып.

Сукбай аның каршына килеп утырды.

— Сөйлә, кем син, кайдан килдең, документларың кайда, нишләп подвалда ятасың?

Сукбайның куркынган күзләре участковый-

га төбәлде. Ашыкмый гына белгән кадәресен сөйләп бирде.

Әлбәттә, сүзләренә ышануы җиңел түгел иде. Бик озак азапланды аны участковый. Әллә нинди сораулар бирeп йөдәтте, кычкырып, куркытып-янап карады. Ахыр чиктә сукбайның хәтерен югалтканлыгын аңлады булса кирәк, бераз тынычланды.

— Нишләмәкче буласың инде?

— Миңа, ни, берәр документ ясап булмасмы соң, берәр эшкә керер идем...

Милиционер, йорт-җирсез мескен адәмнең хәлен яхшы аңласа да, нинди дә булса ярдәм күрсәтү турында уйламый иде.

— О, юк! Монысы булмас, — диде ул, кабат тавышын күтәрә төшеп. — Эшен дә, торак урынын да табып бирәсе түгелме тагын, бомжара?.. Әнә теге бүлмәгә кер, фотога төшерсеннәр. Вдруг син берәр бандиттыр, мин каян белергә тиеш? Тикшerербез.

— Минем киемнәр? — диде сукбай кыюсыз гына, үзенең анадан тума шәрә икәнлегенә ишарәләп.

— Бар, дидем, башта фотога төш! — дип җикерде участковый. — Ә сәләмәләрең тышта, баскыч төбендә...

Күрше бүлмәгә керeп фотога төшкәч, сукбай участковый янына чыкты.

— Бар, ычкын моннан! — диде участковый, аңа күтәрелеп карамыйча гына. — Теге подъездда эзең булмасын.

Сукбай, ишекне саклык белән генә ачып, тышка күз ташлады. Якын-тирәдә кеше-фәлән юклыгын абайлап, җитез генә баскыч төбендә аунап яткан киемнәрен кулына алды. Аларны ашык-пошык кигәндә, күзләреннән тагын ачы яшьләр акты.

«Бетте! Өмет тагын сүнде. Ярдәм иткән ди синең әше хәерчегә милиция! Алар кешене мыскылларга гына мачтыр шул», — дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә атлады да атлады...

Быел бәйрәмдә шулчаклы салкын булыр дип бер генә кеше дә уйламагандыр. Суык үзәкләргә үтә. Ләкин мондый көнне зарланып, суыктан качып өйдә ятып буламы соң? Яңа ел төне бит. Халык тыз-быз чаба. Һәрберсенең кулында ризык, тәм-том тулы пакет-сумка. Баласын җитәкләгән аналарда да, култыклашып баручы карт-корыда да, ялгызакларда да бәйрәм кәефе. Урам саен төрле төстәге гирляндалар, матур уенчыклар белән бизәлгән чыршылар.

Бишмәт якасын күтәреп, җәйге фуражкасын батырып кисә дә, салкын җилнең бертуктаусыз чеметүенә чыдар чама юк. Түземлеге төкәнгәч, сукбай, бар кыюлыгын җыеп, азыктөлек кибетенең «тамбурына», ике ишек арасына кереп басты. Салкын булса да, монда һичьюгы җил исми.

Ләкин озаклап җилдән ышыкланып тора алмады — кибет сакчысы күреп алды да, этләптөрткәләп, сукбайны урамга куып чыгарды.

...Кибет каршына килеп туктаган чит ил машинасыннан ир белән хатын чыкты. Ир түш кесәсеннән бер төргәк акча чыгарып хатынына тоттырды да тәмәке кабызды.

— Монда гына көтеп торам.

Хатыны кибеткә кереп китте.

Сукбай кыюсыз гына затлы куртка кигән әлеге иргә таба юнәлде.

— Брат, ярдәм итә алмыйсыңмы? Ипи булса да алып ашыйсы иде...

Искереп, ертылып беткән пәлтә кигән, йөзен сакал-мыек баскан теләнчене абайлап алуга, теге ир артка чигенде.

— Юк, юк! Якын киләсе булма, — дип, тизрәк бомждан котылырга ашыкты.

Сукбай адымын акрынайтты, ләкин туктамады. Ялыныбрак сорасам, бирми калмас, бәлки, дип өметләнде. Тик ул уйлаганча килеп чыкмады. Киресенчә, затлы куртка һәм чит ил машинасы хуҗасы көтмәгәндә аны бар көченә этеп җибәрде. Инде ничә көн буена юньле-рәтле ризык капмаган кеше, кибет каршындагы чуен рәшәткәгә абынып, арты белән асфальт юлга барып төште.

Сукбайның күз аллары караңгыланды. Бозлы асфальтта ятуына карамастан, баш астында сәер җылылык тойды.

Ул аңына килеп күзләрен ачканда, кибет янында теге машина юк иде инде. Күзләреннән кабат яшь тамчылары йөгерешеп чыкты. Башы авыртудан бигрәк, үзенең шундый мескен хәлдә калуына, хәер сорашып йөрергә мәҗбүр булуына гарьләнеп елады ул.

Кан саркып торган яраны учы белән кысып тоткан хәлдә, әкрен генә торып утырды. Аягына басты. Бер-ике адым гына атлаган иде, башы әйләнеп китте. Егылып китмәс өчен кабат җиргә чүгәләде һәм...

Сукбай үз күзләренә ышанмады — әле генә чит ил машинасы торган урында бер төргәк акча ята!

«Мондый могҗизалар әкияттә генә очрый ла, каян килеп акча булсын инде ул?!» — диде ул үзалдына. Шулай да, як-ягына карап, төргәкне кулына алды.

Аның кулында, дөрестән дә, биш йөз сумлыклардан гына торган төргәк иде.

Сукбайның тәне калтырана башлады. Бер мәлгә баш авыртуы да онытылган кебек булды. Башланмаган биш йөзлекләр төргәге! Илле

мең сум! Көтмәгәндә Ходай Тәгаләдән «Яңа ел бүләге» алган бәхетле сукбай табышны янә бер кат әйләндергәләп карады да тиз генә чалбар кесәсенә яшерде. Авырлык белән генә торып басты да, кинәт бик тә мөһим нәрсәсен онытып калдырганлыгы исенә төшкән кеше кебек ашыга-кабалана, кибет яныннан китеп барды.

Аның бу хәрәкәтләрен сәерсенеп карап торган узгынчылар исерек дип уйладылар булса кирәк — сукбайны аларның гадәти пычрак сүзләре озатып калды. Башка вакытта үзенә аталган мондый мәсхәрәле сүзләрне бик авыр кичерсә дә, бер мизгел эчендә баеган сукбай хәзер бу сүзләрне колагына да элмәде...

* * *

Кесәдәге «Яңа ел бүләге» сукбайның учын кытыклый...

Кешенең төшенә дә керми торган бәхет басты аны бүген. Бер кулы белән яралы башын тотып, икенчесен кесәсенә тыгып, атлады да атлады. Йөрәге шашып-шашып типте, тәне буйлап ниндидер рәхәт дулкыннар йөгерешә. Күңелен биләп алган хисләр ташкыны тышка бәреп чыкты. Сукбай бөтен дөньяны яңгыратып кычкырып җибәрде:

— Әһә-һә-һәй!..

— Ычкындың мәллә?

Сукбай чынбарлыкка кайтты. Якындагы йорт балконында тәмәке тартып торучы берәү аңа таба елмаеп карап тора иде.

— Яңа ел белән! Хәзер президент сөйли башлый, нишләп һаман урамда әле?

«Ярым караңгыда дүртенче кат балконыннан тротуардагы кешене ап-ачык күреп бул-

мыйдыр шул, — диде сукбай үзалдына. — Бәйрәм уңаеннан кәефләнеп өлгергән булса бигрәк тә. Юкса минем ише бомжарага сәлам бирер идеме икән, ай-һай...»

Бик озак барды ул. Алай-болай, акчасы югалганын аңлап, артыннан теге иномарка хуҗасы килмәсен тагын дигән кебек, ара-тирә артына әйләнеп карады. Кесәсендәге төргәкне алды да кире тыгып куйды, алды да тыкты...

«Мин дә кеше кебек яши башлармын микәнни? — дип уйланып барды ул. — Михнәтләр, мыскыллаулар артта калдымы?» Кесәсендә бер төргәк биш йөзлек ятуын белсә дә, күңелен бертуктаусыз нәрсәдер тырмалый, билгесез киләчәк куркыта иде аны.

Каршысында бер киоск күренде. Сукбай аның витринасын күздән кичерде. Сыра, тәмәке, кәнфит-прәннек сатыла торган киоск бикле иде. «Яңа ел төнендә эшләп утырмас инде башы булган кеше» дип уйлап куйды сукбай һәм, фикерләрен тәртипкә китереп, бераз гына киоскка сөялеп торды да утлары еректан ук күренеп торган тимер юл вокзалына таба атлап китте.

Аның бәхетенә, Яңа ел төне булса да, вокзал бинасы бикле түгел иде. Бер почмакта көлешә-көлешә нәрсә турындадыр гәпләшеп торучы ике милиционердан башка бер адәм заты да күренми. Сукбай, бәйрәм төне булса да эшкә чыгарга мәҗбүр булган тәртип сакчыларын каш астыннан гына күзәтә-күзәтә, ризык исе аңкып торган киоскка таба атлады. Калтырана-калтырана, сатучыга биш йөз сумлык кәгазь акча сузды:

— Әнә теге кырынгычны бир әле, — диде сукбай, витринага ишарәләп.

Бер үк киоскта гигиена кирәк-яраклары да,

сабын-порошок ише нәрсәләр дә, азык-төлек тә сатылуы вокзал өчен гадәти күренеш.

Сәләмәгә төренгән, сакал-мыек баскан гап-гади бомж кулында шундый зур акча күреп, сатучы бер мәлгә аптырап калды. Тик, сукбайның бәхетенә, милиционерларга ишетелмәслек итеп кенә:

— Сдача юк! — диде.

— Ә-ә, туктале, сеңлем, алайса ашарга да алам. Пилмән җылытып бирәсеңме?

«Пилмән» сүзен үзе әйткән булса да, ничектер сәерсенеп куйды сукбай. «Пилмән? Кайчан ашадым икән мин ул ризыкны соңгы тапкыр? Гомумән, ашап караганым бармы?» дигән уй йөгереп узды аның башыннан. Үзе дә сизмәстән көлеп җибәрде.

— Кара, сеңлем, башта юынып, кырынып чыгыйм инде, яме, — диде ул, янә сатучыга дәшеп. — Кыяфәтне күреп торасың бит. Бир инде кырынгыч белән бер сабын...

Сатучы кыз карышып тормады.

Бер порция кайнар пилмән, кырынгыч һәм сабын йөз сумга төште.

Әле дә булса ярым пышылдап сөйләшеп торучы милиционерларга карап алды да, үзенә игътибар итмәүләрен аңлагач, сукбай, кызу-кызу атлап, бәдрәфкә юнәлде...

Ун минут чамасы үтүгә, киоск янында бөтенләй икенче кыяфәттәге кеше басып тора иде инде. Сәләмә киемнәрен дә алыштырган булса, сатучы аны танымаган да булыр иде. Әле болай да, сукбай пилмән сорагач, икеләнеп калды. «Әле генә йөз сум акча түләгәнием бит», — дип кат-кат кабатлый торгач, аптыраган кыз, башын киоск тәрәзәсенә тыгып, пилмән талап итүченең өс-башын күздән кичерде. Таныды.

— Менә ичмасам чын кешегә охшап калгансың, юкса карачкы тек карачкы идең, — диде ул, пилмән салынган тәлинкәне кыска дулкынлы мичкә тыгып. — Танымый да торам, билләһи...

Сукбай канәгать елмаеп куйды.

Пилмәнне әкрен генә, тәмләп кенә ашады. Бу минутларда үз башыннан кичергән хәлләр турында уйламаска, инде куркыныч төш кебек кенә тоелган, әллә кайда, артта калган михнәтләрне онытырга тырышты. Аның моңа хакы бар иде. Ләкин бер сорауга җавап табарга кирәк: «Кем мин?»

...Беренче гыйнвар. Кая гына барырга була икән бүген? Сукбай үзенең сәләмәләренә карап куйды. «Базары да эшләми бит аның бүген...»

Кесәсе тулы акча булса да, сукбай әлеге дә баягы ертык бишмәтенә төренде, башына фуражкасын элде дә урамга чыкты. Колакларын шундук чатнама суык чеметеп алды. Сукбай бишмәт якасын күтәрде, фуражкасын батырыбрак киде.

Вокзал бинасының сул як почмагында өч үсмер басып тора иде. Трамвай тукталышына таба атлаучы сукбайны шәйләп алган егетләрнең берсе, йөгереп килеп, аның юлына аркылы чыкты.

«Атналар буе аракы эчеп айныган кеше дә мондый хәлгә килмәс», — дип уйлап куйды сукбай, аның йөзенә карап алуга.

— Бу похмельдән интегә бугай, дисеңдер инде, — диде егет, аның уйларын укыгандай. — Юк, бер грамм да эчмәдем. Хәтта Яңа елны каршылаганда да...

Шикләнүе юкка булмаган икән — чәче саламга охшаган бу егет наркоман булып чыкты. Моны егет үзе дә яшермәде.

— Карап-карап торам да аптырап куям әле, — дип дәвам итте «салам чәч». — Болай ничава гына күренәсең үзең, ә киемең...

— Мин, энекәш, кемлегемне үзем дә белмим инде хәзер, — дип җавап кайтарды сукбай, авыр сулап.

Бу сүзләр, наркоман егеттән битәр, аның үзенә атап әйтелде кебек.

Барыр җире булмаса да, аның бу наркоман егет белән фәлсәфә корып торасы килмәде. Кулын селтәде дә юлын дәвам итәргә ниятләде. Ләкин егет янә аның каршысына килеп басты.

— Мөмкинлегең булса ярдәм ит инде, — диде «салам чәч», сукбайның җиңеннән тартып.

— Мондый кыяфәттәге кеше ничек кенә ярдәм итә алыр икән соң сиңа?

— Кыланып торма инде, абзый кеше, беләм бит...

Сукбай сагаеп калды. «Ничек белгән булырга мөмкин ул?» — дип уйлап куйды ир һәм, тегенә сиздермәскә тырышып кына, чалбар кесәсен капшап карады.

Аның бу хәрәкәтен «салам чәч» күреп калган иде, шуңа күрә сукбайның кесәсенә ымлап елмаеп куйды.

Пилмән ашаганнан калган дүрт йөзлекнең өчесе «салам чәч» кулына күчте...

Кесәсендә илле меңгә якын акчасы булган кеше өчен өч йөз сум зур сумма түгел түгелен. Шулай да сукбайның кәефе төште. «Болай итеп, очраган бөтен алкашка, наркоманга акча өләшә башласаң...» — дип уйлады ул. Үзенең наркотик яки аракы түгел, ә ярты ипи алырга тилмереп йөргән чаклары хәтерендә яңарды...

Көне буе шәһәр урамнары буйлап йөрде сукбай. Киосктан чәй, бутерброд алып тамак ял-

гады. Кием-салым ише кирәк-ярак кибетләре эшләмәгәнлеген яхшы белгәнгә, бүген үз алдына бер генә максат куйды ул. Шәһәр урамнарын карап йөри-йөри, таныш йортлар, үзен белүче кешеләр очрамасмы? Бу шәһәрдә аңына килгәч, шушында ук яшәгәндер бит инде, әллә кайлардан китерен ташламаганнардыр...

Шәһәрнең бер башыннан икенчесенә кадәр җәяүләп барды, ишегалларына керде, зуррак биналар янында туктальп, хәтер капчыгында казынып карады, тик бер генә таныш җир дә очратмады.

Кайда төн кунарга дип баш ватып та тормады — янә тимер юл вокзалына китте...

Таң атуын түземсезлек белән көтте. Иртәнге тугыз тулуга, вокзалдан әллә ни ерак булмаган кием-салым кибетенә юл алды. Керергә кыенсынып шактый вакыт таптанып торды. Ниһаять, кибет тирәсендә әрле-бирле йөрүче шикле кешегә кизү торучы кием шкафы кадәр гәүдәле егет игътибар итте.

— Әй, карале, нишләп монда таптанасың? — дип дәште ул тупас тавыш белән.

Сукбай туктальп калды. «Шкаф»ка якынрак килеп басты.

— Энекәш, сезнең кибеттән кием сатып алырга уйлаган идем, ярыймы?

Аның өс-башына күз төшереп алгач, кизү авызын кыйшайтып кына елмаеп куйды.

— Син алырдай киемнәр сатылмый монда, — диде ул һәм шаркылдап көлеп җибәрде.

Ләкин сукбайның башка барыр җире юк иде. Кайсы гына кибеттә дә шул ук хәл булачагын яхшы белә. Шуңа күрә ничек тә максатына ирешергә булды.

— Мин син уйлаган бомжара түгел, энекәш. Акчам бар. Просто кичә вокзалда талап, кый-

нап киттеләр. Документларны да алдылар, ә акча тапмадылар... — Сукбай тиз генә кесәсеннән берничә кәгазь акча тартып чыгарып күрсәтте.

«Эһем», — дип йөткереп куйды «шкаф» һәм, ишекне киң итеп ачып, сукбайны кибет эченә үткәреп җибәрде.

Кибеттән чыгучы затлы киемле кешенең әле генә сәләмәгә төренеп кереп киткән сукбай булуына ышанмый торды «шкаф». Йөзенә озаклап карап торгач кына таныды.

— Ну, абзый, гаҗәпләндердең, — дип озатып калды ул аны.

Кибеттән чыгып бераз гына барган иде, артыннан кемдер килүен тойды. Мизгел эчендә бөтен тәненнән салкын йөгереп узды.

— Мужик, тукта әле...

Сукбай артына борылып карады. Кичәге наркоман егет!

— Тартырга бармы? — диде «салам чәч» карлыккан тавыш белән.

Сукбай сагаеп калды. Тегенең әшнәләре кай тирәдәрәк качып тора икән дип, күз кырые белән генә әйләнә-тирәне тикшереп чыкты. «Салам чәч»нең кичә вокзал янында бергәләшеп сыра чөмергән иптәшләре күренмәде.

— Кичә өч йөз сум бирдем бит инде. Тагын ни кирәк? — диде сукбай, тегенең күзләренә карап. Берүзе генә булганда бу чирләшкә наркоманның аңа зыян сала алмаячагына иманы камил иде, шуңа күрә җебеп төшмәскә булды. — Туздырып та бетердеңмени?

«Салам чәч»нең үз кайгысы кайгы: бу кеше аңа кичә акча биргәнме, юкмы — кем хәтерли инде аны? Аның тәне бүген, менә хәзер уттай яна, башы хәзер чатный, доза хәзер кирәк!

— Слушай, үтермә мине, ярдәм ит. Бар бит инде синең, беләм...

«Вак акча да юк ичмасам, бер биш йөзлек тоттырып китәргәме инде? — дип уйлап куйды сукбай. — Бушка килгән акча бит... Икенче яктан караганда, минем алда хәзер мескенләнеп торса да, акча бирсәм, тагын минутысәгате белән юкка чыгара инде ул аны... Белсә иде ул минем ике-өч көн элек кенә бер телем ипигә тилмереп, никадәр мыскыллауларга түзеп яшәгәнемне...»

— Әйдә, кафега кереп чыгабыз, — диде ул «салам чәч»кә дәшеп һәм әле генә чыккан вокзал ишегенә таба борылды. Шул мизгелдә арттан ниндидер каты нәрсә белән башына суктылар...

Трамвай тукталышындагы кибет артында аңына килде ул. Әле көндез генә сатып алган җылы курткасы да, чалбар кесәсендәге акча төргәге дә юк иде. Сикереп тормакчы булып талпынган иде, башы авыртуга түзә алмыйча ыңгырашып куйды, күзләре кабат йомылды.

«Хәниф абый, нишләп ятасың монда?» дигән тавыш ишетелде. Курка-курка гына күзләрен ачты. Аның янында бер егет белән кыз басып тора иде. Егет ыңгырашып ятучы кешене чынлап та таныды булса кирәк:

— Хәниф абый, — диде ул, кабат аңа дәшеп. — Карале, Яңа елны шәп каршылагансың бугай син... Салкын тидерәсең бит, бар, тизрәк өеңә кайт...

# «Ышан миңа!»

Чамасыз салкын булгангадыр инде, трамвайның ишекләре, моңарчы ишетмәгән ниндидер авазлар чыгарып, теләр-теләмәс кенә ачылды. Кыска тунының барлык сәдәпләрен эләктергән, якасын күтәргән берәү тукталышта төшеп калды.

Җил, котыра-котыра, урамда кар себерә. Төн уртасы якынлашып килә инде, биек-биек йортларның тәрәзәләрендә утлар да сирәгәйгән. Әле заводтан кайтырга чыкканчы ук Касыймга күңелен ниндидер бушлык биләп алгандай тоелган иде. Күңелсезлектән кая барырга белми аптыраганнандыр инде. Тукталышта соңгы трамвайга керер утыргач та котыла алмады ул әлеге бушлыктан. Баштарак тун куенына чумып йокымсырап барды, бераздан күрше утыргычта гәпләшеп кайтучы хезмәттәшләренә кушылып китәргә маташты. Күңел бушлыгын барыбер җиңә алмады.

Иртәгә чәршәмбе. Димәк, кабат иртүк эшкә барасы. Касыймның күзләре тәрәзә артында аларны озатып калучы шакмак ут яктыларын — йорт тәрәзәләрен санады: бер, ике, ун, егерме... Баштарак сирәк кенә тоелса да, очы-кырые юк. Җитмәсә, баш миен һич кителмәгән уй кимерергә тотынды: нигә дип шулай соң, төн уртасында кунакка барырга булды әле? Ничек кабул итәрләр аны? «Ә нишләмәк кирәк? — дип юатырга тырышты ул үзен. — Өйгә кайтсаң... Анда ялгыз телевизор, салкын түшәк, кичә командировкага дип чыгып киткән хатын пешереп калдырган сөтле боткадан башка берни көтми. Ялгызлык дигән дошман зарыгып көтә. Колачларын җәеп...»

«Арыттты бүген» дип уйлап куйды Касыйм. Трамвай тәгәрмәчләре дә шуны ук кабатлый иде кебек: арыттты, арыттты, арыттты!

«Анда баруым да инде... Иманым камил, шунда ук йоклап китәчәкмен бит, әй. Ә ул кыен хәлдә калачак. Борчылачак, кәефе кырылачак. Иртәгә аның да эшкә барасы бар... Хикмәт анда гына да түгел бит әле, бөтенләй башкада, башкада, башкада».

Тукта, тукта, кая ашыгасың дигән кебек, трамвайны тоткарларга маташучы көчле җилгә, кар тузанына ияреп, нәкъ шул «башка хикмәт» озатып калгандай тоелды Касыймга. Ир бу «хикмәт»нең ни икәнен якынча гына да күз алдына китермәде, ләкин йөрәге белән тойды: бүген, бәлки, бару кирәкмидер дә...

Трамвайдан төшкәч тә, икеләнеп шактый басып торды Касыйм. Үзенчә шаярырга ниятләведер инде: салкын җил, тунның сәдәпләре арасыннан үтеп кереп, ирнең гәүдәсен чеметеп чыкты. Касыйм, корт чаккандай, өшегән тәнен угалап алды.

Ниндидер йөз адым чамасы ераклыкта гына аның йорты. Тәрәзәсендә ут бар. Димәк, көтә. Килеп ишеген шакы гына, бар да булачак — игътибары да, кичке ашы да, иркә кочагы да, тәмле йокысы да, башкасы да...

Касыйм декабрь аеның якшәмбе көннәрендә яхшылап кырынып, үзенең матур спорт костюмы киеп, җилкәсенә чаңгылар элеп шушы тукталышка килүен хәтерендә яңартты. Беренче тапкыр шушы тукталыш очраштырды аларны. Беренче кат иреннәрен табыштырды...

Шәһәр читендәге урман ак карга төренгәч тә, якшәмбе көн җитүен түземсезлек белән көтеп алган иде Касыйм. Һәм җае чыгу белән

табигать кочагына талпынды. Трамвай тулы халык. Кемдер базарга, кемдер, Касыйм кебек үк, кышкы урманга бара. «Болай да бер аякта гына барырлык, монда син тагын...», «Чаңгыларыңны кочаклабрак тот әле, кеше өстенә ава бит...» Усал сүзләр дә ишетергә туры килде Касыймга. Тик ул аларга игътибар итмәскә тырышты. Ул бит ел буе көтеп алды кыш җитүен. Бүген менә, ниһаять, кабат чаңгыга баса. Кычкырсыннар шунда рәхәтләнеп, ә аңа барыбер. Аның күңеле ниндидер сәер ашкынудан иләсләнә, урманга чакыра иде.

Трамвайдан этеп диярлек төшерделәр Касыймны. Җиргә аяк басуы булды, кулындагы чаңгысы ычкынып китте. Өлгерә алмый калды Касыйм, чаңгы янәшәдә генә басып торучы бер яшь кызның җилкәсенә тиде. Шуны гына көткән диярсең, кыз кинәт Касыймга таба борылды да туп-туры күзләренә төбәлде. Ирнең бөтен тәне аркылы ниндидер сәер дулкын йөгереп узды.

— Аһ, шайтан... Гафу итегез, мин... — диде Касыйм, зур гаебе булган кеше кыяфәтенә кереп.

— Зыян юк, борчылмагыз.

Аһ, бу күзләр!.. Тагын бер кат гафу үтенеп, Касыйм калкулыкка таба атлады. Ә кыз, очраклы танышын күзләре белән озатып, туктальшта калды...

Туйганчы шуды Касыйм. Инде кайту нияте белән урман читенә чыккан иде, кинәт кенә аяклары, җиргә береккәндәй, каккан казык кебек катып калды: ап-ак кар өстеннән ап-ак куртка кигән кыз йөзә! Бу бит... бу бит баягы күзләр иясе! Кая инде монда кайтып китү?!

...Якшәмбе саен шушында, калкулык янында очраштылар алар. Укытучы иде ул кыз. Өстәвенә

чаңгыда да оста шуа. Чаңгыга басып, кышкы урманны ничәмә-ничә кат әйләнделәр, озаклап калкулыкта шудылар. Ул ак кар ярата иде. Шушы сирәк очрашулар вакытында гына да кыз Касыймга кышкы табигать, кар турында күпме шигырь сөйләде... Ә беркөнне, кичкырын, инде эңгер-меңгер төшә башлагач, гадәттәгечә, трамвай тукталышында хушлашканда, Касыйм кызның иреннәреннән үбеп алды...

Аларның аралары торган саен җылына, якыная барды. Бөтен дөньясын онытты Касыйм. Бар уйлаганы — укытучы кыз, аның иркә, җылы кочагы, йомшак иреннәре... Кайбер якшәмбедә, өеннән төнге сменага эшкә барам дип чыгып китеп, кыз фатирында куна да калды. Касыймның: «Бердәнберем, мәхәббәтем минем. Сине генә сөям. Ышан миңа», — дип пышылдаулары кызны тәмам исертә иде. Иргә сүз катмыйча гына, үзалдына әллә нинди хыялларга чумды. Яшьлеге офык артында күмелә барган кызның күкрәк турында ниндидер өмет чаткысы кабынды...

Менә хәзер Касыйм тагын шул тукталышта басып тора. Салкыннан дер калтырап. Ул яхшы беләː кулларыннан әле дә машина мае исе аңкый, бите дә чиста дип әйтерлек түгел, күлмәге дә соры, якасына тимер кыйпылчыклары береккән. «Бу кыяфәттә ничек кабул итәр икән? Киләм дип нигә шалтыраттым, ичмасам...»

Тик, юк, иң мөһиме бу да түгел.

«Якшәмбе көн! — дип уйлап куйды Касыйм. — Безнең мәхәббәт бәйрәме иде бит. Ял көне. Мин нишләп, атна уртасында килеп, шул бәйрәмне гадәти көнгә әйләндермәкче булам. Дөрес, ул мине кертми калмас, ашатыр да, юындырыр да... Юк, бәйрәм бәйрәм булып калсын инде!»

Касыйм кинәт иң мөһимен аңлады. Аның ап-ак кар өстендәге мәһабәт буй-сынлы чаңгычы гына буласы килә! Чөнки үзен нәкъ менә шуның өчен, текә калкулыктан күз дә йоммыйча боргалана-сыргалана шуып төшә белгән өчен генә яраталар дип уйлады ул...

«Нигә алдарга үз-үзеңне? Андамыни хикмәт? — дигән уй йөгереп узды Касыйм күңеленнән. — Арыдым мин. Туйдым. Туйдым!..»

Ниһаять, Касыйм аңлады. Бактың исә, мондый хәлдә калуы беренче тапкыр гына түгел икән ләбаса. Бик күпләргә әйткән бит ул бу сүзләрне: «яратам», «ышан миңа»...

Касыйм үзен көткән ялгыз тәрәзәгә янә бер күз ташлады. Кинәт аның бөтен барлыгын курку биләп алды. Үзенең моңарчы җайлы гына аккан тормыш рәвеше өчен курку иде бу. «Карале, көтә бит, әй. Әллә бөтенләйгә берегергә чамалыймы? Ә бит ул минем гаиләле кеше икәнемне дә белми, авыз ачып сораганы да юк, ичмасам. Еламаган балага имчәк каптырмыйлар — очраган берсенә биография сөйләп йөри алмыйм бит инде. Авыз пешкән чаклар булды. Монысы да йөрсен тагын, хатын янына барып ир булешеп...»

Ишекне шакымады Касыйм. Телефоннан да шалтыратып тормады. Тукталышка якынлашып килүче таксига кул изәде.

Ә кыз әле дә булса өстәл артында утыра иде. Кайчаннан бирле көтә ул... Кызның өметләре, якты хыяллары белән тулы ике чынаяк та ничә җылынып, ничә суынды инде. «Нигә килмәде? Ник шалтыратмады? Бәлки, үземә шалтыратыргадыр?»

Кыз телефон трубкасына үрелде. Кире куйды. Аптырагач, бизәкле тәлинкәдән чәк-чәк алып капты. Гаҗәп, нишләптер бал тәмен тоймады. Чәк-чәк тозлы иде...

# Ала карга

Шап-шоп!

Баш очында гына канат кагынган тавыш ишетелде. Агач төбендә ятучы егет башын күтәреп карамакчы иде, маңгаена шык итеп корыган ботак килеп төште. Агачның аскы ботагында, егетнең күзләренә чекерәеп, ялгыз ала карга карап тора иде. Шактый вакыт бер-берсенә карашып торганнан соң, егет җырлап җибәрде:

Ала карга дигән, ай, асыл кош,
Агач башларына ник кундың?

Тере кош түгел, таш сын диярсең — күзен дә йоммый. Нәрсә турында уйлый торгандыр? Егет җырын дәвам итте:

Ник кунганыңны да, ай, белмәгәч,
Якты дөньяларга ник тудың?

Их син, аңгыра җан иясе. Дөрестән дә, ник туганыңны белмисең бит син. Белсәң, кадерле мизгелләреңне әрәм итеп миңа төбәлеп утырыр идеңмени соң?

Ала карга, җавап кайтаргандай, егет тарафына тагын бер чыбык томырды.

— Әһә, оя кормакчы мәллә? Нигә миңа ыргытасың соң син аны, ачыгавыз? Мин ясап бирер дисең мәллә?

— Кар-р-р! — Карганың әллә «әйе», әллә «юк» дияргә маташуы иде бу.

Абау, бигрәк килбәтсез тавыш! Егетнең күңелен ниндидер аңлаешсыз шом биләп алды.

— Көш-ш-ш! Көш, дим, карале! Торма анда кеше куркытып.

Ала карга дигән, ай, асыл кош,
Тәүбә иттең мәллә очмаска?

Очып китү дигән уй карганың исәбендә дә юк. Карашын егетнең күзләреннән алмыйча утыруын белә. Җавапка кабат «Кар-р-р!» дигән аваз гына яңгырады. Түземлеге төкәнгән егет, бер читтә яткан таякны алып, каргага томырды.

— Кар-р-р!

Кош утырган урынында талпынып кына куйды.

Син тәүбә итсәң дә, мин иттәдем,
Чибәр-чибәр кызлар кочмаска...

Нәрсә, сиңа гына оя корырга кирәк дип уйлыйсың мәллә? Менә мин дә, бәлки, гаилә кору нияте белән йөримдер. Син комачауламасаң...

Егет үз кочагында изрәп ятучы кызны иркәләп, чәчләреннән сыйпап куйды.

— Кар-р-р!

— Көш-ш-ш! Ычкын моннан!

Егет каргага тагын бер ботак ыргытты. Ачуы кабарып, сикереп торыр дәрәҗәгә җитте. Һәм шулай эшләде дә. Тик... ачудан түгел, куркудан. Кош, канатларын җәеп, утырган ботагында бер-ике тапкыр җилпенеп алды да туптуры егеткә таба атылды...

— Җаным, әйдә китик моннан. — Көтелмәгән хәлдән кыз да каушап калган иде. — Мин куркам.

Егет сөеклесен тынычландырырга ашыкты.

— Курыкма, бәгърем, саташкан кош кына бит ул, — дип, кызны кочагына кысты. — Якынтирәдә йә балалары бардыр. Үзенчә шуларны саклавыдыр.

Күңеленә курку салкыны кереп оялаган кызның үз киресе кире. Кош очып киткән тарафка күз ташлый-ташлый, өс-башын рәткә китерде. Ала карга күрше агачка килеп кунды.

Бәйрәм кәефе җилгә очты. Егет карганың җиде буын нәселен телгә ала-ала сүгенеп җибәрде, кызга ияреп, ял паркыннан чыгу юлына таба атлады.

— Ниндидер бер карга аркасында... — диде ул, үзалдына сөйләнгәндәй. — Минем, нәрсә, ял итәргә хакым юкмы әллә? Үзем теләгәнчә...

— Язмагандыр инде, күрәсең. — Кыз, тынычландырырга теләгәндәй, анын беләгеннән кысып тотты.

Бераз читтәрәк нәни оныгы белән саф һава суларга дип чыккан олы яшьләрдәге апа йөри. Агачтан агачка куныи артларыннан килгән ала каргага карана-карана атлаучы яшьләрне күреп, аларга дәште:

— Нәрсә, сезгә дә бәйләнәме әллә?

Яшьләр туктап калдылар.

— Карганы әйтәм. Ни хикмәттер ирегетләр затыннан булганнарга бәйләнә ул карга. Сезне дә куркыттымы?

Яшьләр сагаеп калды. Нәрсә сөйли бу апа?

— Таяк белән дә куып карадым, һич арттан калмый, туп-туры өскә килә тәмуг кошы. — Егет башларыннан узган мажараны әлеге апага сөйләп бирде. — Ничек котылырга да белгән юк.

Апаның җавабы яшьләрне тагын да ныграк гаҗәпләндерде.

— Аннан алай гына котылып булмый. Монда йөрсәгез, төнгә хәтле артыгыздан калмаячак. Иң яхшысы — парктан бөтенләй чыгып китү... Беркөнне шулай бер кечкенә малай артыннан куа бу, немец бомбардировщигы кебек туп-туры өстенә килә. Такталан ясалган ниндидер корылма бар тегендәрәк, — апа аттракционнар ягына ымлады, — бала шуның астына кереп посты. Карга — аның артыннан.

Ходайның рәхмәте, ерак түгел генә бер ир үтеп бара иде, баланы шул коткарып калды... Белмим, ни сәбәпле шулай кылангандыр карга. Оясын туздырганга дисәң инде... әллә бөтенләй карга түгелдер, кем белә... Берәр рәнҗетелгән кеше җаны булмагае, диюем. Гөнаһлы кешеләрдән үч алып йөрүе түгел микән? Андый нәрсәләргә ышанып бетмәсәм дә, уйландыра бит...

Карга, дөрестән дә, яшьләрне парк капкасын чыкканчы каркылдап озатып барды. Алар тукталышка килеп җиткәндә, парк эчендә янә карга тавышы, аннан берәүнең аты-юлы белән сүгенүе ишетелде. Күрәсең, кош яңа корбанына һөҗүм башлаган иде...

Гөнаһ, имеш! Әйтеп тә карады инде...

Өенә кайтышлый, парктагы апаның сүзләрен, чираттагы сөяркәсе бүләк иткән татлы минутларны исенә төшереп, егет үзалдына мыскыллы елмаеп куйды. Һәм нәкъ шул мизгелдә машинасының ачык тәрәзәсенә уктай атылган ала карганы күреп, күз аллары караңгыланып китте. Үзе дә сизмәстән, рульне сулга каерды. Зур тизлек белән каршыга килгән иномарканың кара тәрәзәсендә коты очкан егетнең карашы гына береге калды...

# Биш баганалы юл

*(Шаян хикәя)*

Бу туган көн дигәннәрен ел саен үз өендә, үз хатыны белән генә үткәрүче башка ир-атлар ничек түзә икән соң? Ул көнең ял вакытына да туры килсә...

Иртә таңнан алып караңгы төнгә чаклы, нишләргә дә белмичә, өйдә каңгырып утырасың. Элек... Менә элек, ичмасам, бу мәсьәләдә бер кайгың юк иде дисәң дә була: ара-тирә генә булса да, дус-ишне, шешәдәш братларны чакырырга мөмкинлекләр чыгып кына тора иде. Хәзер соң аның кесә ягы кунак чакырырлыкмыни?!

Ул «көтү» дигән нәрсә бик хәтәр әйбер бит, әйеме. Менә син эшкә барышлый автобус туктальшында басып торып кара! Йә булмаса, торак-коммуналь идарәсенә барып, фатир өчен акча түләү өчен генә булса да чиратка бас әле. Кешесе дә шул алтмыш-җитмештән артмас, югыйсә. Көтә-көтә көтек булып бетәсең, билләһи. Әле чиратта тору бер хәл, менә нинди дә булса мәҗлесне көтеп утырып кара син!

«Хатын-кызга нәрсә?! Аңа кайда да рәхәт, ашарга әзерләп, кибеттән кибеткә чабып көн үткәнен сизми дә кала торгандыр әле. Инде алай да вакыты кала икән, рәхим ит, ванна тулы юасы кер көтеп тора. Үзе көтеп карамагач, хатын-кызлар ир-атның хәлен аңлыймы соң инде?!»

Шундый уйлар белән җәфалана-җәфалана йөреп, Гәрәй абзый быел хатынын шәһәрдәге улларына барырга күндерде бит, ниһаять.

— Ичмасам, бер генә тапкыр булса да ту-

ган көнемне балалар белән бергәләшеп каршылыйк әле, — диде ул. — Үзләренең дә күптәннән кайтып күренгәннәре юк...

...Якшәмбе көнне дә эшләтмәсәләр... Гәрәй абзыйның улы заводтан кайтмаган иде әле. Килене белән карчыгы кухняда тыз-быз килә башладылар. Ну, кытыклый гына бит бер нәрсә Гәрәй абзыйның бугазын! «Кая, булмаса, малай кайтканчы бераз кәефләнеп алыйм әле», — дип, сумкасыннан бер шешә «кәкре тамган нәрсә»не тартып чыгарды да бер чәркә тутырып эчеп тә куйды. Ух, рәхәт! Гәрәй абзыйның эченә җылы йөгерде.

Бер читтә күзәтеп торган хатыны Гәрәй абзыйга кинаяле караш ташлады да:

— Фу, саран, үзеңнең туган көнеңдә, балалар каршында шушындый җирәнгеч нәрсә чөмереп утырасыңмы инде?! — дип куйды.

Гәрәй абзый да төшеп калганнардан түгел, җавабын бик тиз тапты:

— Менә, менә, карчык. Ниһаять, синнән дә акыллы сүз чыкса чыгар икән. Югыйсә, эчеп кайткан саен, «Берни турында уйламыйсың, рәхәтләнеп эчеп кенә йөрисең» дип сүгә башлый идең. Җирәнгеч нәрсәне рәхәтләнеп эчеп буламыни?!

— Әй, теленә салынмасана. Синеке шул булыр инде, һәрнәрсәгә җавабың бар. — Хатыны, «сүз бетте» дигән сыман кырт борылып, эшен дәвам итте.

Гәрәй абзыйга тагын газета укып, көтеп утырырга гына калды.

— Картым, бар әле, күрше урамдагы сөт кибетеннән каймак алып кайт. Тик, кара аны, андый әчкелтем-төчкелтем белән шаярасы булма, җитәр! Ишетсен колагың, үзеңнең шәһәрдә кунакта икәнлегеңне исеңдә тот!

Гәрәй абзыйның бер дә урамга чыгасы килеп тормый иде. Шәһәрне белмәвен сәбәп итеп, бармаска булган иде дә, килене кибетнең кай тирәдә икәнлеген бәйнә-бәйнә аңлатып бирде. Киленнән яхшы түгел шул, барырга туры килә...

Гәрәй абзый әкрен генә киенде дә, акча алып, урамга чыкты. Ничек рәхәт!.. Подъезд ишегенә сөялеп, тәмәке тартып җибәрде.

«Туктале, минем кордаш Зәки дә шәһәргә дип киткән иде бит. Кызлары шул кибет тирәсендә генә торырга тиеш. Зорге урамында. «Кибете дә, йорты да, фатиры да 13 нче, каһәр» дип сөйләнгән иде кордаш. Кереп чыгыйм, булмаса...»

...Авылдашы Зәки кунак булып яткан фатирны бик тиз тапты Гәрәй абзый. Шул кибет урнашкан йортның өченче катында булып чыкты. Авылдашын, кордашын күргәч, нишләргә дә белми утырган Зәкигә дә җан кергәндәй булды. Йөзләренә хәтле алсуланып китте тегенең. Хәл-әхвәлләр сорашканнан соң, билгеле инде, «ирләр законы» таләп иткәнчә, Зәки бераз гына төшереп алырга тәкъдим ясады. Гәрәй абзыйның андый сый-хөрмәттән баш тарта торган начар гадәте юк иде. «Эчмим» дип кыланган булып, гомерлек ахирәтеңнең хәтерен калдырып булмас бит инде. Зәки тулып торган чокырларны бер-бер артлы бушата башлады.

Зәки авылдашына озак кына карап утырды да сорап куйды:

— Карале, кордаш, эчкән вакытта нишләп күзләреңне чытырдатып йомасың син?

Гәрәй абзыйның кәефе күтәренке: өйдә газета укып улын көтеп утырудан котылуына шатланып бетә алмый.

— Әй, өйдән чыгып киткәндә, карчыкка: «Ара-

кыга бер күз белән дә карамам», — дигән идем, — диде ул һәм тагын бер порция аракыны ялт иттереп куйды.

Зәки чыгарган шешә тиз бөкләнде. Үзара пышылдашып кына алдылар да саф һавага чыктылар. Бер-бер артлы тарта торгач, яңа гына ачылган тәмәке кабы да бушап калды.

«Нишләргә? Әле бик иртә, өйгә кайтсаң, тагын малайны көтеп кенә утырасы булыр — килен әйткәннәр дөрес булса, ул бу вакытта гына кайтмас...»

— Кордаш, әйдә, бер ярты алыйк та әнә теге сыраханәгә кереп утырыйк. Иркенләп сөйләшеп, гәпләшеп алырбыз. — Гәрәй абзыйның дустыннан да акыллы сүз чыгар икән... Зәкинең тәкъдиме бертавыштан кабул ителде.

Азык-төлек кибетенең аракы сатыла торган бүлегендә чиратның беткәне бармы? Ике ахирәт ун-унбиш кешелек чиратның койрыгына бастылар да кешеләр сөйләшкәнне тыңлап тора башладылар. Юк ла, кешеләр түгел, радио сөйли икән — һава торышы турында әйтәләр: «Казанда — 20, Мәскәүдә — 25, Ташкентта 40 градус...».

Чираты җиткән бер сәрхуш җитди генә кыяфәт белән сатучы кызга дәшә:

— Карале, Казанныкы гына ашказаныма ярап бетмәстер, Ташкентныкын бир инде син, кызым, кырык градуслысын, — ди.

Әй, башланды шул вакыт! Бөтен кеше эчен тотып көлә, кибет стеналары, аракы шүрлекләре зыңгылдап тора. Үзеннән көлгәннәрен аңлап ук бетермәде булса кирәк, теге сәрхуш, тизрәк бер яртыны куенына кыстырып, чыгып таю ягын карады.

Сыраханәдә аракы чөмереп утырган өчен чүт кенә эләкмәде ахирәтләргә. Кайдандыр

урланган диярсең — үзең белән алып килгән «җылыткычларны» эчәргә ярамый икән анда, соңыннан гына белделәр. Сыраханә хуҗасы сизми дә калган булыр иде, әлбәттә, барысы да закуска аркасында килеп чыкты. Кабымлыкка ике шешә сыра, ике телем ипи сорадылар. Китермиләр генә бит шуларны. Гәрәй абзыйның ачуы кабарды.

— Сез нәрсә монда кешене мыскыл итеп утырасыз? Без инде ярты сәгать буе кабымлык көтеп утырабыз, кыл да кыймылдатмыйсыз, — дип җикерде ул берәүгә.

— Ә тегесе, берни булмагандай, бәдрәф ишеге төбендә тәмәке пыскытуын белә.

Борчылмасагыз да була, бабай, без әле бүген төнге бердә генә бикләнәбез, өлгерерсез ипи ашарга, — дип мыскыллаган була бит әле, җитмәсә.

Билгеле, Гәрәй абзыйның түземлеге беткән иде, сикереп торып, тегенең арт сабагын укытырга ниятләде. Шулчак куенындагы шешәсе идәнгә төшеп китеп, чак кына челпәрәмә килмәде. Орыштылар Зәки белән Гәрәй абзыйны, сыраханә тәртипләрен аңлаттылар, шулай да, әйбәтләп сорагач, аракыларын эчеп бетерергә рөхсәт иттеләр үзе.

...Сыраханәдән чыкканда караңгы төшкән иде инде. «Шәп кенә булды әле бу, көннең үтеп киткәне сизелми дә калды бит. Малай да эшеннән кайткандыр инде», — дип җиңел сулап куйды Гәрәй абзый. Авылдашы белән хушлашты да, хатынының йомышын исенә төшереп, кибеттән каймак алып чыкты. «Кайтырга кирәк, озак гуләйт ителде», — дип кабатлады ул үзалдына. Тик...

Шул вакыт Гәрәй абзый кайтыр юлын онытып җибәрде. Искә генә төшми бит. Нишләргә

соң инде хәзер?.. Азрак бер урында таптаныл торды да, килененең сүзләрен исенә төшерергә азаплана-азаплана, атлап китте.

«Ай-й-й!..»

Биш-алты адым гына атлаган иде, Гәрәй абзыйның маңгаена кемдер шак итеп китереп тә бәрде. Авыртуга түзмичә, үкереп үк куйды Гәрәй абзый. Як-ягына караныл алды: беркем юк. Менә әкәмәт! Мизгел эчендә мөгез кебек тырпаерга өлгергән маңгаен ышкый-ышкый, тозлап-борычлап сүгенеп куйды да юлын дәвам иттерде.

Көне буе чөмерелгән аракы, сыра инде болай да шактый гына (шактый гынамы соң?!) башына киткән иде. Көтелмәгән хәлдән Гәрәй абзыйның зиһене тагын да чуалыбрак киткән төсле тоелды, башы да чыдап булмаслык дәрәҗәдә авырта, каһәре. Ну, өйгә кайтып кергәч, карчыгы да, килене белән малае да Гәрәйнең авызын ачтырмаячаклар инде... Өйне тапсаң ярый ла...

«Тукта, килен нәрсә дигән иде соң әле, ну бу хәтер дигәнен...»

«Шык!..»

Гәрәй абзый икенче «мөгез»ен дә уып куйды...

«Ура, искә төште бит наканис! Килен, өй белән кибет арасында биш багана тора, дигән иде бит. Башка урамнарда берәр генә багана утыра, дип тә әйткән иде бугай... Инде икенче мәртәбә «кочаклаштым», димәк, юлны дөрес сайлаганмын, шөкер...»

Гәрәй абзый сөенеченнән өченче бағананы да сөзеп алуын сизми калды...

# Эчтәлек

Зимагур *(Повесть)* . . . . . . . . . . . . . . 3

Хикәяләр

Җан тартмаса... *(Чын хикәя)* . . . . . . 80
Сабантуй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Бәхет пилмәне . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Өмет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Сукбай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
«Ышан миңа!» . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Ала карга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Биш баганалы юл *(Шаян хикәя)* . . . . . 168

Литературно-художественное издание

**Фалях** Амур
(**Фаляхов** Амур Нурович)

ЗИМОГОР

Казань. Татарское книжное издательство. 2010
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Фәләх** Амур
(**Фәләхов** Амур Нур улы)

ЗИМАГУР

Мөхәррирләре *Ф.М.Хафизов, Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.10.2010.
Форматы 75×90 1/32. Шартлы басма табагы 6,88.
Тиражы 2000 д. Заказ О-1471.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Таттмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.